ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

_31.05.2019_________ Казан ш. № __62______

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук үзләренә карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм(яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә торак-төзелеш кооперативлары-ның күпфатирлы йортлар төзелешенә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү тәртибен раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы, «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карарлары нигезендә,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының Татарстан Республикасының аларга карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007

елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган аерым муниципаль берәмлекләрендә күпфатирлы йортлар төзелешенә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны турыдан-туры тәэмин итүче башлык урынбасарларына, структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренә әлеге Регламент нигезләмәләренә тайпылмыйча таянып эш итәргә.

3. Хокук идарәсенең юридик бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Җыелма анализ бүлегенә Регламентны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук үзләренә карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм(яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзелешенә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 сентябрендәге 87 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге боерык үтәлүен тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгының беренче урынбасары И.Ф.Сафиуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның «___» маендагы № ___ боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук үзләренә карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм(яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзелешенә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламенты**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ АТАЛЫШЫ

1.1. Бу Регламент Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук үзләренә карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзелешенә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру» дәүләт функциясен үтәгәндә административ процедураларның (гамәлләрнең) чорларын һәм эзлеклелеген (алга таба, тиешенчә – дәүләт функциясе, дәүләт контроле (күзәтчелеге)), шулай ук дәүләт функциясен үтәгәндә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре һәм предприятиеләр, юридик затлар һәм физик затлар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

### ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ БАШКАРМА ОРГАНЫНЫҢ ИСЕМЕ

1.2. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) Инспекция тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) турыдан-туры гамәлгә ашыручы булып Инспекциянең өлешле төзелешне тикшерүдә тоту бүлеге (алга таба – Бүлек) тора.

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) турыдан-туры Бүлекнең Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) нигезендә тикшерү уздыруга вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) Инспекция тарафыннан Татарстан Республикасы прокуратура органнары (алга таба – прокуратура органнары), үзкөйләнешле оешмалар, экспертлар, эксперт оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, гражданнар белән аларның мөрәҗәгатьләре буенча хезмәттәшлек итеп гамәлгә ашырыла.

«Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры), торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына, «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертү билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла.

## ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫ ҖАЙГА САЛУЧЫ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.3. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 1 ст.);

Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 14 ст.);

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 44, 4147 ст.);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1, 40 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Торак төзелешен үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 161-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 30, 3617 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 1, 26 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Төзүче оешмалар бөлгенлеккә төшкәндә (банкрот булганда) гражданнар – өлешле төзелештә катнашучылар хокукларын яклау буенча гавами-хокук компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017 елның 31 июле, № 31 (1 өлеш), 4767 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 1 июлендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 175-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 28, 4139 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 25 декабрендәге 478-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 478-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 51 (1 өлеш), 8404 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы

турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 8, 1239 ст.);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йортлар төзү (булдыру) өчен гражданнарның һәм юридик затларның акчасын җәлеп итү хокукына ия булган төзүче оешманың шәхси акчасын исәпләү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 11 июнендәге 673 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 2018 елның 11 июнендәге 673 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 25, 3693 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы сайты адресын билгеләү турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 1133 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 40, 6137 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карарының 5 пунктына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2019 елның 13 мартындагы 259 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 15 март);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче оешма эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгы нормативлары турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 31 декабрь);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы турында» 2019 елның 26 мартындагы 319 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 28 март);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шул документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан соратыла һәм алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар исемлеге (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Проект декларациясе формасын раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш Министрлыгының 996/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2016, 30 декабрь);

РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 өлешләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве турында бәяләмә формасын раслау турында» 2018 елның 11 октябрендәге 653/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш Министрлыгының 653/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 28 декабрь);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзүче оешмалар тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзелеш проектларын һәм шартнамәләр буенча үз йөкләмәләрен, төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеген гамәлгә ашыруның якынча графикларын үтәү турында хисаплылык формасын һәм контрольдә тотучы органга тапшыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш Министрлыгының 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы) (www.pravo.gov.ru), 2019, 21 февраль);

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 66-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, 2007, № 259, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2007, № 43, 1707 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 елның 23 августындагы 593 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 65, 2059 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән

объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзелешенә төзелеш өчен гражданнардан акча җәлеп итүче затлардан, торак-төзелеш кооперативыннан һәм мондый кооператив күпфатирлы йорт төзелешенә бәйле шартнамәләрне төзегән бүтән затлардан алына торган гражданнарның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләр, мәгълүматлар һәм (яки) документлар исемлекләре турында» 2013 елның 11 октябрендәге 750 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 77, 2609 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 31 октябрендәге 974 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 89, 2905 ст.).

## ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) ОБЪЕКТЛАРЫ

1.4. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итүче затларга (алга таба шулай ук – үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлар) карата гамәлгә ашырыла):

1) төзүче оешмалар;

2) торак-төзелеш кооперативлары.

Әлеге Регламент максатлары өчен «төзүче оешма» төшенчәсе 214-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясында билгеләнгән мәгънәдә кулланыла, «торак-төзелеш кооперативы» төшенчәсе РФ Торак кодексында билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

## ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) ПРЕДМЕТЫ

1.5. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затларның түбәндәге таләпләрне үтәве дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы булып тора:

төзүче оешмалар тарафыннан – 214-ФЗ номерлы Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне (зарури таләпләрне);

торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан – РФ Торак кодексының 110 статьясының 3 өлешендә, алга таба күпфатирлы йортны карап тотудан тыш, һәм РФ Торак кодексының 123.1 статьясында билгеләнгән таләпләрне (зарури таләпләрне).

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты статусы бирелгән юридик затларга карата 473-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре исәпкә алына.

## ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА ИНСПЕКЦИЯНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫ ӨЧЕН ХОКУКЛАР, БУРЫЧЛАР ҺӘМ ЧИКЛӘҮЛӘР

1.6. Инспекциянең вазыйфаи затлары дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) хезмәт таныклыгын яисә Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) тикшерү уздыру турында күрсәтмәсе күчермәсен күрсәтеп, үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затларның зарури таләпләрне үтәү-үтәмәвен тикшерү максатларында, аларның эшчәнекләрен гамәлгә ашыру урыннарына каршылыкларсыз үтеп керергә;

2) үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлардан, тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) кабул ителгәннән соң кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматларны соратырга, урынга чыгып документларны тикшергәндә тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле булган документларны алырга, әгәр мондый документлар урынга чыгып тикшерү алдыннан булган документар тикшерү барышында тикшерелмәгән булса;

3) Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистика мәгълүматларын формалаштыру буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан төзүче оешмаларның күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә, торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзелеше өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә контрольлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга;

4) җирле үзидарә органнарыннан күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә (шул исәптән күпфатирлы йорт (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын төзүгә бәйле документларны), торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзелеше өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә контрольлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны (шул исәптән күпфатирлы йорт төзелешенә бәйле документларны) һәм мәгълүматларны җирле үзидарә органнарыннан алырга;

5) салымнар һәм җыемнар турында законнар үтәлешен тикшереп тору һәм күзәтү буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (андагы белешмәләрне), 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 7 пунктында билгеләнгән таләпләрнең төзүче оешма тарафыннан үтәлүенә, торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йорт төзелеше өчен кооператив әгъзалары акчасын

җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә контрольлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга;

6) эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә төзүче оешма тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 8 пунктында, РФ Торак кодексының 116.1 статьясының 1 пунктында билгеләнгән таләпләрнең үтәлүенә контрольлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга;

7) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә төзүче оешмаларның, торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар, торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә контрольлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны хокукларны теркәүгә алу органыннан алырга;

8) төзелеш өчен гражданнар акчасын җәлеп итүче затлардан, торак-төәелеш кооперативыннан һәм мондый затлар белән күпфатирлы йорт төзелешенә бәйле шартнамәләр төзегән бүтән затлардан 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән чорда дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне, мәгълүматны һәм (яисә) документларны алырга;

9) үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлардан телдән яисә язмача рәвештә аңлатмалар алырга;

10) тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

11) квартал саен төзүче оешмадан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзүче оешма тарафыннан төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графикларының, шартнамәләр буенча үз бурычларының үтәлүе турында хисаплылыкны, төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеген, шулай ук Россия Федерациясе законнарындагы таләпләр нигезендә төзелгән бухгалтериянең аралык һәм еллык (финанс) хисаплылыгын алырга;

12) квартал саен торак-төзелеш кооперативыннан торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан төзелеш өчен гражданнарның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән мондый кооперативның үз бурычларын кооператив әгъзалары һәм бүтән затлар каршында үз вазыйфаларын үтәве турында, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт бирегән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән формада һәм тәртиптә хисаплылык, шулай ук Россия Федерациясе законнарындагы таләпләр

нигезендә төзелгән бухгалтериянең аралык һәм еллык (финанс) хисаплылыгын алырга;

13) торак-төзелеш кооперативының идарә органнарыннан ачыкланган бозуларны бетерүне таләп итәргә;

14) өлешле төзелештә катнашучыларның, күпфатирлы йорт төзелешендә үз акчасы белән катнашучы торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә, – мондый хокуклар һәм мәнфәгатьләр бозылган очракта;

15) ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирергә;

16) төзүче оешманы, торак-төзелеш кооперативын, аларның вазыйфаи затларын РФ Торак кодексы һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тарту өчен кирәкле чараларны күрергә;

17) зарури таләпләрнең үтәлүен тәэмин итү буенча чаралар күрүне тәкъдим итеп, зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтмә бирергә һәм (яисә) җибәрергә;

18) Административ хокук бозулар турында РФ кодексы нигезендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә;

19) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда административ хокук бозулар турында эшләрне карарга;

20) җинаять җаваплылыгына тартылырлык гамәл билгеләренә ия булган зарури таләпләр бозылу фактларын ачыклауга бәйле материалларны, җинаять эшләрен кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен, хокук саклау органнарына җибәрергә;

21) үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлар тарафыннан шикаять белдерелгән очракта, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үз гамәлләренең нигезле булуын дәлилләргә;

22) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясының 15 пунктында каралган нигезләрдә төзүче оешманың күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген билгеле бер чорга туктату турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә;

23) 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен берничә тапкыр яисә җитди бозган очракта яисә аталган закон нигезендә кабул ителгән бүтән норматив хокукый актлар нигезендә, шулай ук федераль законнарда каралган бүтән очракларда төзелеш өчен гражданнарның акчасын җәлеп итүче затны ликвидацияләү турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә;

24) торак-төзелеш кооперативы Инспекция билгеләгән чорда ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәне үтәмәгән очракта, шулай ук, әгәр бу бозулар торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә чын куркыныч тудырса, тиешле бозуларны бетергәнчегә кадәр кооперативның яңа әгъзаларын җәлеп итү буенча торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген туктату турында күрсәтмә чыгарырга; торак-төзелеш кооперативы Инспекция күрсәтмәләрен үтәмәгән очракта, Инспекция бу кооперативны ликвидацияләү турында таләп белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы;

25) федераль законнарда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

1.7. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар түбәндәгеләрне бурычлы:

1) зарури таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм чикләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын, үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затларның хокукларын һәм законлы мәфнәгатьләрен сакларга;

3) Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) тикшерү уздыру турындагы күрсәтмәсе нигезендә аның билгеләнүе нигезендә тикшерү уздырырга;

4) тикшерүне фәкать хезмәт вазыйфаларын үтәү вакытында гына, урынга чыгып тикшерүне фәкать хезмәт таныклыкларын, Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе күчермәсен күрсәтеп кенә уздырырга;

5) үзенә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү уздырганда катнашуына һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләрдә аңлатмалар бирүенә каршы килмәскә;

6) үзенә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган, тикшерү уздырганда катнашучы юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагылышлы мәгълүматларны һәм документларны тапшырырга;

7) үзенә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган зат җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) үзенә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затның җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозу фактлары буенча күреләчәк чараларны билгеләгәндә күрсәтелгән чараларның бозуларның авырлыгына, аларның гражданнар, юридик затлар өчен потенциаль хәтәренә туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре нигезсез рәвештә чикләнүгә юл куймаска;

10) үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлар тарафыннан шикаять белдерелгән очракта, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үз гамәлләренең нигезле булуын дәлилләргә;

11) 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тикшерүне үткәрү срокларын үтәргә;

12) үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлардан күрсәтелүе Россия Федерациясе законнарында каралмаган документларны һәм бүтән белешмәләрне таләп итмәскә;

13) урынга чыгып тикшерү уздыра башлаганчы үзенә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының

яисә вәкаләтле вәкиленең гозере буенча аларны уздырыла торган тикшерүгә нигез булган әлеге Регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) уздырылган тикшерү турында, үзенә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затларда ул булган очракта, тикшерүләрне исәпкә алу журналында теркәргә.

1.8. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар түбәндәгеләрне хокуклы түгел:

1) әгәр мондый таләпләр Инспекция вәкаләтләренә карамаса, зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук үтәлеше Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган зарури таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

4) аны үткәргәндә юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмый торган очракта урынга чыгып планнан тыш тикшерүне гамәлгә ашырырга;

5) әгәр алар тикшерү объектлары булып тормаса яисә тикшерү предметына карамаса, документлар, мәгълүматлар, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның нөсхәләрен алырга;

6) продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә млхит объектларын һәм җитентерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу өчен күрсәтелгән үрнәкләрне, пробаларны алу турында беркетмәләрне билгеләнгән рәвешендә рәсмиләштермичә һәм илкүләм стандартларда, үрнәкләрне, пробаларны алу кагыйдәләрендә һәм аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу методларында, техник регламентларда яисә алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган бүтән норматив техник документларда һәм тикшеренүләрнең, сынауларның, үлчәмнәр алуларның кагыйдәләрендә һәм методларында билгеләнгән нормалардан артып китүче санда алырга;

7) тикшерү уздыру нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, Россия Федерациясе законнарында саклана торган бүтән серне тәшкил итүче мәгълүматны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

8) тикшерү уздыру өчен билгеләнгән чорларны арттырырга;

9) юридик затларга алар хисабыннан контрольлек буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнамәләр бирүне гамәлгә ашырырга;

10) юридик заттан башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган рөхсәт итү документларын да кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелүче документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшыруларын таләп итәргә;

11) юридик заттан тикшерүне үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруны таләп итәргә. Инспекция, тикшерү үткәрү турында күрсәтмә яки боерык кабул ителгәннән соң, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга хокуклы.

## ҮЗЛӘРЕНӘ КАРАТА ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЗАТЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.9. Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле тикшерүне уздырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерүне үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) Инспекция, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагыла торган һәм бирелеше 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган мәгълүматларны алырга;

3) Инспекция тарафыннан документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яисә) мәгълүматларны Инспекциягә үз ихтыяры белән тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән үзенең танышуы, алар белән, шулай ук Инспекция вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән ризалашуы яки ризалашмавы турында күрсәтергә;

6) тикшерү уздырылганда Инспекция вазыйфаи затларының юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китереп чыгарган гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

7) Россия Федерациясе Президенты каршында шәхси эшкуарлар хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты каршында шәхси эшкуарлар хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.10. Үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлар түбәндәгеләрне бурычлы:

1) тикшерү уздырылганда Инспекциянең тикшерүне уздыручы вазыйфаи затларына исемлеге шушы Регламентның 4 нче бүлегендә китерелгән, вазыйфаи затлар тарафыннан соралучы документлардан һәм (яисә) мәгълүматлардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә;

2) урынга чыгып уздырылган тикшерүдә катнашучы вазыйфаи затларга үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлар

тарафыннан файдаланылучы территориягә (биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, бүлмәләргә) керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

3) Инспекциядән дәлилле гарызнамә алынган көннән соң 10 эш көне эчендә гарызнамәдә күрсәтелгән документларны Инспекция адресына җибәрергә;

4) Инспекциянең вазыйфаи затлары күрсәтмәләрендә күрсәтелгән зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерергә;

5) тикшерү уздырылганда юридик затларның җитәкчеләре, бүтән вазыйфаи затлары яисә вәкаләтләре вәкилләре катнашуны тәэмин итргә;

6) Инспекциянең вазыйфаи затларына үзләренең Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләрен үтәү өчен шартлар тудырырга;

7) Инспекциянең вазыйфаи затлары тарафыннан чыгарылган административ җаваплылыкка тарту турында карарны үтәргә;

8) үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә бүтән бурычларга да ия булырга мөмкин.

## ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРУ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1.11. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) 2 нөсхәдә рәсмиләштерелгән тикшерү акты (актның типик рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

2) тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) урынга чыгып уздырылган тикшерү турында язу (тикшерүләрне исәпкә алу журналының рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

3) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

4) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясындагы 5 өлеше нигезендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;

5) ТР Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;

зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта:

6) зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә), тикшерү актына кушымта булып тора (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

7) Административ хокук бозулар турында РФ кодексында каралган административ хокук бозу турында беркетмә (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

Тикшерүдә тоту чарасы барышында тикшерүдә тоту буенча чара уздыру объекты булып торган хуҗалык яисә бүтән эшчәнлекнең законнардагы таләпләрне бозуга бәйле икәнлеге ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм чикләү мәсьәләләре Инспекция компетенциясенә карамаса, Инспекция мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең яисә Татарстан

Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрергә бурычлы.

Әгәр дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен Инспекциягә гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – мөрәҗәгать итүче) килгән мәгълүматлар нигез булып хезмәт итсә, дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРУГА ТАЛӘПЛӘР

### ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Инспекция урнашкан урын: Казан шәһәре, Зур Кызыл ур., 15/9.

Бүлек урнашкан урын: 420061, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 81.

2.2. Инспекциягә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420061, Казан ш., Декабристлар ур., 81.

2.3. Инспекциянең һәм бүлекнең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр, җомга 08.30 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр, шимбә һәм якшәмбе – ял көннәре.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30-17.30, җомга 8.30-16.30, төшке аш 12.00-12.45.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

2.4. Инспекциянең белешмә телефоны: 237-91-87. Бүлек телефоны: 518-36-92

2.5. Инспекциянең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://gsn.tatarstan.ru, электрон почта адресы: gsn@tatar.ru.

2.6. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча, шулай ук Инспекция урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) инспекция холлында урнашкан мәгълүмат стенды аша, анда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә текстлы мәгълүмат урнаштырыла;

2) «Интернет» челтәре аша:

Инспекциянең рәсми сайтында (http://gsn.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Инспекциягә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

4) Инспекциягә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша).

2.7. Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать иткәннән соң кичекмәстән бирелә; язмача рәвештәге мөрәҗәгатькә һәм (яисә) электрон почта буенча мөрәҗәгатькә җавап юридик затның, физик затның адресына почта буенча яисә электрон адресына шушы мөрәҗәгатьне Инспекциядә теркәүгә алганнан соң 30 календарь көненнән артмаган чорда тиешенчә җибәрелә.

Инспекциядә шатыратуны кабул иткән вазыйфаи затның куелган сорауларга җаваплар бирү мөмкинлеге булмаганда, телефоннан элемтәсе башка вазыйфаи затка адреслана (тоташтырыла) яисә мөрәҗәгать итүче затка кирәкле мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номеры хәбәр ителә.

2.8. Мәгълүмат тактасында һәм «Интернет» челтәрендә Инспекциянең рәсми сайтында: http://gsn.tatarstan.ru түбәндәге мәгълүмат материаллары урнаштырыла:

а) Инспекциянең урнашу урыны, эш графигы, телефон һәм факс номерлары, дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат бирә ала торган вазыйфаи затларның электрон почта адресы;

б) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат – әлеге Регламент;

в) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнарының һәм Татарстан Республикасы законнарының төп нигезләмәләре турында мәгълүмат;

г) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга шикаять белдерү тәртибе;

д) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда гамәлләр эзлеклелеген чагылдыра торган блок-схема (әлеге Регламентка 4 нче кушымта).

2.8. Зарури таләпләрне бозуны профилактикалау максатларында «Интернет» челтәрендә шулай ук Инспекциянең рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

а) бозуларны профилактикалау буенча ел саен раслана торган программа;

б) үтәлешен бәяләү дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булган зарури таләпләрне үз эченә ала торган норматив хокукый актларның яисә аларның аерым өлешләренең исемлеге, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстлары;

в) зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шулай ук зарури таләпләрне үтәү буенча бастырып чыгарылган кулланмалар турында мәгълүмат, семинарлар һәм конференцияләр үткәрелүе, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре турында белешмәләр, бүтән ысуллар белән урнаштырылган бүтән мәгълүматлар турында белешмәләр. Зарури таләпләр үзгәртелгән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләрдәге зарури таләпләрне билгели торган яңа норматив-хокукый актларның эчтәлеге, аларның гамәлгә керү вакытлары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук зарури таләпләрне кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән, зарури оештыру, техник чараларны үткәрү турында киңәшләр урнаштырыла;

г) дәүләт функциясен гамәлгә ашыру буенча даими, елына бер мәртәбәдән сирәк булмаган рәвештә башкарыла торган тәҗрибә гомумиләштерү буенча белешмәләр, шул исәптән зарури таләпләрне бозуның иң еш очрый торган

очракларын күрсәтеп, юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан мондый бозуларга юл куймау максатларында күрелергә тиешле чараларга кагылышлы киңәшләр белән.

## ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) БУЕНЧА ЧАРАЛАРНЫ ҮТКӘРГӘН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРДАН ТҮЛӘҮ АЛУНЫҢ ЯРАМАГАНЛЫГЫ

2.9. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча чаралар үткәргән өчен юридик затлардан түләү алынмый, шул исәптән тикшерүләрне үткәрү өчен җәлеп ителгән очракта, экспертларның һәм экспертлык оешмаларының хезмәтләре өчен дә.

## ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОГЫ

2.10. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру срогы түбәндәгечә тәшкил итә:

1) квартал саен тапшырылучы хисаплылыкны тикшерү – төзүче оешмадан Инспекциягә хисаплылык тапшырылган көннән соң 20 эш көненнән артык түгел;

2) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьяларында каралган планнан тыш тикшерүләрне уздыру – 20 эш көненнән артык түгел.

3) төзүче оешмалар, торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан мәгълүмат ачуга һәм урнаштыруга карата билгеләнгән таләпләрне тикшерү – төзүче оешмалар, торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан мәгълүмат ачу һәм урнаштыру срогы тәмамланган вакыттан башлап 3 эш көне эчендә.

## ТИКШЕРҮЛӘРНЕ УЗДЫРУ НИГЕЗЛӘРЕ

2.11. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затларга карата планлы тикшерүләр үткәрелми.

2.12. Төзүче оешмага карата планнан тыш тикшерү үткәрү нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

1) күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итүче затка Инспекция тарафыннан бирелгән 214-ФЗ номерлы Федераль закондагы таләпләрне, шулай ук күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларында, вәкаләтле федераль органның норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәне үтәү вакыты узып китү, әгәр дә мондый чор узып киткәнчегә кадәр күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итүче зат тарафыннан күрсәтмәдә күрсәтелгән бозулар бетерелмәгән булса;

2) төзүче оешманың күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында квартал саен тапшырыла торган хисаплылыгына, Россия Федерациясе законнарындагы таләпләргә нигезләнеп

төзелгән бухгалтерлык хисаплылыгына (шул исәптән еллык) һәм (яисә) проект декларациясенә анализ үткәрү барышында күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турындагы законнарда билгеләнгән зарури таләпләрне бозу билгеләре ачыклану;

3) 214-ФЗ номерлы Федераль закондагы, Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый актларындагы, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларындагы, вәкаләтле федераль органның норматив хокукый актларындагы, җирле үзидарә органнары актларындагы таләпләрне бозу фактлары турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан Инспекциягә мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.2 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән коммерциягә карамаучы оешмалардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән мәгълүматлар килү;

4) төзүче оешманың төзелеш проектын тормышка ашыру буенча якынча графиктан алты һәм аннан күбрәк айга калышуы;

5) 214-ФЗ номерлы Федераль закондагы һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларындагы зарури таләпләрнең бозылуы ачыклаган очракта, Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәсе нигезендә Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) планнан тыш тикшерү уздыру турында чыгарылган боерыгы (күрсәтмәсе);

6) прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлүенә күзәтчелек итү кысаларында прокурорның планнан тыш тикшерү уздыру турында таләп итүе;

7) Инспекциягә 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.2 статьясының 4 өлешендә каралган вәкаләтле банктан хәбәр килүе.

2.13. Торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә планлы тикшерү үткәрү өчен торак-төзелеш кооперативына төзелешкә рөхсәт бирү датасыннан башлап яки төзелеш гамәлгә ашырыла торган Россия Федерациясе субъекты территориясендә мондый кооперативка соңгы планлы тикшерүне үткәрү вакытыннан бер ел узуы нигез булып тора.

2.14. Торак-төзелеш кооперативына планнан тыш тикшерү уздыру өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) торак-төзелеш кооперативының Инспекция тарафыннан бирелгән РФ ТК 110 статьясының 3 өлешендәге, алга таба күпфатирлы йортны карап тотудан тыш, һәм РФ ТК 123.1 статьясындагы таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәне үтәү вакыты узып китү;

2) РФ ТК 110 статьясының 3 өлешендәге, алга таба күпфатирлы йортны карап тотудан тыш, һәм РФ ТК 123.1 статьясындагы таләпләрне бозу фактлары турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан Инспекциягә мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, шулай ук торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан мәгълүматлар килү;

3) прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлүенә күзәтчелек итү кысаларында прокурорның планнан тыш тикшерү уздыру турында таләп итүе.

## ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР

2.15. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәге вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) Инспекция башлыгы;
2) Инспекция башлыгы урынбасарлары;
3) Бүлек башлыгы;
4) Бүлекнең әйдәп баручы киңәшчесе;
5) Бүлекнең әйдәп баручы консультанты.

Тикшерү уздыру өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә аттестацияләнгән һәм үзләренә карата тикшерүләр уздырыла торган юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән гражданый-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм тикшерелүче затларның аффилир затлары булып тормаучы экспертлар, аккредитацияләүнең илкүләм системасында аккредитацияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аккредитацияләнгән эксперт оешмалары җәлеп ителергә мөмкин.

## РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ЗАКОННАРЫН БОЗГАН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.16. Тикшерүләр уздыруга нигезсез рәвештә каршы төшкән, тикшерүләр уздырудан читләшкән һәм (яки) билгеләнгән чорларда Инспекциянең зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәсен үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре яки вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

## ДӘҮЛӘТ (КОНТРОЛЕН) КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА ИНСПЕКЦИЯНЕҢ, АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.17. Инспекция, аның вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә, тиешенчә, функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешле дәрәҗәдә үтәмәгән очракта, хокукка каршы килә торган гамәлләр кылганда (гамәл кылмаганда), Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгән көннән соң ун көн эчендә Инспекция язмача рәвештә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка хәбәр итәргә бурычлы.

# 3. ЮРИДИК ЗАТЛАРГА КАРАТА БЕЛДЕРЕЛӘ ТОРГАН ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘР

3.1. Юридик затларга карата белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге, тиешле таләпне билгели торган норматив хокукый актларны күрсәтеп, 1 нче таблицада китерелде.

1 нче таблица – Юридик затларга карата белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге

| Контрольлек объектлары (эшчәнлек төрләре, контрольлек төрләре) | Зарури таләпнең тәгъбирләнеше | Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Барлык төзүче оешмалар (өлешле төзү объектын төзүгә рөхсәт алу срогына бәйсез рәвештә һәм өлешле төзелештә катнашучылардан алынган акчаны 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясында каралган тәртиптә эскроу счетларында урнаштыруга яки урмнаштырмауга карамастан) | 1.1. Күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын төзү өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү юридик зат (төзүче оешма) тарафыннан өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла, бары тик түбәндәгеләрдән соң:<br>1) күпфатирлы йорт һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын төзүгә рөхсәт алганнан соң;<br>2) төзүче оешма тарафыннан составларына өлешле төзелеш объектлары керәчәк күпфатирлы йорт һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен тапшырылган җир кишәрлегенә милекчелек хокукы яисә «Торак төзелешен үстерүгә теләктәшлек турында» федераль законда яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясының 2 пунктындагы 15 пунктчасында каралган очракларда мондый җир кишәрлегенең аренда шартнамәсе, субаренда шартнамәсе, мондый җир кишәрлегеннән түләүсез нигездә файдалану шартнамәсе дәүләт теркәвенә алынганнан соң;<br>3) проект декларациясе бастырып чыгарылганнан соң, урнаштырылганнан соң һәм (яисә) тапшырылганнан соң | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше<br>РФ Җир кодексының 39.10 статьясының 2 пунктындагы 15 пунктчасы |
| | 1.2. Төзүче оешма күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүне (булдыруны) төзелешкә бер яки берничә рөхсәт чикләрендә өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп түбәндәге шартларның берәрсен гамәлгә ашырырга хокуклы:<br>1) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.2 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | статьясының 4 өлеше таләпләрен үтәү;<br>2) өлешле төзелештә катнашучылар акчасын 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясында каралган тәртиптә эскроу счетларында урнаштыру | |
| | 1.3. Проект декларациясенә төзүче оешма тарафыннан үзгәрешләр кертү:<br>1) төзүче оешма проект декларациясенә төзүче оешма һәм төзелеш проекты турындагы белешмәләргә, шулай ук проект документациясенә үзгәрешләр кертелү фактларына кагыла торган үзгәрешләрне тиешле белешмәләр үзгәргән көннән башлап өч эш көне эчендә кертергә бурычлы;<br>2) төзүче оешма квартал саен агымдагы елның финанс нәтиҗәсе, соңгы хисап датасына кредитор һәм дебитор бурычының күләмнәре турында үзгәрешләрне проект декларациясенә кертергә тиеш;<br>3) проект декларациясенә булган үзгәрешләр 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясында күрсәтелгән торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш һәм билгеләнгән тәртиптә проект документациясенә үзгәрешләр кертелгән көннән башлап биш эш көне эчендә төзүче оешма тарафыннан Инспекциягә җибәрелергә тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 4-6 өлешләре<br><br>Россия Төзелеш министрлыгының 996/пр боерыгы |
| | 1.4. Төзүче оешма өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзүче оешма тарафыннан төзелеш проектын тормышка ашыруның якынча графикларының, шартнамәләр, төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеге буенча үз бурычларының үтәлүе турында хисаплылыкны, шулай ук Россия Федерациясе законнарындагы таләпләр нигезендә төзелгән аралык һәм еллык бухгалтерия (финанс) хисаплылыгын Инспекциягә тапшырырга тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясының 6 өлешендәге 6 пункты |
| | 1.5. Төзүче оешманың коллегиаль башкарма органы, төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы яки идарәче компания, әгәр ул төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашырса, яки төзүче оешманың вакытлыча бер кулдагы башкарма органы (алга таба – төзүче оешма җитәкчесе), төзүче оешманың баш бухгалтеры һәм күрсәтелгән вазыйфаларга кандидатлар 214-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясында билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.<br>Төзүче оешма төзүче оешма җитәкчесенең вәкаләтләре туктатылуы турында, төзүче оешманың яңа җитәкчесен сайлау (билгеләү) турында, шулай ук төзүче оешманың вакытлыча бер кулдагы башкарма органын оештыру турында карарлар кабул ителгән | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | вакыттан башлап өч эш көненнән соңга калмыйча бу хакта Инспекциягә хәбәр итәргә һәм аталган затларның әлеге статья таләпләренә җавап бирүе турында мәгълүмат тапшырырга тиеш.<br>Төзүче оешманың җитәкчесе яки төзүче оешманың баш бухгалтеры булып түбәндәгеләр тора алмый:<br>1) икътисад эшчәнлеге өлкәсендә кылынган җинаять яки дәүләт хакимиятенә каршы кылынган җинаять өчен алынмаган яки үтәлмәгән хөкеме булган зат;<br>2) үзенә карата квалификациядән мәхрүм ителү рәвешендә административ җәзага тартылган булып саналган срогы узмаган зат;<br>3) «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик зат йөкләмәләре буенча субсидиар җаваплылыкка һәм (яки) юридик заттан югалтуларны түләттерү рәвешендә җаваплылыкка тартылган зат, әгәр зат тарафыннан суд актында билгеләнгән йөкләмәне үтәгән көннән башлап биш елдан азрак вакыт узса;<br>4) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2 өлеше нигезендә проект декларациясен Инспекциягә җибәрү датасыннан алдагы биш ел эчендә юридик затның бер кулдагы башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашырган зат арбитраж суды тарафыннан бөлген (банкрот) дип танылган булса;<br>5) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2 өлеше нигезендә проект декларациясен Инспекциягә җибәрү датасыннан алдагы өч ел дәвамында зат турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аркылы) төзүче оешманың акцияләренең (өлешләренең) биш процентыннан артык өлешенә ия булган булып, арбитраж суды тарафыннан бөлген (банкрот) дип танылса.<br>Ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аркылы) корпоратив юридик затка – төзүче оешмага (капиталында биш проценттан артык өлешендә катнашучы) ия физик зат 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясының 3 өлешендәге таләпләренә җавап бирергә тиеш | |
| | 1.6. Төзүче оешма, аны 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясында күрсәтелгән торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән, 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган мәгълүматтан ирекле файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә (мәгълүмат ачарга) бурычлы. Күрсәтелгән системада (наш.дом.рф) урнаштырылганнан соң, мәгълүмат ачылган булып санала. Өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче төзүче оешма түбәндәге | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясы, 23.3 статьясының 3.1, 4 өлешләре |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүматларны ачарга тиеш:<br>1) 214-ФЗ номерлы федераль законның 20 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт;<br>2) 214-ФЗ номерлы федераль законның 21 статьясының 2 өлешендәге 1, 3, 5 пунктларда күрсәтелгән документлар;<br>3) проект декларациясе;<br>4) төзүче оешманың һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында Инспекция бәяләмәсе;<br>5) өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе проекты яисә күпфатирлы йортны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү буенча төзүче оешма тарафыннан кулланыла торган, 214-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган шундый шартнамәләрнең проектлары;<br>6) 214-ФЗ номерлы федераль законның 15.4 һәм 15.5 статьялары таләпләре нигезендә өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү шартлары, мондый акча эскроу счетларында урнаштырылган очракта;<br>7) 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының 5 өлешендә күрсәтелгән документлар;<br>8) өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп, төзүче оешма тарафыннан төзелә (булдырыла) торган күпфатирлы йортның һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектының агымдагы төзелеш (булдырылу) торышын чагылдыручы фотолары;<br>9) җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы;<br>10) җир кишәрлегенең шәһәр төзү планында күрсәтелгән мәгълүматларга ярашлы рәвештә эшләнгән, капиталь төзелеш объекты урнашкан урынны, аңа машина белән килү һәм үтү юлларын, гавами сервитутларның гамәлдәге зоналары чикләрен, археологик мирас объектларын билгеләп, җир кишәрлеге оештыруның планлаштырылган схемасы;<br>11) төзүче оешманың шәхси акча күләмен исәпләү һәм финанс тотрыклылыгы нормативлары турындагы мәгълүматны үз эченә алган документ;<br>12) «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында белешмәләр;<br>13) капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында шәһәр төзү эшчәнлеге турындагы | |

| | | |
|---|---|---|
| | законнар нигезендә җибәрелгән хәбәр;<br>14) төзүче оешманың исәп-хисап счетын ачу турында яки ябу турында белешмәләр, мондый счетның номерын, вәкаләтле банк исемен һәм аның идентификаторларын (салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры) күрсәтеп;<br>15) 214-ФЗ номерлы федераль законда каралган бүтән мәгълүмат | |
| | 1.7. Әлеге пунктның 2, 3, 5, 6, 8-10, 13 пунктчаларында күрсәтелгән мәгълүмат төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган һәр күпфатирлы йортка һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектына карата ачыла. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясының 2.1 өлеше |
| | 1.8. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында (наш.дом.рф) төзүче оешманың һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында Инспекция бәяләмәсен алган көннән башлап биш эш көне эчендә урнаштырылырга тиеш. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясының 2 өлешендәге 8 пунктында күрсәтелгән фотолар күрсәтелгән системада ай саен урнаштырылырга тиеш. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясының 2 өлешендәге 11 пунктында күрсәтелгән белешмәләр төзүче оешма тарафыннан аталган системада квартал саен 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 5 өлешендә каралган мәгълүматны урнаштыру белән бер үк вакытта урнаштырылырга тиеш.<br>214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ачылырга тиешле белешмәләргә һәм документларга кертелгән үзгәрешләр мондый үзгәрешләр кертелгән көннән башлап өч эш көне эчендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында (наш.дом.рф) урнаштырылырга тиеш. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясының 3, 4 өлешләре |
| | 1.9. Төзүче оешма өлешле төзелештә катнашучыдан шартнамәне дәүләт теркәвенә алганчыга кадәр шартнамә бәясен түләүне таләп итәргә хокуклы түгел. Шартнамә бәясен түләү түләүләрне бер мәртәбә яки шартнамәдә билгеләнгән чорда налсыз тәртиптә түләү юлы белән гамәлгә ашырыла. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясының 3 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | 1.10. Төзүче оешма өлешле төзелеш объектын өлешле төзүдә катнашучыга шартнамәдә каралган һәм төзүче оешма күпфатирлы йорт һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объекты составына яки күпфатирлы йортта уртак файдалану территориясенә чыгу юлы булган аерым килү өлешенә ия блок-секция составына керә торган өлешле төзелеш объектларын тапшырырга тиешле өлешле төзелештә катнашучылар өчен бердәй була алмый торган сроктан соңга калмыйча тапшырырга тиеш, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясының 3 өлешендә билгеләнгән очрактан тыш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясының 1 өлеше |
| | 1.11. Әгәр күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын төзү (булдыру) шартнамәдә каралган срокта тәмамлана алмаса, төзүче оешма күрсәтелгән срок узганчыга кадәр ике айдан соңга калмыйча өлешле төзелештә катнашучыга тиешле мәгълүматны һәм шартнамәне үзгәртү турында тәкъдим җибәрергә тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясының 3 өлеше |
| | 1.12. Төзүче оешма өлешле төзелештә катнашучыга сыйфаты шартнамә шартларына, техник регламентларның, проект документациясенең һәм шәһәр төзү регламентларының таләпләренә, шулай ук бүтән зарури таләпләргә җавап бирә торган өлешле төзелеш объектын тапшырырга тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлеше |
| | 1.13. Өлешле төзелеш объектын тапшырганда төзүче оешма өлешле төзелештә катнашучыга өлешле төзелеш объектын эксплуатацияләү буенча аны нәтиҗәле һәм куркынычсыз файдалану кагыйдәләре һәм шартлары, өлешле төзелеш объектының хезмәт итү срогы һәм аның составына керә торган төзекләндерү элементлары, инженер-техник тәэминат системалары, конструктив элементлар, эшләнмәләр турында кирәкле һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә алган аңлатмалар тапшырырга тиеш. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1.1 өлеше |
| | 1.14. Өлешле төзелеш объектының, мондый өлешле төзелеш объекты составына керщ торган технологик һәм инженерлык җиһазланышыннан тыш, гарантия срогы шартнамәдә билгеләнә һәм биш елдан да азрак була алмый. Күрсәтелгән гарантия срогы өлешле төзелеш объектын тапшырган көннән башлап, мондый өлешле төзелеш объекты составына керщ торган технологик һәм инженерлык җиһазланышыннан тыш, өлешле төзелеш объектын өлешле төзелештә катнашучыга тапшырган көннән башлап исәпләнә, әгәр шартнамәдә башкача каралмаса.<br>Өлешле төзелештә катнашучыларга тапшырыла торган өлешле төзелеш объект составына керә торган | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 5, 5.1 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | технологик һәм инженерлык җиһазларына гарантия срогы шартнамәдә билгеләнә һәм өч елдан да азрак була алмый. Күрсәтелгән гарантия срогы беренче тапшыру акты яки өлешле төзелеш объектын тапшыру турында бүтән документ имзаланган көннән башлап санала. | |
| | 1.15. Өлешле төзелеш объектын тапшыру билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт алынганнан соң да иртәрәк булмаган чорда гамәлгә ашырыла.<br>Төзүче оешма тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт алынганнан соң, төзүче оешма өлешле төзелеш объектын шартнамәдә каралган сроктан соңга калмыйча тапшырырга бурычлы. Бу вакытта төзүче оешманың өлешле төзелеш объектын тапшыру йөкләмәсен вакытыннан алда үтәве рөхсәт ителми, шартнамәдә башкача каралмаса. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 2, 3 өлешләре |
| | 1.16. Төзүче оешма, өлешле төзелеш объектын тапшыру буенча шартнамәдә билгеләнгән срок килеп җиткәнчегә кадәр кимендә бер ай алдан яки, әгәр шартнамәдә өлешле төзелеш объектын тапшыруның һәм кабул итүнең башлану срогы күздә тотылса, тапшыру һәм кабул итү срогы башланганчыга кадәр кимендә ундүрт көн алдан өлешле төзелештә катнашучыга күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын төзүне (булдыруны) шартнамә нигезендә төгәлләү турында һәм өлешле төзелеш объектының тапшыруга әзер булуы турында хәбәр җибәрергә, шулай ук өлешле төзелештә катнашучыны өлешле төзелеш объектын кабул итү зарурлыгы турында һәм өлешле төзелештә катнашучының гамәл кылмавының 214-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 6 өлешендә каралган нәтиҗәләре турында кисәтергә тиеш. Хәбәр почта аша заказлы хат белән, теркәлгәннәрнең исемлеге һәм өлешле төзелештә катнашучы күрсәткән почта адресы буенча тапшырылуы турында хәбәре белән җибәрелергә яки өлешле төзелештә катнашучыга шәхсән кул куйдыртып тапшырылырга тиеш. Бу вакытта өлешле төзелеш объектын тапшыра һәм кабул итә башлау срогы төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелеш объектын өлешле төзелештә катнашучыга тапшыруның шартнамәдә билгеләнгән срогыннан ундүрт көннән алдарак һәм бер айдан соңгарак калып билгеләнә алмый. Төзүче оешмадан күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын төзүне | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 4 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | (булдыруны) шартнамә нигезендә төгәлләү турында һәм өлешле төзелеш объектының тапшыруга әзер булуы турында хәбәр алган өлешле төзелештә катнашучы шартнамәдә каралган срокта яки, мондый срок билгеләнмәсә, аталган хәбәрне алган көннән башлап җиде эш көне эчендә аны кабул итүгә керешергә тиеш. | |
| | 1.17. Төзүче оешма, шартнамә 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 1 өлешендә каралган нигезләрдә таркатылган очракта, шартнамәне таркаткан көннән башлап егерме эш көне эчендә яки, шартнамә 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1.1 өлешендә каралган нигезләрдә таркатылган очракта, шартнамәне таркаткан көннән башлап ун эш көне эчендә өлешле төзелештә катнашучыга аның шартнамә хисабына түләнгән акчасын кайтарып бирергә, шулай ук күрсәтелгән акчадан файдаланган өчен әлеге сумма буенча өлешле төзелештә катнашучы түләгән акчаны кайтару йөкләмәсе үтәлгән көнгә гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә процентлар түләргә тиеш. Күрсәтелгән процентлар өлешле төзелештә катнашучы акчаны яки акчаның бер өлешен шартнамә бәясе хисабына керткән көннән башлап төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучыга кайтарып бирелгән көнгә кадәр түләнә. Әгәр өлешле төзелештә катнашучы булып гражданин торса, күрсәтелгән процентлар төзүче оешма тарафыннан икеләтелгән күләмдә түләнә. Әгәр тиешле билгеләнгән срок дәвамында өлешле төзелештә катнашучы төзүче оешмага өлешле төзүдә катншаучы тарафыннан шартнамә бәясе хисабына түләнгән акчаны һәм күрсәтелгән акча чараларыннан файдаланган өчен әлеге суммага процентларны алу артыннан мөрәҗәгать итмәсә, төзүче оешма, күрсәтелгән срок узган көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча, акчаны һәм акча чараларыннан файдаланган өчен процентларны төзүче оешма урнашкан урын буенча нотариус депозитына күчерергә тиеш, бу хакта өлешле төзелештә катнашучыга хәбәр ителә. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 2 өлеше |
| | 1.18. Төзүче оешма шартнамәне үтәүдән 214-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясының 4 һәм 5 өлешләрендә каралган нигезләр буенча бер яклы баш тарткан очракта, төзүче оешма өлешле төзелештә катнашучы тарафыннан шартнамә бәясе хисабына түләнгән акчаны аны таркаткан көннән башлап ун эш көне эчендә кайтарып бирергә тиеш. Әгәр | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 5 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән срокта өлешле төзелештә катнашучы төзүче оешмага өлешле төзелештә катнашучы тарафыннан шартнамә бәясе хисабына түләнгән акчаны алу өчен мөрәҗәгать итмәсә, төзүче оешма, күрсәтелгән срок узган эш көненнән соңгы көннән соңга калмыйча, әлеге акчаны төзүче оешма урнашкан урын буенча нотариус депозитына күчерергә тиеш, бу хакта өлешле төзелештә катнашучыга хәбәр ителә. | |
| | 1.19. Төзүче оешма акчаны кайтарып бирүнең яки әлеге акчаны нотариус депозитына кайтарып бирүнең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 2 һәм 5 өлешләрендә каралган срогын бозган очракта, төзүче оешма өлешле төзелештә катнашучы түләгән акча чараларын кайтарып бирү буенча тиешле йөкләмәне үтәү көненә Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә күрсәтелгән акчадан файдаланган өчен әлеге суммага процентларны өлешле төзелештә катнашучыга түли. Күрсәтелгән процентлар төзүче оешманың акчаны өлешле төзелештә катнашучыга кайтарып бирү срогы тәмамланган көннән яки әлеге акчаны нотариус депозитына күчерү срогыннан башлап төзүче оешма тарафыннан акчаны өлешле төзелештә катнашучыга кайтарып бирү көненә кадәр яки мондый акчаны нотариус депозитына күчерү көненә кадәр исәпләнә. Әгәр өлешле төзелештә катнашучы булып гражданин торса, күрсәтелгән процентлар төзүче оешма тарафыннан икеләтелгән күләмдә түләнә | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 6 өлеше |
| | 1.20. Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, төзүче оешма өлешле төзелештә катнашучыга 214-ФЗ номерлы Федераль законда һәм күрсәтелгән шартнамәдә каралган неустойканы (штрафларны, пеняларны) түләргә һәм китерелгән сарыфларны неустойканы арттырып, тулы күләмендә капларга тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы |
| | 1.21. Яклар тарафыннан тапшыру акты яки өлешле төзелеш объектын тапшыру турында бүтән документ имзаланган вакытка кадәр төзүче оешманың йөкләмәләре үтәлгән булып санала алмый. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясының 1 өлеше |
| | 1.22. «Гражданнар – өлешле төзелештә катнашучылар хокукларын яклау фонды» гавами-хокук компаниясе (алга таба – Фонд) таләбе буенча төзүче оешмалар гарызнамә килгән датадан башлап ун көн эчендә Фондка белешмәләрнең төгәллеген раслаучы бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын һәм документларны (мәгълүматны) тапшырырга тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясының 2 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | 1.23. Төзүче оешмага карата юридик зат-төзүче оешманы ликвидацияләү процедуралары уздырылмый | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 2 пункты |
| | 1.24. Юридик зат-төзүче оешмага карата «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турында эштә кулланылучы процедураларның берсе кертелүе турында арбитраж суды карарының булмавы, күрсәтелгән федераль законда каралган очраклардан тыш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 3 пункты |
| | 1.25. Юридик зат-төзүче оешмага карата административ җәза чарасы сыйфатында аның эшчәнлеген туктату турында арбитраж суды карарының булмавы | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 4 пункты |
| | 1.26. «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барыла торган намуссыз тәэминатчылар реестрында, «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барыла торган намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрында предметы капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору һәм капиталь ремонтлау өлкәсендә эшләр башкарудан, хезмәтләр күрсәтүдән яисә мондый төзүне, үзгәртеп коруны һәм капиталь ремонтны оештырудан яисә юридик заттан торак урыннары сатып алудан гыйбарәт булган контрактларда яисә шартнамәләрдә каралган үзенең бурычларын үтәү өлешендә юридик зат-төзүче турында (шул исәптән төзүче оешманың бер кулдагы башкарма орган функцияләрен башкаручы зат турында) белешмәләрнең булмавы | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 5 пункты |
| | 1.27. Дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттә торган җир кишәрлеген сату буенча аукционда яисә дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттә торган җир кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучыларның Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясының 28 һәм 29 пунктлары нигезендә алып | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | барыла торган реестрында төзүче оешма турында (шул исәптән төзүче оешманың бер кулдагы идарә органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат турында) мәгълүматлар булмавы | |
| | 1.28. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2.1 өлеше нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның беренчесе белән төзүче оешма арасында шартнамә төзелгәнчегә кадәр бирелгән, төзүче оешманың һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә булуы | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 9 пункты |
| | 1.29. Юридик зат-төзүче оешманың узган календарь елы өчен күләмнәре соңгы хисап датасына әҗәтле-юридик затка карата таләпләрнең җыелма күләменә тигез булган яки аны уздырып җибәрә торган салымнар, җыемнар буенча түләнмәгән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бүтән мәҗбүри түләүләр буенча әҗәте булмавы (Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә кичектереп, ваклап түләү мөмкинлеге, инвестицияле салым кредиты бирелгән, аларга карата мөрәҗәгать итүченең бу суммаларны түләү бурычларын үтәлгән дип тану турында законлы көченә кергән суд карары булган яисә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган суммалардан тыш), чөнки бу хәл «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турында эш кузгату өчен шарт булып тора. Төзүче оешма, әгәр аның тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән түләнмәгән йөкләмәләргә, әҗәтләргә шикаять белдерү турында гариза тапшырылса һәм мондый гариза буенча карар кабул ителмәгән булса яки күрсәтелгән түләнмәгән йөкләмәләргә, әҗәтләргә шикаять белдерү буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срок узмаган булса, билгеләнгән таләпкә җавап бирә дип санала. Әлеге кагыйдә «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда кулланылмый | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 7 пункты |
| | 1.30. Төзүче оешманың бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затның, төзүче оешманың коллегиаль, башкарма органы әгъзасы булып торган затның яисә идарәче компаниянең бер кулдагы башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы затның, әгәр дә ул төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы функцияләрен гамәлгә | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | ашырса, яисә төзүче оешманың бер кулдагы вакытлыча башкарма органының (алга таба – төзүче оешма җитәкчесе), ахыр чиктә турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аркылы) корпоратив юридик зат-төзүче оешмага хуҗа булган (капиталында егерме биш проценттан артык күләмдә катнашу өстенлегенә ия булган) физик затның, төзүче оешманың баш бухгалтерының 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе № 214-ФЗ | |
| 2. Өлешле төзелештә катнашучылар акчасын 214-ФЗ номерлы федераль законның 15.4 статьясында каралган тәртиптә эскроу счетларында урнаштырмаучы төзүче оешмалар | 2.1. Төзүче оешма, шартнамә 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 1 өлешендә каралган нигезләрдә таркатылган очракта, шартнамәне таркаткан көннән башлап егерме эш көне эчендә яки, шартнамә 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1.1 өлешендә каралган нигезләрдә таркатылган очракта, шартнамәне таркаткан көннән башлап ун эш көне эчендә өлешле төзелештә катнашучыга аның шартнамә хисабына түләнгән акчасын кайтарып бирергә, шулай ук күрсәтелгән акчадан файдаланган өчен әлеге сумма буенча өлешле төзелештә катнашучы түләгән акчаны кайтару йөкләмәсе үтәлгән көнгә гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә процентлар түләргә тиеш. Күрсәтелгән процентлар өлешле төзелештә катнашучы акчаны яки акчаның бер өлешен шартнамә бәясе хисабына керткән көннән башлап төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучыга кайтарып бирелгән көнгә кадәр түләнә. Әгәр өлешле төзелештә катнашучы булып гражданин торса, күрсәтелгән процентлар төзүче оешма тарафыннан икеләтелгән күләмдә түләнә. Әгәр тиешле билгеләнгән срок дәвамында өлешле төзелештә катнашучы төзүче оешмага өлешле төзүдә катншаучы тарафыннан шартнамә бәясе хисабына түләнгән акчаны һәм күрсәтелгән акча чараларыннан файдаланган өчен әлеге суммага процентларны алу артыннан мөрәҗәгать итмәсә, төзүче оешма, күрсәтелгән срок узган көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча, акчаны һәм акча чараларыннан файдаланган өчен процентларны төзүче оешма урнашкан урын буенча нотариус депозитына күчерергә тиеш, бу хакта өлешле төзелештә катнашучыга хәбәр ителә. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 2 өлеше |
| | 2.2. Төзүче оешма шартнамәне үтәүдән 214-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясының 4 һәм 5 өлешләрендә каралган нигезләр буенча бер яклы баш тарткан очракта, төзүче оешма өлешле төзелештә | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 5 |

| | | |
|---|---|---|
| | катнашучы тарафыннан шартнамә бәясе хисабына түләнгән акчаны аны таркаткан көннән башлап ун эш көне эчендә кайтарып бирергә тиеш. Әгәр күрсәтелгән срокта өлешле төзелештә катнашучы төзүче оешмага өлешле төзелештә катнашучы тарафыннан шартнамә бәясе хисабына түләнгән акчаны алу өчен мөрәҗәгать итмәсә, төзүче оешма, күрсәтелгән срок узган эш көненнән соңгы көннән соңга калмыйча, әлеге акчаны төзүче оешма урнашкан урын буенча нотариус депозитына күчерергә тиеш, бу хакта өлешле төзелештә катнашучыга хәбәр ителә. | өлеше |
| | 2.3. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13-15 статьяларында билгеләнгән тәртиптә залог белән төзелешкә бер рөхсәт нигезендә күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын төзү өчен төзелгән барлык шартнамәләр буенча төзүче оешманың түбәндәге йөкләмәләренең үтәлүе тәэмин ителергә тиеш:<br>1) өлешле төзелештә катнашучы керткән акчаны кайтарып бирү, әлеге федераль законда һәм (яки) шартнамәдә каралган очракларда;<br>2) өлешле төзелештә катнашучыга өлешле төзелеш объектын тапшыру буенча йөкләмәләрне үтәмәү, үтәүне кичектерү яки башкача тиешенчә үтәмәү нәтиҗәсендә югалтуларны каплау һәм (яки) неустойка (штраф, пенялар) сыйфатында һәм шартнамә һәм (яки) федераль законнар нигезендә аңа тиешле башка төрле акчаны түләү | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясының 1 өлеше |
| | 2.4. Төзүче оешманың исәп-хисап счеты буенча 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә акча күчерү һәм исәптән чыгару операцияләре гамәлгә ашырылырга мөмкин. Төзүче оешманың исәп-хисап счетыннан акча бары тик түбәндәге максатларда гына файдаланыла ала:<br>1) бер күпфатирлы йортны яисә берничә күпфатирлы йортны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең составларына өлешле төзелеш объектлары кергән бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен, проект документациясе нигезендә, күрсәтелгән күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) төзелеш өчен бер яки төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә гамәлгә ашырылу шарты белән;<br>2) 214-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясының 1 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләрен мөлкәткә сатып алу яки арендага алу максатларында | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 1 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | түләүләр, мондый җир кишәрлекләре өчен аренда түләвен түләү, шулай ук рөхсәтле файдалану төрен үзгәрткән өчен түләү кертү, мондый җир кишәрлекләрендә урнашкан биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне төзүгә һәм үзгәртеп коруга «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 3 пункты нигезендә билгеләнгән тыюны алган өчен түләү;<br>3) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен проект документациясен әзерләү һәм инженерлык эзләнүләрен башкару, шулай ук проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә, дәүләт экология экспертизасын уздыру, әгәр мондый экспертизаларны мәҗбүри уздыру турындагы таләп федераль законнарда билгеләнгән булса;<br>4) хокук иясе булып төзүче оешма торган җир кишәрлеге чикләрендә әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын инженер-техник тәэмин челтәрләренә тоташтыру өчен кирәкле әлеге инженер-техник тәэминат челтәрләрен төзү, үзгәртеп кору, әгәр ул тиешле проект документациясендә каралган булса;<br>5) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын инженер-техник тәэминат челтәрләренә тоташтырган (технологик ялгаган) өчен түләү кертү;<br>6) шәһәр төзү эшчәнлеге турында законнар нигезендә стандарт торак төзү максатларында территорияне үзләштерү турында төзелгән шартнамә һәм аны үтәүгә бәйле түләүләр, әгәр мондый шартнамә буенча стандарт торак төзелеше өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылса;<br>7) шәһәр төзү эшчәнлеге турында законнар нигезендә йортлар салынган территорияне үстерү турында төзелгән шартнамә буенча түләүләр, әгәр әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) төзүче оешмага әлеге шартнамә нигезендә тапшырылган һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.1 статьясы таләпләрен исәпкә алып, йортлар салынган мондый территория чикләрендә торучы җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылса; Шул ук вакытта бер күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөлкәтнең бүтән объектын яки берничә күпфатирлы йорт һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең берничә объектын әлеге шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла торган төзелешкә бер рөхсәт чикләрендә төзү проекты (алга таба – төзелеш проекты) буенча гамәлгә ашырылырга тиешле түләүләрнең күләме әлеге шартнамә буенча түләнергә тиешле акчаның исәпләнгән суммар күләменнән чыгып планлаштырыла торган һәр төзелеш проектының бәясенә пропорциональ рәвештә билгеләнә һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясының 1 өлешендәге 10.1 пункты нигезендә проект декларациясендә күрсәтелә;<br>8) Россия Федерациясенең шәһәр төзү эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә, шул исәптән стандарт торак төзелеше максатларында, территорияне комплекслы үзләштерү турында төзелгән шартнамә, хокук ияләренең инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә, җирле үзидарә органнары инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү шартнамәсе буенча түләүләр, әгәр әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) әлеге шартнамәләр нигезендә, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.1 статьясы таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырылса. Шул ук вакытта әлеге шартнамәләр буенча гамәлгә ашырыла торган төзелеш проекты буенча гамәлгә ашырылырга тиешле түләүләрнең күләме төзүче оешма тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, әлеге шартнамәләр буенча түләнергә тиешле акчаның исәпләнгән суммар күләменнән чыгып, һәр төзелеш проектының планлаштырылган бәясенә пропорциональ билгеләнә һәм әлеге Федераль законның 21 статьясының 1 өлешендәге 10.1 пункты нигезендә проект декларациясендә күрсәтелә;<br>9) территорияне планлаштыру буенча документация әзерләү, мондый территория чикләрендә инженер-техник инфраструктура объектларын, балалар өчен мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрен, гомуми белем бирү мәктәпләрен, поликлиникалар урнаштыру өчен билгеләнгән социаль инфраструктура объектларын һәм, транспорт инфраструктурасы объектларын дәүләт мөлкәтенә яки муниципаль мөлкәткә түләүсез нигездә тапшыру очрагында, транспорт инфраструктурасы объектларын (юллар, тротуарлар, велосипед юллары) төзү һәм үзгәртеп кору, әгәр әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 6-8 | |

| | | |
|---|---|---|
| | пунктларында күрсәтелмәгән бүтән очракларда 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.1 статьясы таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырылса;<br>10) кредит шартнамәсендә, шул исәптән кредит бирүгә бәйле, бүтән түләүләргә каралган максатчан кредитлар буенча процентларны түләү һәм әҗәт суммасын каплау һәм (яки) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга, шулай ук 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 1 өлешендәге 7-9 пунктларында күрсәтелгән очракларда, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.1 статьясы таләпләрен исәпкә алып, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга) максатчан займнар (максатчан займ шартнамәсе шартларын бозган өчен неустойкадан (штрафлардан, пенялардан) тыш) буенча процентларны түләү һәм әҗәтнең төп суммасын каплау;<br>11) өлешле төзелештә катнашу шартнамәләрен дәүләт теркәвенә алу белән бәйле түләүләр;<br>12) вакытлыча ирекле акчаны төзүче оешманың исәп-хисап счеты ачылган вәкаләтле банкта ачтырылган банк счетындагы депозитка урнаштыру, әлеге акчаның һәм мондый депозит буенча исәпләнгән процентларның күрсәтелгән акча урнаштырылган төзүче оешманың исәп-хисап счетына кире кайтарылырга тиеш булу шарты белән;<br>13) төзүче оешманың исәп-хисап счетында булган акча белән операцияләр башкарган өчен вәкаләтле банк хезмәтләрен түләү;<br>13.1) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2.3-1 өлеше нигезендә башка вәкаләтле банкта ачылган счетка акча чараларын күчерү;<br>14) Россия Федерациясе законнарында билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда Россия Федерациясенең тиешле бюджет дәрәҗәсенә һәм (яки) бюджетныкы булмаган дәүләт фондларына түләнә торган салымнарны, җыемнарны һәм мәҗбүри бүтән кертемнәрне, шул исәптән Россия Федерациясенең тиешле бюджет дәрәҗәсенә һәм (яки) бюджетныкы булмаган дәүләт фондларына түләнә торган салымнарны, җыемнарны һәм мәҗбүри бүтән кертемнәрне түләү йөкләмәсен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен штрафларны, пеняларны һәм бүтән санкцияләрне, шулай ук административ штрафларны һәм җинаять законнарында билгеләнгән штрафларны түләү;<br>15) компенсация фондына мәҗбүри түләүләрне (кертемнәрне) түләү;<br>16) өлешле төзелештә катнашучы тарафыннан шартнамә бәясе хисабына түләнгән акчаны кайтару, | |

| | | |
|---|---|---|
| | шулай ук, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында каралган очракларда, күрсәтелгән акчадан файдаланган өчен әлеге суммага процентлар түләү;<br>17) тиешле салымнарны, иминият кертемнәрен Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясенең Социаль иминиятләштерү фондына, Мәҗбүри медицина иминиятләштерү буенча федераль фондка берьюлы түләү шарты белән, хезмәткә түләү, әгәр мондый салымнарны һәм кертемнәрне түләү федераль законнарда каралган булса;<br>18) төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы коммерция оешмасы хезмәтләре өчен түләү;<br>19) хезмәткәрләргә Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган гарантияләрне һәм компенсацияләрне бирүгә бәйле акчалата түләүләр;<br>19.1) төзелеше өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасы җәлеп ителгән күпфатирлы йортта һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектында мондый күчемсез мөлкәт объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт алынган көннән башлап, әгәр күрсәтелгән биналарга милекчелек хокукы теркәлмәгән булса, торак һәм (яки) торак булмаган биналарны, машина урыннарын карап тотуга бәйле чыгымнарны түләү, шул исәптән коммуналь хезмәтләр өчен түләү;<br>20) башка чыгымнарны, шул исәптән рекламага, коммуналь хезмәтләргә, элемтә хезмәтләренә булган чыгымнарны, төзүче оешманың идарә органнарын һәм хезмәткәрләрен урнаштыруны, шулай ук аларның эш урыннарын һәм оргтехниканы да кертеп, төзүче оешма эшчәнлеген тәэмин итү максатларында торак булмаган бина арендасына бәйле сарыфларны түләү | |
| | 2.5. Әлеге таблицаның 2.4 пунктындагы 13, 17-20 пунктларында каралган чыгымнар төзелешнең проект бәясенең ун процентыннан артыграк өлешен тәшкил итә алмый, ә халыкара финанс хисаплылыгы стандартлары нигезендә әзерләнгән бердәм финанс хисаплылыгын ачучы төзүче оешмалар яки аларның төп җәмгыятьләре өчен күрсәтелгән чыгымнар төзелешнең проект бәясенең егерме процентыннан артыграк булган өлешен тәшкил итә алмыйлар | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 2 өлеше |
| | 2.6. Әлеге таблицаның 2.4 пунктындагы 1, 3, 4 һәм 9 пунктларында күрсәтелгән максатларда барлык аванс түләүләренең җыелма күләме төзелешнең проект бәясенең утыз процентыннан артыграк булырга тиеш түгел. Шул ук вакытта төзүче оешма, әлеге | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 4 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | чикләүнең билгеле бер өлешен исәпкә алып, һәр шартнамә буенча аванс түләүләре күләмен мөстәкыйль билгели. | |
| | 2.7. Төзүче оешма өлешле төзелештә катнашучылар тарафыннан түләнә торган акчаны һәм төзелешкә киткән чыгымнарны 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 1 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән һәр күпфатирлы йортка һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең һәр объектына карата аерым исәпкә алып барылуын тәэмин итәргә тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 5 өлеше |
| | 2.8. Төзүче оешма, өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүгә һәм төзелешкә бер рөхсәт яки төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга) бәйле эшчәнлектән һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 7.1 өлешендә күрсәтелгән эшчәнлектән тыш, башка төрле эшчәнлекне гамәлгә ашырырга хокуклы түгел | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 6 өлеше |
| | 2.9. Төзүче оешма түбәндәгеләргә хокуклы түгел:<br>1) әлеге статьяның 6 өлешендәге таләпләр нигезендә төзелешкә булган максатчан кредитлардан һәм төзүче оешманың гамәлгә куючылары (анда катнашучылар) тарафыннан бирелүче максатчан займнардан тыш, кредитлар, займнар, ссудалар рәвешендә акча җәлеп итәргә;<br>2) төзүче оешманыкы булган мөлкәтне өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен, шулай ук төзүче оешманың төзелешкә бирелгән бер рөхсәт яисә төзелешкә бирелгән берничә рөхсәт чикләрендә өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә һәм күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга) бәйле булмаган шәхси йөкләмәләрен үтәү өчен файдаланырга;<br>3) өченче затларның йөкләмәләрен тәэмин итү йөкләмәләрен үз өстенә алырга;<br>4) акцияләрдән тыш, кыйммәтле кәгазьләр чыгарырга яки бирергә;<br>5) аңа карата төп җәмгыяте булып торучы башка төзүче оешмага төзүче оешма тарафыннан бирелүче максатчан займнардан тыш, займнар һәм ссудалар бирергә;<br>6) кыйммәтле кәгазьләр сатып алырга;<br>7) коммерцияле һәм коммерциясез оешмалар оештырырга, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларында, башка төрле коммерцияле һәм коммерциясез оешмаларның мөлкәтендә катнашырга, төзүче оешма аларга карата төп җәмгыяте булып торучы (булучы) хуҗалык җәмгыятьләрен – төзүче | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 7 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | оешмаларны оештырудан (аларның устав капиталларында катнашудан) тыш;<br>8) өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә һәм төзелешкә бер рөхсәт яки төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга) яки төзүче оешма эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган бүтән алыш-бирешләрне башкарырга | |
| | 2.10. Төзүче оешма, залог предметына түләттерү йөкләмәсен юнәлдерү нигезләре барлыкка килгәндә, төзелеше тәмамланмаган объектка милекчелек хокукын теркәтергә тиеш. Төзүче оешма төзелеше тәмамланмаган объектка милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алудан баш тартканда, мондый объектка милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алу залог предметына түләттерү йөкләмәсен юнәлдерү турында өлешле төзелештә катнашучы шикаяте буенча кабул ителгән суд карары нигезендә гамәлгә ашырыла | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 5 өлеше |
| | 2.11. Әгәр төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнаучыларның беренчесе белән шартнамә төзелгәнчегә кадәр 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 1-3 өлешләрендә күрсәтелгән мөлкәт төзүче оешманың составына өлешле төзелеш объектлары керә торган күпфатирлы йортны һәм 9яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга) максатчан кредит буенча йөкләмәләрен тәэмин итү сыйфатында залогка тапшырылган булса, төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучылардан акча җәлеп итү түбәндәге шартларны берьюлы үтәү шарты белән рөхсәт ителә:<br>1) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 1-3 өлешләрендә күрсәтелгән мөлкәтне залогта тотучы булып банк торса;<br>2) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 6 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән залогта тотучыдан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 өлеше нигезендә залогка тапшырылган мөлкәт хисабына үз таләпләрен канәгатьләндерүгә ризалык, шулай ук, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 8 өлешендә каралган очракта, өлешле төзелеш объектларына залог хокукын туктатуга ризалык алынганда | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 6 өлеше |
| | 2.12. Төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучыларның беренчесе белән шартнамә төзелгәннән соң 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 1-3 өлешләрендә күрсәтелгән мөлкәт өлешле төзелештә катнашучылар ризалыгыннан | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 7 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | башка залогка тапшырыла алмый, составына өлешле төзелеш объектлары керә торган күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга) төзүче оешмага банк тарафыннан бирелгән максатчан кредитны кайтаруны тәэмин итү буенча банкка залогка тапшыру очрагыннан тыш, банктан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 өлеше нигезендә залогка тапшырылган мөлкәт хисабына үз таләпләрен канәгатьләндерүгә ризалык һәм, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 8 өлешендә каралган очракта, өлешле төзелеш объектларына залог хокукын туктатуга ризалык алыну шарты белән | |
| | 2.13. 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру максатларында төзүче оешма, төзүче оешма белән төзелгән шартнамә нигезендә эшләр башкаручы техник заказчы һәм төзүче оешма белән төзелгән төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә эшләр башкаручы генераль подрядчы бер үк вәкаләтле банкта банк счетлары ачтырырга һәм фәкать күрсәтелгән счетлардан файдаланып кына үзара исәп-хисапларны гамәлгә ашырырга тиеш. Төзүче оешма бер генә исәп-хисап счетына ия булырга хокуклы. Әгәр төзүче оешма төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә бер яисә берничә күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итә икән, мондый төзүче оешманың төзелешкә булган һәр рөхсәт буенча аерым исәп-хисап счеты булырга тиеш. Банк счеты (банк счетлары) шартнамәсенә клиентның вәкаләтле банк тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган мәгълүматның Инспекциягә һәм әлеге Федераль законның 23.2 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән коммерциясез оешмага тапшыруына ризалыгы турында шарт кертелә. Төзүче оешманың банк счетыннан (банк счетларыннан) акчаны исәптән чыгару операцияләре вәкаләтле банк тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.2 статьясында күрсәтелгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта төзүче оешмаларның исәп-хисап счетлары саны төзелешкә рөхсәтләр саныннан артмаска тиеш. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2.3 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | 2.14. Төзүче оешма 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) блоклап төзелә торган өч һәм аннан күбрәк блоклы торак йортларны өлешле төзү өчен гражданнар һәм юридик затлар акчасын җәлеп итәргә хокуклы, торак урынын тапшыруны күздә тотучы өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе дәүләт теркәвенә алынганчыга кадәр күрсәтелгән акчаны (кертемнәрне) күчерү һәм күрсәтелгән акчаны инвестицияләү хисабына сатып алынган мөлкәт хисабыннан формалаштырылучы компенсация фондына акча (кертемнәр) түләү буенча бурычларын үтәве шарт булып тора. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 4 өлеше |
| 3. Өлешле төзелеш объектын төзүгә 2018 елның 1 июленнән соң рөхсәт алган төзүче оешмалар, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясында каралган тәртиптә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын эскроу счетларында урнаштыручы төзүче оешмалардан тыш | 3.1. Төзүче оешма, составына өлешле төзелеш объектлары керә торган бер яки берничә күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын проект документациясе нигезендә төзү (булдыру) өчен, күрсәтелгән күпфатирлы йортларның һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларының төзелеше (булдырылуы) рөхсәткә бирелгән бер рөхсәт чикләрендә, яки җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы яки территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә төзелешкә булган берничә рөхсәт чикләрендә, яки үзенә карата төзеп тутырылган территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән төзеп тутырылган территория яки үзенә карата территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашучы бер яки берничә җир кишәрлегендә төзелешкә бер яки берничә рөхсәт чикләрендә гамәлгә ашырылу шарты белән, өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итәргә хокуклы. Төзүче оешма, бер үк вакытта, әлеге өлештә күрсәтелгән күчемсе мөлкәт объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү буенча эшчәнлекне җир кишәрлегенең берничә шәһәр төзелеше планы яки территорияне планлаштыруның расланган берничә проекты яисә төзеп тутырылган территорияне үстерү турында берничә шартнамә һәм (яки) территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәләр һәм (яки) территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәләр буенча гамәлгә ашырырга хокуклы түгел | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.1 өлеше |
| | 3.2. Проект документациясе һәм проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсе булу | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | | пункты |
| | 3.3. Төзүче оешманың шәхси акча күләме төзелешнең проект бәясенең кимендә ун процентын тәшкил итәргә тиеш. Төзүче оешманың шәхси акчасын хисаплау тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә; | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1.1 пункты |
| | 3.4. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2 өлеше нигезендә проект декларациясен Инспекциягә җибәрү датасына төзүче оешмада 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2.3 өлеше нигезендә вәкаләтле банкта төзүче оешманың банк счетында төзелешнең проект суммасының кимендә ун проценты күләмендә төзүче оешманың шәхси акчалары булуы, яисә күрсәтелгән датага төзүче оешма белән вәкаләтле банк арасында төзелгән, вәкаләтле банктан төзүче оешмага составына өлешле төзелеш объектлары керә торган күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга) вәкаләтле банктан төзелешнең проект бәясенең кимендә кырык проценты күләмендә максатчан кредит бирелүен күздә тотучы кредит шартнамәсенең булуы. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1.2 пункты |
| | 3.5. Төзелешкә бирелгән бер рөхсәт яисә төзелешкә бирелгән берничә рөхсәт чикләрендә өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә һәм күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга) бәйле кредитлар, займнар, ссудалар буенча йөкләмәләр булмавы, максатчан кредитлардан, (максатчан займнардан) тыш; | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1.3 пункты |
| | 3.6. Төзүче оешма тарафыннан, акцияләрдән тыш, кыйммәтле кәгазьләр чыгарыла яки бирелә алмый | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1.4 пункты |
| | 3.7. Төзүче оешманың 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2 өлеше нигезендә проект декларациясен Инспекциягә җибәрү датасына өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә һәм төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күпфатирлы йортлар һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә бәйле булмаган йөкләмәләре төзелешнең проект бәясеннән бер процентка артып китми. Әлеге кагыйдә төзүче | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1.5 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | оешманың 214-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы нигезендә өлешле төзелеш объектындагы җитешсезлекләрне бетерү йөкләмәләренә карата кулланылмый | |
| | 3.8. Төзүче оешманыкы булган мөлкәтнең өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен, шулай ук төзүче оешманың төзелешкә бирелгән бер рөхсәт яисә төзелешкә бирелгән берничә рөхсәт чикләрендә өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә һәм күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүгә (булдыруга) бәйле булмаган шәхси йөкләмәләрен үтәү өчен файдаланылмый | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1.6 пункты |
| | 3.9. Төзүче оешманың өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү буенча бурычлары юк. Әлеге таләп 2017 елның 1 гыйнварына «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1 пунктында каралган һәм әлеге федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән түләү җаваплылыгын үз өстенә алу шартнамәләре буенча түләү җаваплылыгын үз өстенә алучылар булып торучы төзүче оешмаларга кагылмый, мондый төзүче оешмаларның өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү буенча бүтән йөкләмәләре булмавы шарты белән, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1.7 пунктында билгеләнгән таләпкә җавап бирә дип санала | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1.7 пункты<br>175-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 6 өлеше |
| | 3.10. Төзүче оешма финанс тотрыклылыгы нормативларын саклый | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1.8 пункты |
| | 3.11. Төзүче оешманың узган календарь елы өчен күләмнәре соңгы хисап датасына әҗәтле-юридик затка карата таләпләрнең җыелма күләменә тигез булган яки аны уздырып җибәрә торган салымнар, җыемнар буенча түләнмәгән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бүтән мәҗбүри түләүләр буенча әҗәте юк (Россия Федерациясенең | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 7 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә кичектереп, ваклап түләү мөмкинлеге, инвестицияле салым кредиты бирелгән, аларга карата мөрәҗәгать итүченең бу суммаларны түләү бурычларын үтәлгән дип тану турында законлы көченә кергән суд карары булган яисә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган суммалардан тыш), чөнки бу хәл «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турында эш кузгату өчен шарт булып тора. Төзүче оешма, әгәр аның тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән түләнмәгән йөкләмәләргә, әҗәтләргә шикаять белдерү турында гариза тапшырылса һәм мондый гариза буенча карар кабул ителмәгән булса яки күрсәтелгән түләнмәгән йөкләмәләргә, әҗәтләргә шикаять белдерү буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срок узмаган булса, билгеләнгән таләпкә җавап бирә дип санала. Әлеге кагыйдә «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда кулланылмый | |
| 4. Өлешле төзелеш объектын төзүгә 2018 елның 1 июленә кадәр рөхсәт алган төзүче оешмалар, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясында каралган тәртиптә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын эскроу счетларында урнаштыручы төзүче оешмалардан тыш | 4.1. Юридик зат – төзүче оешманың устав (җыелма) капиталы, устав фонды (алга таба – төзүче оешманың устав капиталы) тулысынча түләнгән булырга һәм түбәндәгедән ким булмаска тиеш:<br>1) төзүче оешманың яки төзүче оешманың һәм төзүче оешмага бәйле юридик затларның барча өлешле төзелеш объектларының максималь мәйданы иң күбе бер мең биш йөз квадрат метр булганда – ике миллион биш йөз мең сум;<br>2) төзүче оешманың яки төзүче оешманың һәм төзүче оешмага бәйле юридик затларның барча өлешле төзелеш объектларының максималь мәйданы иң күбе ике мең биш йөз квадрат метр булганда – дүрт миллион сум;<br>3) төзүче оешманың яки төзүче оешманың һәм төзүче оешмага бәйле юридик затларның барча өлешле төзелеш объектларының максималь мәйданы иң күбе ун мең квадрат метр булганда – ун миллион сум;<br>4) төзүче оешманың яки төзүче оешманың һәм төзүче оешмага бәйле юридик затларның барча өлешле төзелеш объектларының максималь мәйданы иң күбе егерме биш мең квадрат метр булганда – кырык миллион сум;<br>5) төзүче оешманың яки төзүче оешманың һәм төзүче оешмага бәйле юридик затларның барча өлешле төзелеш объектларының максималь мәйданы иң күбе илле мең квадрат метр булганда – сиксән миллион | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2.1 өлеше (218-ФЗ номерлы Йедераль закон, 175-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алмыйча); 175-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 7 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | сум;<br>6) төзүче оешманың яки төзүче оешманың һәм төзүче оешмага бәйле юридик затларның барча өлешле төзелеш объектларының максималь мәйданы иң күбе йөз мең квадрат метр булганда – йөз илле миллион сум;<br>7) төзүче оешманың яки төзүче оешманың һәм төзүче оешмага бәйле юридик затларның барча өлешле төзелеш объектларының максималь мәйданы иң күбе ике йөз илле мең квадрат метр булганда – дүрт йөз миллион сум;<br>8) төзүче оешманың яки төзүче оешманың һәм төзүче оешмага бәйле юридик затларның барча өлешле төзелеш объектларының максималь мәйданы иң күбе биш йөз мең квадрат метр булганда – сигез йөз миллион сум;<br>9) төзүче оешманың яки төзүче оешманың һәм төзүче оешмага бәйле юридик затларның барча өлешле төзелеш объектларының максималь мәйданы биш йөз мең квадрат метрдан артыграк булганда – бер миллиард биш йөз миллион сум. | |
| | 4.2. Юридик зат – төзүче оешманың узган календарь елы өчен күләмнәре соңгы хисап чоры өчен бухгалтерия (финанс) хисаплылыгы белешемәләре буенча төзүче оешмадагы активларның баланс бәясенең егерме биш процентыннан артып китүче күләмдә салымнар, җыемнар буенча вакытында түләнмәгән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бүтән мәҗбүри түләүләр буенча әҗәтләре юк (Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә кичектереп, ваклап түләү мөмкинлеге, инвестицияле салым кредиты бирелгән, аларга карата мөрәҗәгать итүченең бу суммаларны түләү бурычларын үтәлгән дип тану турында законлы көченә кергән суд карары булган яисә Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган суммалардан тыш). Төзүче оешма, әгәр аның тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән түләнмәгән йөкләмәләргә, әҗәтләргә шикаять белдерү турында гариза тапшырылса һәм проект декларациясен Инспекциягә җибәрү датасына мондый гариза буенча карар кабул ителмәгән булса, билгеләнгән таләпкә җавап бирә дип санала | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 7 пункты (218-ФЗ номерлы Федераль закон, 175-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алмыйча); 175-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 7 өлеше |
| | 4.3. Төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы функциясен гамәлгә ашыручы затның һәм төзүче оешманың баш бухгалтерының яисә бухгалтерия исәбен алып бару вазыйфасы йөкләнгән бүтән вазыйфаи затының, яисә төзүче оешманың | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 8 |

| | | |
|---|---|---|
| | бухгалтерия исәбен алып бару буенча хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә төзелгән затның икътиад өлкәсендә суд хөкеменә тартылмаган булуы (мондый суд хөкеме үтәлгән яисә алынган затлардан кала), шулай ук күрсәтелгән затларга карата капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору яисә мондый төзүне, үзгәртеп коруны оештыру өлкәсендә билгеле бер вазыйфаларны биләү яисә билгеле бер эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү рәвешендәге җәзаның һәм квалификациясен алу рәвешендәге административ җәзаның кулланылмаган булуы | пункты (218-ФЗ номерлы Федераль закон, 175-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алмыйча); 175-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 7 өлеше |
| 5. Торак-төзелеш кооперативы | 5.1. Торак-төзелеш кооперативы, төзелешне үзләренә муниципаль мөлкәттән яки дәүләт мөлкәтеннән түләүсез нигездә билгеле бер вакытка файдалануга тапшырылган, шул исәптән «Торак төзелешен үстерүгә булышлык күрсәтү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, яки «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә оештырылган җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашырган очракта, шәһәр төзү эшчәнлеге турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның акчаларын җәлеп итү вакытына эксплуатациягә кертелмәгән күпфатирлы йортларны төзү (булдыру) өчен гражданнарның мондый акчаларын җәлеп итүгә хокуклы. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясының 2 өлешендәге 3 пункты |
| | 5.2. Торак-төзелеш кооперативы, мондый торак-төзелеш кооперативы 175-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көннән башлап оештырылган очракта, шәһәр төзү эшчәнлеге турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның акчаларын җәлеп итү вакытына эксплуатациягә кертелмәгән күпфатирлы йортларны төзү (булдыру) өчен гражданнарның мондый акчаларын җәлеп итүгә хокуклы. | 175-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 4 өлешендәге 2 пункты |
| | 5.3. Шәһәр төзү эшчәнлеге турында законнар нигезендә кооператив әгъзалары акчасы хисабына күпфатирлы йорт төзүне гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативы төзүче оешма сыйфатында чыгыш ясый һәм үзендә булган җир кишәрлегендә мондый кооперативка төзелешкә бирелгән рөхсәт нигезендә күпфатирлы йорт төзүне, үзгәртеп коруны тәэмин итә. | РФ Торак кодексының 110 статьясының 3 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | 5.4. Торак-төзелеш кооперативы, төзелеше «Торак төзелешен үстерүгә теләктәшлек турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законда каралган торак-төзелеш кооперативларыннан тыш, берьюлы катларының саны өчтән артык булган бердән артык күпфатирлы йорт төзелешен гамәлгә ашырырга хокуклы түгел. | РФ Торак кодексының 110 статьясының 3 өлеше |
| | 5.5. Кооператив әгъзалары акчасы хисабына күпфатирлы йорт төзүне гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында (алга таба – торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы) кооператив уставын, шулай ук киләсе документларны һәм мәгълүматны урнаштырырга тиеш:<br>1) торак-төзелеш кооперативы әгъзалары санын;<br>2) төзелешендә торак-төзелеш кооперативы әгъзалары үзләренең шәхси акчасы белән катнаша торган күпфатирлы йорт төзелешенә рөхсәт;<br>3) күпфатирлы йорт төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлегенә торак-төзелеш кооперативының хокуклары, шул исәптән җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документ реквизитлары, җир кишәрлегенең милекчесе турында белешмәләр (торак-төзелеш кооперативы җир кишәрлегенең милекчесе булып тормаган очракта), төзекләндерү элементлары турында белешмәләр;<br>4) төзелә торган күпфатирлы йортның урнашкан урыны һәм аның төзелешкә рөхсәт бирүгә нигез булган проект документациясе нигезендә әзерләнгән тасвирламасы;<br>5) төзелә торган күпфатирлы йортта торак урыннар саны, проект документациясе нигезендә мондый торак урыннарына техник сыйфатламаларны тасвирлау, шулай ук проект документациясенә тиешле үзгәрешләр кертелгән очракта күрсәтелгән мәгълүматларны үзгәртү;<br>6) төзелә торган күпфатирлы йортны эксплуатациягә тапшыруга рөхсәт алуның күздә тотылган чоры<br>Торак-төзелеш кооперативларының торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру буенча бурычы 2019 елның 25 сентябреннән барлыкка килә. | РФ ТК 123 статьясының 1 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | 5.6. Торак-төзелеш кооперативы, әлеге кооператив әгъзасы таләбе буенча, танышу өчен, шул исәптән торак төзелешенең бердәм мәгълүмати системасыннан файдалану өчен, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә тиеш:<br>1) проект документациясенә экспертиза бәяләмәсен, әгәр мондый экспертизаның үткәрелүе федераль законда билгеләнгән булса;<br>2) үзенә кертелгән барлык үзгәрешләре белән проект документациясен;<br>3) җир кишәрлегенә торак-төзелеш кооперативының хокукларын раслый торган документларны;<br>4) торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышларының, аның идарәсе һәм ревизия комиссиясе (ревизор) утырышларының беркетмәләрен;<br>5) тавыш бирү нәтиҗәләрен, шул исәптән тавыш бирү өчен бюллетеньнәрне һәм торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышында катнашуга ышаныч кәгазен яки мондый ышаныч кәгазьләренең күчермәләрен раслаучы документларны;<br>6) торак-төзелеш кооперативының ревизия комиссиясе (ревизор) бәяләмәсен;<br>7) әлеге Кодекста, торак-төзелеш кооперативы уставында, аның эчке документларында, әлеге кооператив әгъзаларының гомуми җыелышы карарларында каралган башка документларны.<br>Торак-төзелеш кооперативларының торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру буенча бурычы 2019 елның 25 сентябреннән барлыкка килә. | РФ ТК 123 статьясының 1 өлеше |
| | 5.7. Кооператив әгъзалары акчасына күпфатирлы йорт төзүче торак-төзелеш кооперативы, шул исәптән торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында, үз әгъзаларының реестрын алып барырга тиеш, ул түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:<br>1) торак-төзелеш кооперативы әгъзасының фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме яисә, әгәр торак-төзелеш кооперативның әгъзасы булып юридик зат торса, юридик затның аталышы;<br>2) проект документациясе нигезендә, пай кертемен тулысынча түләп бетергән очракта торак-төзелеш кооперативы әгъзасы тарафыннан милекчелек хокукы алына торган билгеле бер торак урынын билгеләү;<br>3) торак-төзелеш кооперативының һәр әгъзасына карата керү һәм пай кертемнәре күләме<br>Торак-төзелеш кооперативларының торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында | РФ ТК 123.1 статьясының 3 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмат урнаштыру буенча бурычы 2019 елның 25 сентябреннән барлыкка килә. | |
| | 5.8. Кооператив әгъзалары акчасына күпфатирлы йорт төзүче торак-төзелеш кооперативы торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортны төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән кооператив әгъзалары һәм бүтән затлар каршында кооперативның үз бурычларын үтәве турында хисаплылыкны квартал саен Инспекциягә тапшырырга тиеш | РФ ТК 123.2 статьясының 2 өлешендәге 3.3 пункты |

3.2. Юридик затлар тарафыннан зарури таләпләр бозылуны кисәтү, зарури таләпләр бозылуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында Инспекция ел саен үзе тарафыннан расланучы бозуларны профилактикалау программасы нигезендә зарури таләпләр бозылуны профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыра.

3.3. Инспекциядә зарури таләпләрне бозарга әзерләнүләр яисә бозу билгеләре турында юридик затлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын тормышка ашыру барышында алынган яисә килгән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш) бәян ителгән белешмәләр, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар булганда, әгәр зарури таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүе, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фондына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган һәм илкүләм китапханә фонды составына керә торган документларына, дәүләт иминлегенә зыян салуы, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка китерүе яисә күрсәтелгән нәтиҗәләрнең булу куркынычын барлыкка китерүе турында дәлилләнгән белешмәләр булмаса, Инспекция юридик затка зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм юридик затка зарури таләпләрнең үтәлүен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта мондый кисәтүдә билгеләнгән чорда Инспекциягә хәбәр итүне тәкъдим итә.

3.4. Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, мондый кисәтүгә юридик зат тарафыннан шикаять белдерү һәм аларны Инспекция тарафыннан карау, юридик зат тарафыннан Инспекциягә мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы һәм РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары белән расланган Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, мондый кисәтүгә юридик зат тарафыннан шикаятьләр белдерү һәм аларны карау, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

# 4. ТИКШЕРҮ УЗДЫРГАНДА ЮРИДИК ЗАТЛАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив хокукый актлар 2 нче таблицада китерелде.

2 таблица – Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| Тикшерү уздырганда юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар | Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|
| 1. Юридик затның гамәлгә кую документлары (уставы яисә гамәлгә кую шартнамәсе һәм уставы) | |
| 2. Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын (алга таба – Объект) төзү (булдыру) өчен гражданнарның һәм юридик затларның акчасын җәлеп итүче юридик зат җитәкчесе вазыйфасына сайлау турында яисә билгеләү турында, ышанычнамәдән башка күрсәтелгән юридик зат исеменнән аңа эш йөртү хокукын бирә торган карар | |
| 3. Капиталь төзелеш объектларының куркынычсызлыгына йогынты ясый торган эшләрнең билгеле бер төренә яисә төрләренә кертелү турында таныклык | |
| 4. Проект документациясе, аңа кертелгән барлык үзгәрешләрне үз эченә ала | |
| 5. Объект төзелеше проектына техник-икътисадый нигезләү | |
| 6. Проект документациясенә экспертиза һәм (яисә) инженерия эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәсе, әгәр мондый экспертизаны үткәрү федераль законнарда билгеләнсә | |
| 7. Объектны төзүче оешма, техник заказчысы, подрядчылары һәм проектлаучылары турында мәгълүмат | |
| 8. Төзелеше тәмамланмаган объектның әзерлек дәрәҗәсе турында белешмә, башкарылган эшләрне һәм төзелеш стадияләрен сурәтләп, башкарылган эшләр дәрәҗәсен күрсәтеп (процентларда), – түбәндәгеләр буенча:<br>– монолит;<br>– кирпеч өеме;<br>– уртак файдаланудагы урыннарны ясау;<br>– эчке челтәрләрне, тышкы челтәрләрне, вентиляцияне, тәрәзәләрне, лифтларны монтажлау;<br>– электр-монтаж эшләре;<br>– Объектны төзекләндерү | |

| | |
|---|---|
| 9. Төзүче оешманың өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча вазыйфаларын үтәвен раслаучы документлар (тапшыру акты яисә өлешле төзелеш актын тапшыру турында бүтән документ) | |
| 10. Проект декларациясе, төзүче оешма һәм төзелеш проекты турындагы мәгълүматларны үз эченә ала, үзгәрешләре белән, бастырып чыгару һәм (яисә) урнаштыру даталарын һәм чыганакларын күрсәтеп | Россия Төзелеш министрлыгының 996/пр боерыгы |
| 11. Өлешле төзелештә катнашучыларның 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 1-3 өлешләрендә күрсәтелгән мөлкәтне залогка тапшыруга ризалыгы, – залог төзүче оешма белән өлешле төзелештә катнашучының беренчесе белән шартнамә төзегәннән соң рәсмиләштерелгән очракта | |
| 12. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 1-3 өлешләрендә күрсәтелгән мөлкәтне залогта тотучы банкның 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 өлеше нигезендә залогка тапшырылган мөлкәт хисабына үз таләпләрен канәгатьләндерүгә ризалыгы һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 8 өлешендә каралган очракта өлешле төзелеш объектларына залог хокукын туктатуга ризалыгы | |
| 13. Өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре һәм (яисә) Объектны төзү өчен акча җәлеп итүгә нигез булган бүтән шартнамәләр, шулай ук аларны үзгәртүләр, өстәмәләр кертүләр, таркату турында килешүләр | |
| 14. Әҗәтне өлешле төзелешнең яңа катнашучысына күчерү һәм төзелеше тәмамланмаган объекттагы фатирларга гражданнар һәм юридик затлар мөлкәт хокукларын сатып алуга нигез булган таләпләр хокукын шартнамә буенча өлешле төзелештә катнашучы тарафыннан тапшыру | |
| 15. Алар кысасында Объект төзелеше гамәлгә ашырыла торган гади ширкәт шартнамәләре (уртак эшчәнлек турында шартнамәләр), инвестиция килешүләре | |
| 16. Объектны төзү (булдыру) өчен төзелгән һәм (яисә) төзүче оешманың гамәлдәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булган кредит шартнамәләре һәм займ шартнамәләре, шулай ук аларны үзгәртүләр, өстәмәләр кертү, таркату турында килешүләр | |
| 17. Төзүче оешма өчен банктан түләү җаваплылыгы | |
| 18. Төзелеш подряды, төзелеш материалларын китертү шартнамәләре, Объектны төзүгә | |

| | |
|---|---|
| (булдыруга) бәйле бүтән шартнамәләр | |
| 19. Төзелә (булдырыла) торган Объектларның реестрлары, өлешле төзелештә катнашучыларны (физик затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затларның аталышлары), шулай ук Объектның төзелеше тәмамланганнан соң (булдырылганнан соң) өлешле төзелештә катнашучыларга тапшырылачак фатирларның, торак өчен билгеләнмәгән урыннарның, парковка урыннарының санын һәм номерларын күрсәтеп | |
| 20. Өлешле төзелештә катнашу шартнамәләренең һәм (яисә) Объектны төзү (булдыру) өчен акча җәлеп итүгә нигез булган бүтән шартнамәләрнең (килешүләрнең) реестрлары, юридик затның аталышын, урнашкан урын адресын, салым түләүченең идентификация номерын, физик затның фамилиясен, исемен, атасының исемен һәм теркәүгә алыну адресын, шартнамәне имзалау һәм дәүләт теркәвенә алу датасын, һәр шартнамәнең суммасын, шартнамә буенча акча килү датасын, шартнамәне таркату фактын күрсәтеп | |
| 21. Өлешле төзелештә катнашу буенча таркатылган шартнамәләрнең һәм (яисә) Объектны төзү (булдыру) өчен акча җәлеп итүгә нигез булган, таркатылган бүтән шартнамәләрнең (килешүләрнең) реестрлары, таркату сәбәпләрен күрсәтеп | |
| 22. Төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучыларга җибәрелгән, шартнамәдә каралган чорда төзелешне тәмамлау мөмкинлегенең булмавы турында һәм шартнамә шартларын үзгәртү турында хәбәрләре (почтадан җибәрүне раслап) | |
| 23. Өлешле төзелештә катнашу шартнамәләрен һәм (яисә) Объектны төзү (булдыру) өчен акча җәлеп итүгә нигез булган бүтән шартнамәләрне үтәүдән бер яклы тәртиптә баш тарту турында хәбәрләр (аның почта аша җибәрелгәнлеген раслап) | |
| 24. Исәпкә алу сәясәте турында боерык, шул исәптән төзүче оешманың финанс-хуҗалык эшчәнлеген исәпкә алу буенча синтетик һәм аналитик счетларны һәм субсчетларны үз эченә алган бухгалтерия исәбе счетларының эш планнары | |
| 25. Төзелешкә рөхсәт алган вакыттан башлап хисап чорлары өчен (алга таба – квартал өчен, ел өчен) юридик затның бухгалтерия хисаплылыгы (бухгалтерия балансы, табышлар һәм сарыфлар турында хисап, капитал үзгәрүләре турында хисап, акча хәрәкәте турында хисап, бухгалтерия балансына бүтән кушымталар) | |

| | |
|---|---|
| 26. Бухгалтерия хисаплылыгының төгәл булуын раслаучы аудитор бәяләмәсе (төзүче оешма тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырылган хисап чорлары өчен) | |
| 27. Өлешле төзелешнең һәр объекты буенча хисап чорлары өчен бухгалтерия балансы статьяларына аңлатма | |
| 28. Бухгалтерлык исәбе документлары турында мәгълүмат, төзүче оешма тарафыннан РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзүче оешмалар тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзелеш проектларын һәм шартнамәләр буенча үз йөкләмәләрен, төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеген гамәлгә ашыруның якынча графикларын үтәү турында хисаплылык формасын һәм контрольдә тотучы органга тапшыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгы белән расланган форма буенча өлешле төзелештә катнашучылардан җәлеп ителгән акчаларны файдалану турындагы графаларны тутыруга нигез булган бухгалтерлык исәбе һәм бухгалтерлык хисаплылыгы белешмәләре | |
| 29. Объектларны өлешле төзүгә акча җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашырганда финанс-хуҗалык операцияләрен исәпкә алуга бәйле бухгалтерия исәбе регистрлары: журнал-ордерлар, счетларның карточкалары, субсчетлар, субконто (төзелеш объектлары буенча), Объектларны өлешле төзүдә катнашучылар буенча (76, 86, 08, 60 счетлары буенча) әйләнешле-сальдо исемлекләре (аналитика исәбе) һәм 50, 51, 76, 86, 08, 60 счетларының карточкалары, шулай ук өлешле төзелештә катнашучыларның акчасы белән эш итүгә бәйле бүтән счетлар | |
| 30. Касса кенәгәсе, хисап чорлары өчен керем һәм чыгым касса ордерлары | |
| 31. Хисап чорлары өчен КМ-6 номерлы рәвештә кассир-операцияләрне башкаручының белешмә-хисаплары | |
| 32. Акчаларның банк счетлары буенча хәрәкәте турында өземтәләр, хисап чорлары өчен түләү йөкләмәләре | |
| 33. Капиталь төзелештә эшләрне исәпкә алу буенча беренчел исәпкә алу документациясе | |
| 34. Төзелеш материалларын китертүгә накладнаялар, төзелеш материалларын гамәлдән чыгару актлары | |

| | |
|---|---|
| 35. КС-6 номерлы рәвештә эшләрнең гомуми журналы | |
| 36. Өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре һәм (яисә) Объектны төзү (булдыру) өчен акча җәлеп итүгә нигез булган бүтән шартнамәләр (килешүләр) буенча хисап чоры азагына өлешле төзелештә катнашучыларның дебитор бурычы күләмен күрсәтеп, квартал саен тапшырыла торган белешмә | |
| 37. Өлешле төзелеш Объектын һәм/яисә Объект төзелеше өчен бүленгән җир кишәрлеген залогка тапшырып җәлеп ителгән кредит (заем) акчаларының күләмен күрсәтеп | |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ҮТӘҮ ВАКЫТЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

5.1. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

планнан тыш документар тикшерү үткәрү, зарури таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын бетерү буенча чаралар күрү;

урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү, зарури таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын бетерү буенча чаралар күрү;

торак-төзелеш кооперативларына тикшерүләр уздыруны планлаштыру;

торак-төзелеш кооперативына планлы документар тикшерү үткәрү;

торак-төзелеш кооперативына урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү;

күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында квартал саен тапшырылучы хисаплылыкны тикшерү;

төзүче оешма, торак-төзелеш кооперативы белән бәйләнешкә кермичә зарури таләпләр үтәлешен тикшерүдә тоту буенча чараларны (алга таба шулай ук – юридик зат белән бәйләнешкә кермичә тикшерүдә тоту чарасы) оештыру һәм үткәрү.

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның блок-схемасы әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелә.

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда рөхсәт ителә.

### «ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ, ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕ БОЗУНЫҢ АЧЫКЛАНГАН ОЧРАКЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.2. «Планнан тыш документар тикшерү үткәрү, зарури таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасын башлау өчен нигез булып әлеге Регламентның 2.12 пунктының 1, 3, 5, 6 пунктчаларында, 2.14 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

Әгәр юридик зат тарафыннан зарури таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракларны юкка чыгару турында күрсәтмәне үтәү вакыты узу планнан тыш тикшерүне уздыру өчен нигез булып торса, ул очракта мондый тикшерүнең предметы булып бары тик Инспекция биргән күрсәтмә үтәлеше генә тора ала.

5.3. «Планнан тыш документар тикшерү үткәрү, зарури таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасы гамәлләрнең түбәндәге тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла:

җаваплы башкарчыны билгеләү;

зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләрендә гражданнарның яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау (планнан тыш тикшерү нигезе булып әлеге Регламентның 2.12 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез хезмәт итсә);

тикшерү уздыру турында күрсәтмә (боерык) рәсмиләштерү;

юридик затка тикшерү уздыру турында хәбәр итү;

тикшерүне үткәрү;

тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү һәм зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү.

## ҖАВАПЛЫ БАШКАРЧЫНЫ БИЛГЕЛӘҮ

5.4. Бүлек башлыгы зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләрендә гражданнарның яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен (планнан тыш тикшерү нигезе булып әлеге Регламентның 2.12 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез хезмәт итсә) карау, мөрәҗәгатькә җавап проектын әзерләү, тикшерү уздыру, юридик затка тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) проектын әзерләү өчен Бүлек хезмәткәрләре арасыннан җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 2.12 пунктының 1, 3, 5, 6 пунктчаларында, 2.14 пунктында күрсәтелгән очраклар башланган көнне яки әлеге очраклар башланган көннән соңгы бер эш көне эчендә (йөкләү срокларын исәпкә алып).

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) проектын әзерләү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы ачыклау.

## ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕ ҮТӘҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЕНЧА МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРНЕ ЯКИ ГАРИЗАЛАРНЫ КАРАУ

5.5. Инспекциягә гражданнар тарафыннан, шул исәптән шәхси эшкуарлар, юридик затлар тарафыннан, җибәрелгән, әлеге Регламентның 2.12 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләрне үз эченә алганмөрәҗәгатьләр яки гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.2 статьясының 1

өлешендә күрсәтелгән коммерциясез оешмадан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән килгән мәгълүмат (алга таба тиешенчә – мөрәҗәгатьләр яки гаризалар; мөрәҗәгать итүчеләр) планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып хезмәт итә ала.

5.6. Әлеге Регламентның 5.5 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать яисә гариза 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә карала.

5.7. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар аларның мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан мөрәҗәгать итүченең Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында зарури авторлаштырылган булуын күздә тотучы мәгълүмати-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булу шарты белән генә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә ала.

5.8. Зарури таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, зарури таләпләрне бозу турында җитәрлек мәгълүматлар булмаганда, җаваплы башкаручы кергән мәгълүматка алдан тикшерү уздырырга мөмкин.

5.9. Алдан тикшерү үткәрү барышында җаваплы башкаручы:

мөрәҗәгать, гариза җибәргән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу нигезендә чаралар күрә;

Инспекция карамагында булган, үзенә карата белешмәләр алынган затның документларын тикшерә;

зарурлык булган очракта Инспекция башлыгы белән килештереп үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлар белән бәйләнешкә кермичә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат тапшыру йөкләмәсен йөкләмичә гамәлгә ашырыла торган зарури таләпләр үтәлеше буенча контрольлек чараларын уздыра.

5.10. Беренчел тикшерү кысаларында үзләренә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затлардан алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратылырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка төрле документларны тапшыру мәҗбүри булып саналмый.

5.11. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча зарури таләпләр бозылуга юл куйган затларны ачыклаганда, зарури таләпләрнең бозылуы турында җитәрлек белешмәләр алынганда җаваплы башкаручы планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилләнгән йогынты актын әзерли. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшмәкәрне җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

Планнан тыш тикшерүне билгеләү турында дәлилләнгән йогынты акты Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) җибәрелә. Әлеге Регламентның 2.12 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы карар Инспекция башлыгы (башлыгы урынбасары) тарафыннан кабул ителә.

5.12. Әгәр алдан тикшерү башланганнан соң аны оештыру нигезе булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада булган мәгълүматларның белә торып ялган булуы билгеләнсә Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) карары буенча алдан тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

5.13. Җаваплы башкаручы билгеләнгән вакытта мөрәҗәгатькә, гаризага җавап

әзерли, аны Инспекция башлыгыннан (башлык урынбасарыннан) имзалата.

5.14. Мөрәҗәгатькә яки гаризага җавап мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язмача формада яисә, мөрәҗәгать электрон формада кергән очракта, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ формасында җибәрелә.

## ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.15. Җаваплы башкаручы:

юридик затка тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасарының) күрсәтмәсе (боерыгы) проектын әзерли;

күрсәтмә (боерык) проектын имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Күрсәтмә (боерык) Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган үрнәк рәвешенә туры китереп рәсмиләштерелә.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерү уздыру турында йөкләмә алынган көнне яисә аннан соңгы бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзаланган күрсәтмә (боерык).

## ЮРИДИК ЗАТКА ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.16. Юридик затка планнан тыш документар тикшерү уздыру турында хәбәр итү шушы Регламентның 5.34 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ

5.17. Планнан тыш тикшерү Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) нигезендә үткәрелә.

Тикшерү бары тик күрсәтмәдә (боерыкта) күрсәтелгән вазыйфаи зат яисә вазыйфаи затлар тарафыннан гына уздырыла ала.

Планнан тыш документар тикшерү Инспекциянең урнашу урыны буенча үткәрелә.

5.18. Боерык күчермәсен алганнан соң ун эш көне эчендә юридик зат тикшерү уздыру турында күрсәтмәдә (боерыкта) күрсәтелгән документларны Инспекциягә җибәрергә тиеш.

Документар тикшерүне уздырганда юридик заттан документар тикшерү предметына карамаган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) бүтән органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итү рөхсәт ителми.

Әгәр дә Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, Инспекциягә тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхәт ителми.

5.19. Документар тикшерүне уздырганда җаваплы башкаручы тарафыннан иң беренче нәүбәттә юридик затның Инспекция карамагында булган документлары, шул исәптән алдагы тикшерүләрнең актлары, административ хокук бозулар турында эшләрне карау материаллары һәм әлеге юридик затка карата гамәлгә ашырылган дәүләт контроле (күзәтчелеге) нәтиҗәләре турында бүтән документлар карала.

Җаваплы башкаручы:

белешмәләрнең төгәл булу-булмавына бәя бирә;

документлардагы белешмәләрне юридик зат эшчәнлегенең билгеләнгән зарури таләпләргә туры килүе предметына бәяли;

зарурлык очрагында ведомствоара хезмәттәшлек ярдәмендә белешмәләр ала.

Әгәр документар тикшерү барышында юридик зат тарафыннан тапшырылган документларда хаталар булуы һәм (яисә) каршылыклар, яисә бу документларда булган мәгълүматларның Инспекция карамагында булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәве ачыкланса, җаваплы башкаручы:

бу хакта мәгълүмат белән һәм ун эш көне эчендә язмача рәвештә кирәкле аңлатмаларны тапшыруны таләп итеп, юридик затка хат әзерли;

хатны имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый;

имзаланганнан соң хатны юридик зат адресына кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп яисә үтемле башка ысул белән җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерүне уздыра башлаган көннән соң яисә юридик заттан аңлатмалар алган көннән соң биш эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: язмача рәвештә барлык кирәкле аңлатмаларны тапшыру таләбе белән юридик затка кулга тапшыру тамгасы белән заказлы хат итеп җибәрелгән хат.

Җаваплы башкаручы тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) кабул ителгәннән соң үзенә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган заттан шушы Регламентның 4 бүлегендә күрсәтелгән зарури документларны һәм (яисә) мәгълүматларны соратырга хокуклы.

Зарурлык булганда җаваплы башкаручы, шул исәптән электрон рәвештә, әлеге Регламентка 5 нче кушымтада күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә сората һәм ала.

Җаваплы башкаручы юридик затның җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштыра.

Салым серен яисә закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән торучы документларны һәм (яисә) мәгълүматларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорату тиешле белешмәләрне тикшерүнең

юридик затлар тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлү фактын билгеләү зарурлыгы белән аңлатылган һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру федераль законда каралган булу шарты белән рөхсәт ителә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яисә) мәгълүматларны бирү, аларны ачу, шул исәптән, 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда, алар белән таныштыру Россия Федерациясенең дәүләт сере һәм законда саклана торган бүтән сер турында законнарындагы таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

5.20. Нигезләнгән гарызнамә алынган көннән башлап ун эш көне эчендә юридик зат гарызнамәдә күрсәтелгән документларны Инспекциягә җибәрергә тиеш.

Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм юридик зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Юридик зат гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

5.21. Юридик заттан тапшырылган документлардагы кисәтүләргә карата аңлатмаларны карау түбәндәге рәвешле гамәлгә ашырыла.

Инспекциягә тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата яисә бу документларда булган белешмәләрнең Инспекция карамагындагы документларның белешмәләренә туры килмәвенә карата аңлатмалар тапшыручы юридик затлар Инспекциягә элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслый торган документларны өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы.

Элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслаучы аңлатмалар һәм (яисә) документлар алынганнан соң җаваплы башкаручы юридик зат тарафыннан тапшырылган, элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслаучы аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карый.

Әгәр дә тапшырылган, элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслаучы аңлатмаларны һәм (яки) документларны карап тикшергәннән соң яисә аңлатмалар булмаган очракта җаваплы башкаручы мәҗбүри таләпләрнең бозылу билгеләрен ачыкласа, Бүлекнең вазыйфаи затлары урынга чыгып тикшерү үткәрергә хокуклы. Урынга чыгып тикшерү үткәргәндә юридик заттан документар тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела. Урынга чыгып тикшерү үткәрү зарурлыгы турында карарны Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) кабул итә.

Үтәү вакыты: аңлатмаларны алганнан соң өч эш көне дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: җаваплы башкаручы тарафыннан каралган юридик зат тапшырган аңлатмалар һәм (яисә) документлар; урынга чыгып тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) проекты (зарурлык булганда).

## ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ, ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.22. Җаваплы башкаручы юридик зат документларындагы белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре нигезендә ике нөсхәдә тикшерү актын төзи, аның типик рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Контрольлек чаралары нәтиҗәсендә зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы законнарны үтәүне (ачыкланган бозулар нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплауга) тәэмин итүгә юнәлдерелгән түбәндәге вәкаләтләрнең тормышка ашырылуын гамәлгә ашыра:

тикшерү актында ачыкланган бозуларның барлык очракларын да терки;

әлеге җитешсезлекләрне бетерү срокларын күрсәтеп, юридик затка зарури таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә әзерли.

Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең типик рәвеше шушы Регламентның 2 нче кушымтасында китерелде.

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 13.19.2 статьясының 1 өлешендә (күпфатирлы йортлар төзүне гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 13.19.3 статьясында (төзүче оешма, төзүче оешманың вазыйфаи затлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 14.28 статьясының 1-5 өлешләрендә, 14.28.1 статьясында һәм 19.5 статьясының 4 өлешендә каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи зат административ хокук бозулар турында эшләр кузгата һәм билгеләнгән тәртиптә аларның каралуын тәэмин итә, административ җәза билгели һәм куллана.

Административ хокук бозу турында беркетмәнең типлаштырылган формасы әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелә.

Административ хокук бозу турында беркетмәгә имза салу процедурасыннан соң җаваплы башкаручы аның күчермәсен үзенә карата беркетмә төзелгән юридик зат җитәкчесенә, юридик затның бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшыра.

Тикшерүдә тоту чарасы барышында тикшерүдә тоту буенча чара уздыру объекты булып торган хуҗалык яисә бүтән эшчәнлекнең законнардагы таләпләрне бозуга бәйле икәнлеге ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм чикләү мәсьәләләре Инспекция компетенциясенә карамаса, Инспекция мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрергә бурычлы.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталары белән бергә) җаваплы башкаручы эшкә куша, икенчесен (кушымталары белән бергә) юридик зат җитәкчесенә, юридик затның бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә танышып чыгу турында яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында имзалатып тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тартуы турында имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерүнамә Инспекция эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә

теркәлә. Тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты:

тикшерү актын төзү һәм кушымталары белән бергә тапшыру, тикшерү актын почта аша заказлы хат итеп җибәрү яисә электрон документ рәвешендә, – турыдан-туры тикшерү тәмамлангач;

административ хокук бозу турында беркетмә төзү – административ хокук бозуның кылынганлыгы ачыклану белән кичекмәстән;

эш хәлләрен яисә үзләренә карата административ хокук бозу турында эш кузгатыла торган физик зат турында белешмәләрне яки юридик зат турында белешмәләрне өстәмә ачыклау таләп ителгәндә, административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозуны ачыклау вакытыннан башлап ике тәүлек дәвамында төзелә.

Гамәлнең нәтиҗәсе:

ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, кушымталары белән, берсе юридик затка тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә теркәп куелган;

зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта:

тикшерү актына кушымта булган күрсәтмә;

административ хокук бозу турында беркетмә.

5.23. Күрсәтмәне билгеләнгән чорда үтәүне тикшереп торуны Инспекциянең күрсәтмәдә күрсәтелгән вазыйфаи заты тәэмин итә.

Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп тору җаваплылыгы йөкләнгән вазыйфаи зат күрсәтмәнең үтәлү чоры тәмамланган көннән соңгы көннән соңга калмыйча Бүлек башлыгына күрсәтмәне үтәү вакытының бетүе турында хәбәр итәргә һәм Инспекция күрсәтмәсенең үтәлүе предметына карата планнан тыш тикшерү уздыруны оештыру һәм уздыру буенча тәкъдимнәр җиткерергә бурычлы.

5.24. Инспекция төзүче оешманың күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыруны билгеле бер чорга туктатып тору турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы, түбәндәге очракларда:

1) 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хисаплылыкны тапшыру утыз көннән артык чорга тоткарланганда;

2) төзүче оешма тарафыннан аның эшчәнлегендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән финанс тотрыклылыгы нормативлары сакланмаганда;

3) төзүче оешма 214-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясының 1 өлешендә каралган акча йөкләмәләре буенча өлешле төзелештә катнашучыларның таләпләрен һәм (яисә) өлешле төзелеш объектын тапшыру вазыйфасын, мондый

таләпләрне канәгатьләндерү һәм (яисә) мондый вазыйфаны үтәү көне башланганнан соң өч ай дәвамында, канәгатьләндермәгәндә һәм (яисә) үтәмәгәндә. Бу вакытта күрсәтелгән таләпләр җыеп алганда кимендә 100 мең сум тәшкил итәргә тиеш;

4) төзүче оешма тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль закон, шулай ук аның нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлар таләпләре үтәлмәде, әгәр төзүче оешмага бер ел дәвамында 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган йогынты чаралары ике һәм аннан күбрәк тапкыр кулланылган булса;

5) төзүче оешма тарафыннан Инспекциягә тапшырылган проект декларациясендә төзүче оешманың 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында төзүче оешма тарафыннан белә торып төгәл булмаган белешмәләр декларацияләнгәндә;

6) Инспекция тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелгән көннән соң өч ай узып киткәч төзүче тарафыннан мондый таләпләрне бозулар бетерелмәгәндә.

5.25. Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Инспекция билгеләгән чорда ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта, шулай ук мондый бозулар торак-төзелеш кооператив әгзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә чын куркыныч тудырганда, Инспекция торак-төзелеш кооперативы тиешле бозуларны бетергәнчегә кадәр кооперативның яңа әгъзаларын җәлеп итү буенча торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген туктатып тору турында күрсәтмә чыгарырга хокуклы.

Инспекция аның күрсәтмәләре торак-төзелеш кооператив тарафыннан үтәлмәгән очракта бу кооперативны ликвидацияләү турында таләп итеп судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.26. Үзенә карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Инспекциягә тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Инспекциягә тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Инспекция күрсәтмәсе җибәрелгән, төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат күрсәтелгән күрсәтмә җибәрелгән көннән соң өч ай дәвамында күрсәтелгән күрсәтмәне законсыз дип тану турында билгеләнгән тәртиптә гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Арбитраж судына күрсәтелгән күрсәтмәне законсыз дип тану турында гариза белән мөрәҗәгать итү аның үтәлүен туктатмый. Мондый гариза белән мөрәҗәгать итү тәртибе, аны карау тәртибе һәм күрсәтмәне законсыз дип тану турында гариза буенча карар кабул итү тәртибе арбитраж судларында суд эшен башкару турындагы законнарда билгеләнә.

5.27. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тикшерү нәтиҗәләре турындагы, шул исәптән бирелгән күрсәтмәләр турындагы тиешле мәгълүматларның һәм административ җаваплылыкка тарту турындагы белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә урнаштырылуын оештыра:

294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында һәм РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда тикшерүләрнең бердәм реестрында;

214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясындагы 5 өлеше нигезендә бердәм мәгълүмат системасында;

ТР Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында;

«Интернет» челтәрендә Инспекциянең рәсми сайтында.

## «УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ, ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕ БОЗУНЫҢ АЧЫКЛАНГАН ОЧРАКЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.28. «Урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү, зарури таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен әлеге Регламентның 2.12, 2.14 пунктларында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора, әгәр планнан тыш документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаса:

1) Инспекция карамагында булган юридик зат документларындагы белеәмәләрнең тулы һәм төгәл булуына ышану;

2) юридик зат эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

Әгәр юридик зат тарафыннан зарури таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракларны юкка чыгару турында күрсәтмәне үтәү вакыты узу планнан тыш тикшерүне уздыру өчен нигез булып торса, ул очракта мондый тикшерүнең предметы булып бары тик Инспекция биргән күрсәтмә үтәлеше генә тора ала.

5.29. «Урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү, зарури таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.3 пунктында күрсәтелгән гамәлләр тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

## ҖАВАПЛЫ БАШКАРЧЫНЫ БИЛГЕЛӘҮ

5.30. Бүлек башлыгы, әлеге Регламентның 2.12, 2.14 пунктларында күрсәтелгән очраклар башланган очракта, зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләрендә гражданнарның яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен (планнан тыш тикшерү нигезе булып әлеге Регламентның 2.12 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез хезмәт итсә) карау, мөрәҗәгатькә җавап проектын әзерләү, тикшерү уздыру, юридик затка тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары)

күрсәтмәсе (боерыгы) проектын әзерләү өчен Бүлек хезмәткәрләре арасыннан җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 2.12, 2.14 пунктларында күрсәтелгән очраклар башланган көнне яисә аннан соңгы бер эш көне эчендә (йөкләмә срокларын исәпкә алып).

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) проектын әзерләү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы ачыклау.

## ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕ ҮТӘҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЕНЧА ГРАЖДАННАРНЫҢ ЯКИ ОЕШМАЛАРНЫҢ МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРЕН КАРАУ

5.31. Әгәр әлеге Регламентның 2.12 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру нигезе була алса, җаваплы башкаручы мөрәҗәгатьне яки гаризаны әлеге Регламентның 5.5-5.14 пунктлары нигезендә карый.

## УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.32. Җаваплы башкаручы:

юридик затка тикшерү уздыру турында күрсәтмә (боерык) проекты әзерли;

күрсәтмә (боерык) проектын имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Күрсәтмә (боерык) Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган типик рәвешкә туры китереп рәсмиләштерелә.

Үтәү вакыты: урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру турында йөкләмә алынган көнне яисә аннан соңгы бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзаланган күрсәтмә (боерык).

5.33. Әгәр төзүче оешмага карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) планнан тыш тикшерү уздыру турында әлеге Регламентның 2.12 пунктындагы 1, 2, 4, 5, 6 пунктчалары нигезендә чыгарылган күрсәтмәсе (боерыгы) торса, Инспекция 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 6 һәм 7 өлешләрендә каралган документларны прокуратура органнарына егерме дүрт сәгать эчендә җибәреп, контрольлек чарасын уздыру турында прокуратура органнарына хәбәр итеп, кичекмәстән планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруга керешергә хокуклы.

## ЮРИДИК ЗАТКА УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.34. Җаваплы башкаручы юридик затка планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәреләчәге турында (әлеге Регламентның 2.12 пунктындагы 1, 2, 4, 5, 6 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелә торган планнан тыш урынга

чыгып тикшерүләрдән кала), теләсә нинди үтемле ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә хәбәр итә, әгәр дә мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә элегрәк юридик зат тарафыннан Инспекциягә тапшырылган булса.

Үтәү вакыты: юридик зат тикшерүне үткәрә башларга кимендә егерме дүрт сәгать калганчыга кадәр хәбәр алырга тиеш.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка җибәрелгән, тикшерү уздыру турында күрсәтмә (боерык) күчермәсе.

## УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ

5.35. Җаваплы башкаручы юридик затның объектына килеп җитү белән тикшерүне түбәндәгеләрдән башлый:

хезмәт таныклыгын күрсәтеп;

юридик зат җитәкчесенә яисә вазыйфаи затына, аның вәкаләтле вәкиленә танышу өчен Инспекциянең урынга чыгып планлы тикшерү уздыру турында күрсәтмәсен (боерыгын) күрсәтеп;

юридик зат җитәкчесенә яисә вазыйфаи затына, аның вәкаләтле вәкиленә урынга чыгып тикшерү уздыручы затларның вәкаләтләре, шулай ук урынга чыгып уздырылган тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольлек чараларының төрләре һәм күләмнәре, урынга чыгып тикшерү уздыру өчен җәлеп ителүче экспертларның составы, эксперт оешмалары вәкилләре, аны уздыру вакытлары һәм шартлары белән мәҗбүри таныштырып.

Юридик зат җитәкчесенең яисә вазыйфаи затының, аның вәкаләтле вәкиленең гозере буенча җаваплы башкаручы тикшерелергә тиешле затларны шушы Регламент һәм эшчәнлеген гамәлгә ашырганда юридик зат тарафыннан файдаланыла торган объектларда контрольлек чараларын уздыру тәртибе белән таныштырырга бурычлы.

Җаваплы башкаручы юридик зат эшчәнлегенең шушы Регламентның 3 бүлегендә китерелгән таләпләргә җавап бирүен бәяли, шул исәптән түбәндәге контрольлек чараларын уздыра:

урынга чыгып тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлар белән таныша, әгәр дә урынга чыгып тикшерү уздыру өчен уздырылган документар тикшерү сәбәпче булса;

әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгәнзарури таләпләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра;

уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзи, тикшерүне уздырганда катнашкан юридик зат җитәкчесен, вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен аның белән таныштыра;

тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрә.

Үтәү вакыты: шушы Регламентның 2.10 пунктындагы таләпләргә туры китереп.

Гамәлнең нәтиҗәсе: контроль буенча үткәрелгән чаралар.

Зарурлык булганда, җаваплы башкаручы билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән электрон рәвештә бүтән дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларда булган, шушы Регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны сората һәм ала.

Салым серен яисә закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән торучы документларны һәм (яисә) мәгълүматларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорату тиешле белешмәләрне тикшерүнең юридик затлар тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлү фактын билгеләү зарурлыгы белән аңлатылган һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру федераль законда каралган булу шарты белән рөхсәт ителә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яисә) мәгълүматларны бирү, аларны ачу, шул исәптән, 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда, алар белән таныштыру Россия Федерациясенең дәүләт сере һәм законда саклана торган бүтән сер турында законнарындагы таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.36. Җаваплы башкаручы юридик зат документларындагы белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре нигезендә ике нөсхәдә тикшерү актын төзи, аның типик рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Контрольлек чаралары нәтиҗәсендә зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы законнарны үтәүне (ачыкланган бозулар нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплауга) тәэмин итүгә юнәлдерелгән түбәндәге вәкаләтләрнең тормышка ашырылуын гамәлгә ашыра:

тикшерү актында ачыкланган бозуларның барлык очракларын да терки;

әлеге җитешсезлекләрне бетерү срокларын күрсәтеп, юридик затка зарури таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә әзерли.

Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең типик рәвеше шушы Регламентның 2 нче кушымтасында китерелде.

Тикшерү актына түбәндәгеләр теркәлә:

зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмә;

юридик затның зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләренең аңлатмалару;

тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган бүтән документлар яисә аларның күчермәләре.

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 13.19.2 статьясының 1 өлешендә (күпфатирлы йортлар төзүне гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 13.19.3 статьясында (төзүче оешма, төзүче оешманың вазыйфаи затлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 14.28 статьясының 1-5 өлешләрендә, 14.28.1 статьясында һәм 19.5 статьясының 4 өлешендә каралган

административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи зат административ хокук бозулар турында эшләр кузгата һәм билгеләнгән тәртиптә аларның каралуын тәэмин итә, административ җәза билгели һәм куллана.

Административ хокук бозу турында беркетмәнең типлаштырылган формасы әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелә.

Административ хокук бозу турында беркетмәгә имза салу процедурасыннан соң җаваплы башкаручы аның күчермәсен үзенә карата беркетмә төзелгән юридик зат җитәкчесенә, юридик затның бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшыра.

Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең, экспертизаларның бәяләмәсен алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек чараларын тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артып китмәгән чорда төзелә һәм юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла яисә кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә һәм (яисә) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булган очракта), күрсәтелгән документның алынуын тәэмин итүче ысул белән җиткерелә. Бу вакытта кулга тапшыру турыда хәбәр һәм (яисә) күрсәтелгән документның алынуына бүтәнчә дәлилләмә тикшерү актының Инспекциядә саклана торган эштәге нөсхәсенә теркәп куела.

Тикшерүдә тоту чарасы барышында тикшерүдә тоту буенча чара уздыру объекты булып торган хуҗалык яисә бүтән эшчәнлекнең законнардагы таләпләрне бозуга бәйле икәнлеге ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм чикләү мәсьәләләре Инспекция компетенциясенә карамаса, Инспекция мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрергә бурычлы.

Зарури таләпләрне бозуның җинаять җәзасына тартырлык гамәл билгеләренә ия булган фактлары ачыкланган очракта, Инспекция җинаять эшләрен кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен мондый фактларны ачыклауга бәйле органнарны хокук саклау органнарына җибәрә.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталары белән бергә) җаваплы башкаручы эшкә куша, икенчесен (кушымталары белән бергә) юридик зат җитәкчесенә, юридик затның бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә танышып чыгу турында яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында имзалатып тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тартуы турында имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерүнамә Инспекция эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)

кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты:

тикшерү актын төзү һәм кушымталары белән бергә тапшыру, тикшерү актын почта аша заказлы хат итеп җибәрү яисә электрон документ рәвешендә, – турыдан-туры тикшерү тәмамлангач;

административ хокук бозу турында беркетмә төзү – административ хокук бозуның кылынганлыгы ачыклану белән кичекмәстән;

эш хәлләрен яисә үзләренә карата административ хокук бозу турында эш кузгатыла торган физик зат турында белешмәләрне яки юридик зат турында белешмәләрне өстәмә ачыклау таләп ителгәндә, административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозуны ачыклау вакытыннан башлап ике тәүлек дәвамында төзелә.

Гамәлнең нәтиҗәсе:

ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, кушымталары белән, берсе юридик затка тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә теркәп куелган;

зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта:

тикшерү актына кушымта булган күрсәтмә;

административ хокук бозу турында беркетмә.

5.37. Күрсәтмәне билгеләнгән чорда үтәүне тикшереп торуны Инспекциянең күрсәтмәдә күрсәтелгән вазыйфаи заты тәэмин итә.

Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп тору җаваплылыгы йөкләнгән вазыйфаи зат күрсәтмәнең үтәлү чоры тәмамланган көннән соңгы көннән соңга калмыйча Бүлек башлыгына күрсәтмәне үтәү вакытының бетүе турында хәбәр итәргә һәм Инспекция күрсәтмәсенең үтәлүе предметына карата планнан тыш тикшерү уздыруны оештыру һәм уздыру буенча тәкъдимнәр җиткерергә бурычлы.

5.38. Әлеге Регламентның 5.24 пунктында күрсәтелгән очракларда Инспекция төзүче оешманың күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыруны билгеле бер чорга туктатып тору турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.39. Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Инспекция билгеләгән чорда ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта, шулай ук мондый бозулар торак-төзелеш кооператив әгзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә чын куркыныч тудырганда, Инспекция торак-төзелеш кооперативы тиешле бозуларны бетергәнчегә кадәр кооперативның яңа әгъзаларын җәлеп итү буенча торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген туктатып тору турында күрсәтмә чыгарырга хокуклы.

Инспекция аның күрсәтмәләре торак-төзелеш кооператив тарафыннан үтәлмәгән очракта бу кооперативны ликвидацияләү турында таләп итеп судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.40. Әгәр юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының булмый торуы сәбәпле, яисә юридик затның фактта эшчәнлеге гамәлгә ашырылмавы сәбәпле, яисә юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавына китереп чыгарган башка гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, җаваплы башкаручы, тикшерүне уздыруның мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, аны уздыруның мөмкин булмавы хакында акт төзи. Моннан тыш, Инспекция тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында актны төзегән көннән башлап өч ай дәвамында мондый юридик затка карата, юридик затка алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү хакында карар кабул итәргә хокуклы.

5.41. Җаваплы башкаручы уздырылган тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язып куя, аны юридик зат РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгында билгеләнгән үрнәк рәвештә алып барырга хокуклы. Уздырылган тикшерү турындагы язуда дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне уздыра башлау һәм тәмамлау даталары, аны уздыру вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы турында белешмәләр була, шулай ук тикшерүне уздыручы вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары, аның яки аларның имзалары күрсәтелә.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы тегелгән, номерланган һәм юридик затның мөһере (мөһер булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш. Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда тикшерү актында тиешле язу теркәлә.

5.42. Үзенә карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Инспекциягә тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Инспекциягә тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Инспекция күрсәтмәсе җибәрелгән, төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат күрсәтелгән күрсәтмә җибәрелгән көннән соң өч ай дәвамында күрсәтелгән күрсәтмәне законсыз дип тану турында билгеләнгән тәртиптә гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Арбитраж судына күрсәтелгән күрсәтмәне законсыз дип тану турында гариза белән мөрәҗәгать итү аның үтәлүен туктатмый. Мондый гариза белән мөрәҗәгать итү тәртибе, аны карау тәртибе һәм күрсәтмәне законсыз дип тану турында гариза буенча карар кабул итү тәртибе арбитраж судларында суд эшен башкару турындагы законнарда билгеләнә.

5.43. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тикшерү нәтиҗәләре турындагы, шул исәптән бирелгән күрсәтмәләр турындагы тиешле мәгълүматларның һәм административ җаваплылыкка тарту турындагы белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә урнаштырылуын оештыра:

294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында һәм РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда тикшерүләрнең бердәм реестрында;

214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясындагы 5 өлеше нигезендә бердәм мәгълүмат системасында;

ТР Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында;

«Интернет» челтәрендә Инспекциянең рәсми сайтында.

## «ТОРАК-ТӨЗЕЛЕШ КООПЕРАТИВЛАРЫНА ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮНЕ ПЛАНЛАШТЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.44. «Торак-төзелеш кооперативларына тикшерүләр үткәрүне планлаштыру» административ процедурасын башлау өчен ел саен үткәрелә торган тикшерүләр планын әзерләү вакытының килеп җитүе нигез булып тора.

План Бүлек тарафыннан эшләнә.

Торак-төзелеш кооперативын планлы тикшерүне еллык планга кертү өчен әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

5.45. Бүлек башлыгы һәр ел саен төзелә торган Планны әзерләү өчен җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) билгели (алга таба – ел саен төзелә торган Планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы).

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан алда килүче елның 10 июненә кадәр.

5.46. План әзерләү буенча җаваплы башкаручы:

1) РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карарында билгеләнгән форма буенча ел саен төзелә торган План проектын төзи;

2) аны Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) белән килештерә;

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан соң килүче елның 20 августына кадәр;

3) ел саен төзелә торган План проектын карау өчен үзләренә карата планлы тикшерүләрне уздыру планлаштырыла торган торак-төзелеш кооперативларының урнашкан урыны буенча кәгазьдә (күчермәсен электрон формада теркәп) кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында прокуратура органына җибәрә;

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан алда килүче елның 1 сентябренә кадәр.

5.47. Ел саен төзелә торган Планнар РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карарында расланган үрнәк формага ярашлы рәвештә төзелә.

5.48. План әзерләү буенча җаваплы башкаручы прокуратура органнары

тәкъдимнәренең каралуын оештыра һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча прокуратура органнарына Инспекция башлыгы тарафыннан расланган ел саен төзелүче Планны җибәрә.

Үтәү вакыты: ел саен төзелә торган, расланган Планны прокуратура органнарына җибәрү – планлы тикшерүләрне уздыру елыннан алда килүче елның 1 ноябренә кадәр.

5.49. План әзерләү буенча җаваплы башкаручы расланган Планның Инспекциянең рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итә.

Үтәү вакыты: План расланган вакыттан башлап 5 эш көне эчендә.

5.50. РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карарында билгеләнгән очракларда, раслаучы документлар булганда, Планга үзгәрешләр кертү рөхсәт ителә.

Планга үзгәрешләр кертү Инспекция боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла. Кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр алар кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә кәгазьдә (күчермәсен электрон рәвештә теркәп) тиешле кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында билгеләнгән тәртиптә тиешле прокуратура органына җибәрелә, шулай ук үзгәрешләр кертелгән көннән соң 5 эш көне эчендә билгеләнгән тәртиптә Инспекциянең рәсми сайтында урнаштырыла.

## «ТОРАК-ТӨЗЕЛЕШ КООПЕРАТИВЫНА ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.51. Еллык План нигезендә планлы документар тикшерү уздыру чорларының килеп җитүе «Торак-төзелеш кооперативына планлы документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

5.52. «Торак-төзелеш кооперативына планлы документар тикшерү үткәрү» административ процедурасы гамәлләрнең түбәндәге тәртибе буенча башкарыла:

җаваплы башкаручыны билгеләү һәм тикшерү уздыру турында күрсәтмә (боерык) рәсмиләштерү;

торак-төзелеш кооперативына тикшерү үткәрү турында хәбәр итү;

тикшерүне үткәрү;

тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү һәм зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү.

## ҖАВАПЛЫ БАШКАРУЧЫНЫ БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.53. Бүлек башлыгы Бүлектәге вазыйфаи затлар арасыннан торак-төзелеш кооперативына карата тикшерү уздыру өчен җаваплы башкаручыны (алга таба – җаваплы башкаручы) билгели.

Үтәү вакыты: торак-төзелеш кооперативына тикшерү үткәрергә 10 эш көне кала.

Гамәлнең нәтиҗәсе: торак-төзелеш кооперативын тикшерү өчен җаваплы башкаручыны билгеләү.

5.54. Җаваплы башкаручы:

Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) юридик затка тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәсе (боерыгы) проектын әзерли;

күрсәтмә (боерык) проектын имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Күрсәтмә (боерык) Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган үрнәк рәвешенә туры китереп рәсмиләштерелә.

Үтәү вакыты: тикшерүне уздыра башлаганчыга кадәр биш эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзаланган күрсәтмә (боерык).

## ТОРАК-ТӨЗЕЛЕШ КООПЕРАТИВЫНА ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.55. Җаваплы башкаручы тикшерү уздыру турында торак-төзелеш кооперативына, планлы тикшерүне уздыра башлау турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) күчермәсен кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәреп һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булса яисә элегрәк юридик зат тарафыннан Инспекциягә тапшырылган булса, юридик затның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә яисә башка төрле ысул белән хәбәр итә.

Тикшерү уздыру турында торак-төзелеш кооперативы адресына хәбәр җибәрү Инспекциядә эш башкаруны алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: торак-төзелеш кооперативына юнәлдерелгән тикшерү үткәрү турында боерык (боерык) күчермәсе.

## ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ

5.56. Тикшерү Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) нигезендә үткәрелә.

Тикшерү бары тик күрсәтмәдә (боерыкта) күрсәтелгән вазыйфаи зат яисә вазыйфаи затлар тарафыннан гына уздырыла ала.

Документар тикшерү Инспекциянең урнашу урыны буенча үткәрелә.

5.57. Торак-төзелеш кооперативы боерык күчермәсен алганнан соң ун эш көне дәвамында тикшерү үткәрү турында күрсәтмәдә (боерыкта) күрсәтелгән документларны Инспекциягә җибәрергә тиеш.

Документар тикшерүне уздырганда торак-төзелеш кооперативыннан документар тикшерү предметына карамаган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) бүтән органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итү рөхсәт ителми.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, Инспекциягә тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.

5.58. Документар тикшерүне уздырганда җаваплы башкаручы тарафыннан иң беренче нәүбәттә торак-төзелеш кооперативының Инспекция карамагында булган документлары, шул исәптән алдагы тикшерүләрнең актлары, административ хокук бозулар турында эшләрне карау материаллары һәм әлеге юридик затка карата гамәлгә ашырылган дәүләт контроле (күзәтчелеге) нәтиҗәләре турында бүтән документлар карала.

Җаваплы башкаручы:

белешмәләрнең тулы булу-булмавына бәя бирә;

документлардагы белешмәләрне торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенең билгеләнгән зарури таләпләргә туры килүе предметына бәяли;

зарурлык очрагында ведомствоара хезмәттәшлек ярдәмендә белешмәләр ала.

Әгәр документар тикшерү барышында юридик зат тарафыннан тапшырылган документларда хаталар булуы һәм (яисә) каршылыклар, яисә бу документларда булган мәгълүматларның Инспекция карамагында булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәве ачыкланса, җаваплы башкаручы:

торак-төзелеш кооперативына бу хакта мәгълүмат һәм ун эш көне дәвамында кирәкле аңлатмаларны язмача бирү таләбе белән хат әзерли;

хатны имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый;

имзаланганнан соң хатны торак-төзелеш кооперативы адресына кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп яисә үтемле башка ысул белән җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерүне уздыра башлаган көннән соң яисә торак-төзелеш кооперативыннан аңлатмалар алган көннән соң биш эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: язмача рәвештә барлык кирәкле аңлатмаларны тапшыру таләбе белән торак-төзелеш кооперативына кулга тапшыру тамгасы белән заказлы хат итеп җибәрелгән хат.

Җаваплы башкаручы тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) кабул ителгәннән соң үзенә карата дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган заттан шушы Регламентның 4 бүлегендә күрсәтелгән зарури документларны һәм (яисә) мәгълүматларны соратырга хокуклы.

Зарурлык булганда җаваплы башкаручы, шул исәптән электрон рәвештә, әлеге Регламентка 5 нче кушымтада күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә сората һәм ала.

Җаваплы башкаручы торак-төзелеш кооперативы җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштыра.

Салым серен яисә закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән торучы документларны һәм (яисә) мәгълүматларны ведомствоара

мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорату тиешле белешмәләрне тикшерүнең юридик затлар тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлү фактын билгеләү зарурлыгы белән аңлатылган һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру федераль законда каралган булу шарты белән рөхсәт ителә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яисә) мәгълүматларны бирү, аларны ачу, шул исәптән, 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда, алар белән таныштыру Россия Федерациясенең дәүләт сере һәм законда саклана торган бүтән сер турында законнарындагы таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

5.59. Нигезләнгән гарызнамә алынган көннән башлап ун эш көне эчендә торак-төзелеш кооперативы гарызнамәдә күрсәтелгән документларны Инспекциягә җибәрергә тиеш.

Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм торак-төзелеш кооперативы җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Торак-төзелеш кооперативы гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

5.60. Торак-төзелеш кооперативы тапшырган документлардагы кисәтүләргә карата аңлатмаларны карау түбәндәге рәвешле гамәлгә ашырыла.

Инспекциягә тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата яисә бу документларда булган белешмәләрнең Инспекция карамагындагы документларның белешмәләренә туры килмәвенә карата аңлатмалар тапшыручы торак-төзелеш кооперативы Инспекциягә элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслый торган документларны өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы.

Элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслаучы аңлатмалар һәм (яисә) документлар алынганнан соң җаваплы башкаручы торак-төзелеш кооперативы тарафыннан тапшырылган, элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслаучы аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карый.

Әгәр тапшырылган, элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслаучы аңлатмаларны һәм (яки) документларны карап тикшергәннән соң яисә аңлатмалар булмаган очракта җаваплы башкаручы мәҗбүри таләпләрнең бозылу билгеләрен ачыкласа, Бүлекнең вазыйфаи затлары урынга чыгып тикшерү үткәрергә хокуклы. Урынга чыгып тикшерү үткәргәндә торак-төзелеш кооперативыннан документар тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела. Урынга чыгып тикшерү үткәрү зарурлыгы турында карарны Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) кабул итә.

Үтәү вакыты: аңлатмаларны алганнан соң өч эш көне дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: җаваплы башкаручы тарафыннан каралган торак-төзелеш кооперативы тапшырган аңлатмалар һәм (яисә) документлар; урынга чыгып тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) проекты (зарурлык булганда).

Урынга чыгып тикшерү (аны үткәрү турында карар кабул ителгәндә) әлеге Регламентның «Торак-төзелеш кооперативына карата урынга чыгып планлы тикшерү уздыру» административ процедурасы» бүлекчәсендә күрсәтелгән тәртипкә

туры китереп гамәлгә ашырыла.

## ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.61. Җаваплы башкаручы юридик зат документларындагы белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре нигезендә ике нөсхәдә тикшерү актын төзи, аның типик рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

Контрольлек чаралары нәтиҗәсендә зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы законнарны үтәүне (ачыкланган бозулар нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплауга) тәэмин итүгә юнәлдерелгән түбәндәге вәкаләтләрнең тормышка ашырылуын гамәлгә ашыра:

тикшерү актында ачыкланган бозуларның барлык очракларын да терки;

зарури таләпләр бозылуны бетерү турында торак-төзелеш кооперативына кисәтү бирә һәм әлеге бозуларны бетерү срокларын билгели;

торак-төзелеш кооперативына үтәү өчен мәҗбүри булган зарури таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр җибәрә һәм мондый бозуларны бетерү срокларын билгели;

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 13.19.2 статьясының 1 өлешендә (күпфатирлы йортлар төзүче торак-төзелеш кооперативы кылган административ хокук бозулар өлешендә), 14.28.1 статьясында һәм 19.5 статьясының 4 өлешендә каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда административ хокук бозулар турында эшләр кузгата һәм билгеләнгән тәртиптә аларның каралуын тәэмин итә, административ җәза билгели һәм куллана.

Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең типик рәвеше шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

Административ хокук бозу турында беркетмәгә имза салу процедурасыннан соң җаваплы башкаручы аның күчермәсен үзенә карата беркетмә төзелгән юридик зат җитәкчесенә, юридик затның бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшыра.

Тикшерүдә тоту чарасы барышында тикшерүдә тоту буенча чара уздыру объекты булып торган хуҗалык яисә бүтән эшчәнлекнең законнардагы таләпләрне бозуга бәйле икәнлеге ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм чикләү мәсьәләләре Инспекция компетенциясенә карамаса, Инспекция мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрергә бурычлы.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталары белән бергә) җаваплы башкаручы эшкә куша, икенчесен (кушымталары белән бергә) торак-төзелеш кооперативы җитәкчесенә, аның бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә танышып чыгу турында яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында имзалатып тапшыра.

Торак-төзелеш кооперативының җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү

акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тартуы турында имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерүнамә Инспекция эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты:

тикшерү актын төзү һәм кушымталары белән бергә тапшыру, тикшерү актын почта аша заказлы хат итеп җибәрү, яисә электрон документ рәвешендә, – турыдан-туры тикшерү тәмамлангач;

административ хокук бозу турында беркетмә төзү – административ хокук бозуның кылынганлыгы ачыклану белән кичекмәстән;

эш хәлләрен яисә үзләренә карата административ хокук бозу турында эш кузгатыла торган физик зат турында белешмәләрне яки торак-төзелеш кооперативы турында белешмәләрне өстәмә ачыклау таләп ителгәндә, административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозуны ачыклау вакытыннан башлап ике тәүлек дәвамында төзелә.

Гамәлнең нәтиҗәсе:

ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, кушымталары белән, берсе торак-төзелеш кооперативына тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә теркәп куелган;

зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта:

тикшерү актына кушымта булган күрсәтмә;

административ хокук бозу турында беркетмә.

5.62. Күрсәтмәне билгеләнгән чорда үтәүне тикшереп торуны Инспекциянең күрсәтмәдә күрсәтелгән вазыйфаи заты тәэмин итә.

Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп тору җаваплылыгы йөкләнгән вазыйфаи зат күрсәтмәнең үтәлү чоры тәмамланган көннән соңгы көннән соңга калмыйча Бүлек башлыгына күрсәтмәне үтәү вакытының бетүе турында хәбәр итәргә һәм Инспекция күрсәтмәсенең үтәлүе предметына карата планнан тыш тикшерү уздыруны оештыру һәм уздыру буенча тәкъдимнәр җиткерергә бурычлы.

5.63. Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Инспекция билгеләгән чорда ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта, шулай ук мондый бозулар торак-төзелеш кооператив әгзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә чын куркыныч тудырганда, Инспекция торак-төзелеш кооперативы тиешле бозуларны бетергәнчегә кадәр кооперативның яңа әгъзаларын җәлеп итү буенча торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген туктатып тору турында күрсәтмә чыгарырга хокуклы.

Инспекция аның күрсәтмәләре торак-төзелеш кооператив тарафыннан үтәлмәгән очракта бу кооперативны ликвидацияләү турында таләп итеп судка

мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.64. Үзенә карата тикшерү үткәрелгән торак-төзелеш кооперативы, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Инспекциягә тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта торак-төзелеш кооперативы мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуынраслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Инспекциягә тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

5.65. Инспекция күрсәтмәсе җибәрелгән торак-төзелеш кооперативы күрсәтелгән күрсәтмә җибәрелгән көннән соң өч ай дәвамында күрсәтелгән күрсәтмәне законсыз дип тану турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Арбитраж судына күрсәтелгән күрсәтмәне законсыз дип тану турында гариза белән мөрәҗәгать итү аның үтәлүен туктатмый. Мондый гариза белән мөрәҗәгать итү тәртибе, аны карау тәртибе һәм күрсәтмәне законсыз дип тану турында гариза буенча карар кабул итү тәртибе арбитраж судларында суд эшен башкару турындагы законнарда билгеләнә.

5.66. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тикшерү нәтиҗәләре турындагы, шул исәптән бирелгән күрсәтмәләр турындагы тиешле мәгълүматларның һәм административ җаваплылыкка тарту турындагы белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә урнаштырылуын оештыра:

294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында һәм РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда тикшерүләрнең бердәм реестрында;

214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясындагы 5 өлеше нигезендә бердәм мәгълүмат системасында;

ТР Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында;

«Интернет» челтәрендә Инспекциянең рәсми сайтында.

## «КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРНЫ ҺӘМ (ЯИСӘ) КҮЧЕМСЕЗ МӨЛКӘТНЕҢ БҮТӘН ОБЪЕКТЛАРЫН ТӨЗҮ (БУЛДЫРУ) ӨЧЕН ӨЛЕШЛЕ ТӨЗЕЛЕШТӘ КАТНАШУЧЫЛАР АКЧАСЫН ҖӘЛЕП ИТҮГӘ БӘЙЛЕ ЭШЧӘНЛЕКНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТУРЫНДА КВАРТАЛ САЕН ТАПШЫРЫЛУЧЫ ХИСАПЛЫЛЫКНЫ ТИКШЕРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.67. Административ процедураны үти башлау өчен төзүче оешмадан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле

эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графикларының төзүче оешма тарафыннан, шартнамәләр буенча үз бурычларының үтәлүе турында квартал саен тапшырылучы хисаплылыкны, төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеген, шулай ук Россия Федерациясе законнарындагы таләпләр нигезендә төзелгән бухгалтериянең аралык һәм еллык (финанс) хисаплылыгын (алга таба – хисаплылык) алу нигез булып тора.

5.68. «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында квартал саен тапшырылучы хисаплылыкны тикшерү» административ процедурасы түбәндәге эшләр тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла:

хисаплылыкны кабул итү, теркәү;

хисаплылыкны карау;

хисаплылыкка анализ уздыру һәм тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

ачыкланган бозулар факты буенча чаралар күрү.

## ХИСАПЛЫЛЫКНЫ КАБУЛ ИТҮ, ТЕРКӘҮ

5.69. Әлеге административ гамәлне үтәү өчен җаваплы булган вазыйфаи затлар булып Инспекциянең документлар белән тәэмин итү һәм контроль бүлегенең җаваплы вазыйфаи затлары тора.

5.70. Хисаплылык түбәндәге рәвештә дә җибәрелә ала:

турыдан-туры Инспекциягә почта аша җибәреп;

шәсхән, яисә вәкаләтле вәкил аша;

көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

5.71. Хисаплылык хисап кварталы тәмамланганнан соң 30 календарь көненнән соңга калмыйча һәм IV квартал тәмамланганнан соң 90 көннән соңга калмыйча тапшырыла. Бу вакытта төзүче оешма тарафыннан хисаплылыкны тапшыру датасы булып почта аша кушымталар исемлеге белән җибәрү датасы, элемтәнең телекоммуникация каналлары аша җибәрү датасы яисә Инспекциягә фактта тапшыру датасы санала.

Хисаплылык, әгәр шушы квартал эчендә өлешле төзелештә катнашу буенча төзүче белән өлешле төзелештә катнашучылар арасында төзелгән бер генә булса да шартнамә гамәлдә булса яки әгәр дә төзүче оешманың шартнамә буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булса, квартал өчен тапшырыла.

5.72. Инспекциянең документлар белән тәэмин итү һәм контроль бүлеге вазыйфаи заты:

хисаплылыкны кабул итә;

хисаплылыкны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында теркәүгә ала;

хисаплылыкны Инспекция башлыгына карау өчен җибәрә.

Үтәү вакыты: хисаплылык кергән көнне.

## ХИСАПЛЫЛЫКНЫ КАРАУ

5.73. Инспекция башлыгы хисаплылыкны карый һәм аны резолюциясен куеп, Инспекция башлыгының беренче урынбасары юллый.

Инспекция башлыгының беренче урынбасары хисаплылыкны карый һәм резолюциясе белән аны Бүлек башлыгына юллый

Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны билгели һәм хисаплылыкны үтәү өчен юллый.

Үтәү вакыты: хисаплылык килгән көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: шушы Регламентта билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән хисаплылык.

## ХИСАПЛЫЛЫКНЫ АНАЛИЗЛАУ ҺӘМ ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.74. Шушы административ гамәлне башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып әлеге Регламентның 5.50 пункты нигезендә билгеләнгән җаваплы башкаручы тора.

5.75. Җаваплы башкаручы:

хисаплылыкның билгеләнгән барлык рәвешләре, бухгалтерия балансы булу-булмавын һәм аларның мәгънәви һәм санлы билгеләнешләрен тикшерә;

төзүче оешманың бүтән чыгымнары булуы турында мәгълүматны ачыклый. Шундыйлар булган очракта, акча тоту юнәлешен һәм проект декларациясенә сылтаманы күрсәтеп, белешмәне кабул итә;

төзүче оешманың өлешле төзелеш объектын өлешле төзелештә катнашучыга тапшырылу чорлары саклануын тикшерә. Шартнамә буенча үтәлмәгән (вакыты бозылган) йөкләмәләр булганда йөкләмәләрне тиешле тәртиптә үтәмәү сәбәпләре турында белешмә булуын тикшерә;

проект декларациясенең массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылуы турында мәгълүмат булу-булмавын тикшерә;

төзүче оешманың финанс тотрыклылыгы нормативларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче оешма эшчәнлегендә финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлары турында» 2008 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карарындагы таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә.

Төзелеш проектларын тормышка ашыруның тапшырылган якынча графикларының (алга таба – графиклар) төзүче оешма тарафыннан үтәлүен тикшерүдә тоту максатларында Бүлекнең җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектлары карала.

Төзүче оешма тарафыннан тапшырылган финанс хисаплылыгындагы белешмәләрне тикшерү зарурлыгы булганда, Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы буенча федераль хезмәтнең Территориаль органыннан алынган финанс хисаплылыгы белешмәләре файдаланыла.

Хисаплылыкны тикшерү һәм күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын карау йомгаклары буенча җаваплы башкаручы

тарафыннан ике нөсхәдә төзүче оешма хисаплылыгын тикшерү акты (шушы Регламентның 6 нчы кушымтасы) төзелә.

Үтәү вакыты: төзүче оешмадан хисаплылык килгән көннән соң 20 эш көненнән артык түгел.

Гамәлнең нәтиҗәсе: төзүче оешманың хисаплылыгын тикшерү турында рәсмиләштерелгән акт.

## АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАР ФАКТЫ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.77. Кварталлык хисаплылыкны тикшерү нәтиҗәсендә зарури таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы законнар үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән түбәндәге вәкаләтләрнең тормышка ашырылуын гамәлгә ашыра:

тикшерү актында ачыкланган бозуларның барлык очракларын да терки;

шушы Регламентның 2.12 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) проектын рәсмиләштерә;

күрсәтмә (боерык) проектын имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) төзүче оешмага планнан тыш тикшерү уздыру турында карар кабул итә. Карар кабул итү критериясе булып зарури таләпләрне бозу фактлары тора.

Төзүче оешмага планнан тыш тикшерү җаваплы башкаручы тарафыннан әлеге Регламентның 5.34, 5.35 пунктлары нигезендә уздырыла. Тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы:

әлеге Регламентның 5.36 пункты нигезендә планнан тыш тикшерү актын рәсмиләштерә;

анда зарури таләпләрне бозуның барлык фактларын терки;

әлеге Регламентның 5.37-5.39 пунктлары нигезендә зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрә, шул исәптән:

төзүче оешмага 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен, шулай ук күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү мәсьәләләрендә Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларында, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы норматив хокукый актларында билгеләнгән бүтән таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирә һәм шушы бозуларны бетерү чорын билгели;

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 14.28 статьясында каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, административ хокук бозулар турында эшләр кузгата һәм аларның билгеләнгән тәртиптә каралуын тәэмин итә, административ җәза билгели һәм куллана.

214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2.3 өлешендә күрсәтелгән фактлар ачыкланганда («Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә гражданнар – өлешле төзелештә катнашучылар хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына

үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясының 7 өлешен исәпкә алып) җаваплы башкаручы Татарстан Республикасы буенча Теркәүгә алу, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәт идарәсенә тиешле карар алынган көннән соң бер эш көненнән артмаган чорда төзүчедә күпфатирлы йортларны төзү (булдыру) өчен гражданнар – өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү хокукы булмавы турында, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2.3 өлешендә күрсәтелгән карарларны кушып, хәбәр җибәрә.

Әгәр төзүче хисаплылык тапшыруны утыз көннән артыграк вакытка кичектерсә, Инспекция билгеле бер чорга төзүче оешманың күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыруны туктатып тору турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Үтәү вакыты: шушы Регламентның 2.12 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш тикшерү зарури таләпләрне бозулар ачыкланган очракта кварталлык хисаплылыкны тикшерү тәмамланганнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча уздырыла башларга тиеш.

Гамәлнең нәтиҗәсе:

шушы Регламентның 2.12 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча уздырылган планнан тыш тикшерү.

тикшерү нәтиҗәләре буенча:

тикшерү акты;

төзелгән күрсәтмә (зарури таләпләрне бозу ачыкланганда);

административ хокук бозу турында беркетмә (административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда).

## «ТӨЗҮЧЕ ОЕШМА, ТОРАК-ТӨЗЕЛЕШ КООПЕРАТИВЫ БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШКӘ КЕРМИЧӘ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘР ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮДӘ ТОТУ ЧАРАЛАРЫН ОЕШТЫРУ ҺӘМ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.78. Административ процедураны башлап җибәрү нигезе булып Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән өлешле төзелештә катнашуның беренче шартнамәсен теркәү турында хәбәр алу, шулай ук юридик зат белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын гамәлгә ашыру срокларының килеп җитүе тора.

5.79. Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып Бүлек башлыгы тарафыннан билгеләнгән Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи затлары тора.

5.80. Юридик зат белән бәйләнешкә кермичә тикшерүдә тоту чаралары Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан мондый чараларны уздыруга Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан раслана торган йөкләмәләр нигезендә үзләренең компетенциясе чикләрендә уздырыла. Йөкләмәнең үрнәк формасы Инспекция тарафыннан билгеләнә.

5.81. «Төзүче оешма, торак-төзелеш кооперативы белән бәйләнешкә кермичә зарури таләпләр үтәлешен тикшерүдә тоту чараларын оештыру һәм уздыру»

административ процедурасы эшләрнең түбәндәге тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла:

төзүче оешманың Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат ачканда зарури таләпләрне үтәвен күзәтү;

төзүче оешмаларның Торак төзелешенең бердәм дәүләт системасындагы мәгълүматларга анализ ясау юлы белән проект декларациясенә карата зарури таләпләрнең үтәлүен күзәтү;

кооператив әгъзаларының акчасы хисабына күпфатирлы йортларны төзүне гамәлгә ашыручы төзелеш-торак кооперативының Торак төзелешенең бердәм дәүләт системасында документларны һәм мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә урнаштыруга карата зарури таләпләрне үтәвен күзәтү;

ачыкланган бозулар факты буенча чаралар күрү.

## ТӨЗҮЧЕ ОЕШМАНЫҢ ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕНЕҢ БЕРДӘМ МӘГЪЛҮМАТ СИСТЕМАСЫНДА МӘГЪЛҮМАТ АЧКАНДА ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕ ҮТӘВЕН КҮЗӘТҮ

5.82. Юридик зат белән бәйләнешкә кермичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чаралары кысаларында Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында (https://наш.дом.рф) мәгълүмат урнаштырганда төзүче оешманың зарури таләпләрне үтәвен күзәтү 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.3 статьясындагы таләпләр нигезендә уздырыла.

5.83. Тикшерү предметы булып төзүче оешманың Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында (https://наш.дом.рф) түбәндәге мәгълүматларны ачуның тәртибе, тулылыгы һәм сроклары тора:

1) Составына өлешле төзелеш объектлары керә торган һәм төзелеше (булдырылуы) өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган, 2018 елның 1 октябренә булган торышында эксплуатациягә кертелмәгән күпфатирлы йорт (йортлар) һәм (яки) күчемсез мөлкәт объекты (объектлары) төзелешенә 2018 елның 1 июленә кадәр алынган һәр рөхсәт, шул исәптән 2018 елның 1 октябренә кадәр төзелеше башланмаган һәм (яки) аларның төзелеше өчен өлешле төзелештә катанучыларның акчалары әле җәлеп ителә башламаган күчемсез мөлкәт объектларына карата да.

Төзелешкә күрсәтелгән теләсә кайсы рөхсәтләргә үзгәрешләр кертелгән очракта торак төзелеше системасында, төзелешкә бирелгән, көчен югалткан рөхсәтне торак төзелеше системасыннан бетермичә, төзүче оешмага төзелеш өчен алдагы рөхсәткә алмаш итеп бирелгән рөхсәт урнаштырылырга тиеш;

2) Күчемсез мөлкәт объекты төзелешенә 2018 елның 1 июленнән соң алынган һәр рөхсәт, шул исәптән 2018 елның 1 октябренә төзелеше башланмаган һәм (яки) аларның төзелеше өчен өлешле төзелештә катанучыларның акчалары әле җәлеп ителә башламаган күчемсез мөлкәт объектларына карата да.

Төзелешкә күрсәтелгән теләсә кайсы рөхсәтләргә үзгәрешләр кертелгән очракта торак төзелеше системасында, төзелешкә бирелгән, көчен югалткан рөхсәтне торак төзелеше системасыннан бетермичә, төзүче оешмага төзелеш өчен алдагы рөхсәткә алмаш итеп бирелгән рөхсәт урнаштырылырга тиеш.

Төзелешкә мондый рөхсәтне алыштырмыйча гына үзгәрешләр кертергә рөхсәт ителгән очракта, торак төзелеше системасында төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле органның төзелешкә кертелгән үзгәрешләр турында белешмәне үз эченә алган карары урнаштырылырга тиеш;

3) Торак төзелеше системасында урнаштырылган төзелешкә рөхсәтләрнең теләсә кайсының гамәлдә булуын туктату турында белешмәләр, төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле орган тарафыннан мондый карарны кабул итү нигезләрен күрсәтеп һәм торак төзелеше системасында әлеге карар кабул ителгән көннән соң 5 эш көненнән соңга калмыйча әлеге карарны урнаштырып;

4) Әлеге пунктның «1» һәм «2» пунктчаларында күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларына карата аларның барлык версияләрендә (редакцияләрендә) проект декларацияләре.

Төзүче оешма тарафыннан проект декларациясенә үзгәрешләр кертелгән очракта, мондый үзгәрешләр турында мәгълүмат шулай ук торак төзелеше системасында урнаштырылырга тиеш;

5) Проект декларациясен бастырып чыгарганнан алдагы 3 ел эчендә төзелеш проектларында төзүче оешма һәм (яки) аның төп җәмгыяте яки мондый төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте катнашкан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын эксплуатациягә кертү буенча барлык рөхсәтләр;

6) Төзүче оешма тарафыннан торак төзелеше системасында урнаштырылган һәр проект декларациясендә күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектын файдалануга тапшыруга алынган һәр рөхсәт;

7) Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең өлешле төзелеш турында законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында контрольдә тотучы орган тарафыннан төзүче оешмага бирелгән барлык бәяләмәләр, ә контрольдә тотучы орган тарафыннан төзүче оешмага мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту җибәрелгән очракта – шулай ук мондый баш тарту;

8) Торак төзелеше системасында урнаштырылган һәр проект декларациясе составында төзелеш проекты турында мәгълүмат ачылган һәр күчемсез мөлкәт объектына карата проект документациясенә экспертиза бәяләмәсе (тиешле күчемсез мөлкәт объектына экспертиза уздыру зарурилыгы федераль законда каралган очракта);

9) Торак төзелеше системасында урнаштырылган һәр проект декларациясе составында аның төзелеш проекты турында мәгълүмат ачылган һәм гамәлгә ашырыла башлаган һәм гамәлгә ашырылуы дәвам иткән елның I кварталы, беренче яртыеллыгы һәм 9 ае өчен арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы.

Арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы тиешле арадаш хисап чоры тәмамланганнан соң 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла;

10) Торак төзелеше системасында урнаштырылган һәр проект декларациясе составында аның төзелеш проекты турында мәгълүмат ачылган һәм гамәлгә ашырыла башлаган һәм гамәлгә ашырылуы дәвам иткән һәр ел өчен мондый хисаплылыкка карата еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы һәм аудитор бәяләмәсе.

Еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы һәм мондый хисаплыкка карата аудитор бәяләмәсе тиешле хисап елы тәмамланганнан соң 120 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла;

11) Төзүче оешма тарафыннан төзелә (булдырыла) торган, Торак төзелеше системасында аның төзелеш проекты турында мәгълүмат ачылган һәр күчемсез мөлкәт объектының фоторәсемнәре.

Торак төзелеше системасында урнаштырылган фоторәсемнәргә туры килә торган мәгълүматта фотога төшерү датасы турында мәгълүмат булырга тиеш;

12) Торак төзелеше системасында урнаштырылган һәр проект декларациясе составында төзелеш проекты турында мәгълүмат ачылган һәр күчемсез мөлкәт объектын төзү гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнары һәм барлык җир кишәрлекләрен оештыру планнарының схемалары.

Әгәр шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон нигезендә күрсәтелгән документларга үзгәрешләр кертелсә, торак төзелеше системасында мондый үзгәрешләр турында мәгълүматны үз эченә алган вәкаләтле хакимият органнары карары да урнаштырылырга тиеш;

13) Төзүче оешманың контрольдә тотучы органнан төзүче оешманың һәм проект декларациясенең законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә алган датасы белән башланган чорда узып киткән һәр квартал өчен төзүче оешманың шәхси акчалары күләме һәм финанс тотрыклылыгы нормативларын саклавы турында белешмәләр, ә төзүче оешма бер үк вакытта 2 һәм аннан артык төзелеш проекты буенча күчемсез мөлкәт объектлары төзелеше буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда – күрсәтелгән бәяләрнең иң беренче датасы белән башлана торган чорда узып киткән һәр квартал саен.

Төзүче оешманың шәхси акча күләме һәм финанс тотрыклылыгы нормативларын үтәве турында беренче белешмәсе төзүче оешма тарафыннан торак төзелеше системасында Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмәсе 2018 елның 1 октябреннән соң төзүче тарафыннан алынган беренче проект декларациясен урнаштыру белән бер үк вакытта урнаштырыла. Алга таба әлеге белешмәләрне урнаштыру төзүче оешма тарафыннан квартал саен, һәр квартал тәмамланганнан соң 5 эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла, әлеге чор дәвамында төзүче оешма күчемсез мөлкәт объектын (объектларын) төзү проектын гамәлгә ашыра, аның турында мәгълүмат торак төзелеше системасында урнаштырылган проект декларациясендә күрсәтелгән була;

14) Төзүче оешмага карата «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» Федераль закон нигезендә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсе кертелүе турында белешмәләр;

15) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 5 өлеше нигезендә төзүчегә мондый хәбәрне төзүче оешма тарафыннан җибәрү мәҗбүри булып торса, күчемсез мөлкәт объектын төзү эшләренең башлануы турында хәбәр итү. Күрсәтелгән хәбәр торак төзелеше системасында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган документлардан башка гына урнаштырыла;

16) Төзүче оешманың торак төзелеше системасында урнаштырылган һәр проект декларациясе составында төзелеш проекты турында мәгълүмат ачылган

күчемсез мөлкәт объекты төзелешенә алынган һәр рөхсәтенә карата исәп-хисап счетын ачтыру (яптыру) турында белешмәләр;

17) Төзүче оешманың торак төзелеше системасында урнаштырылган проект декларацияләрендә күрсәтелгән һәр күчемсез мөлкәт объектын (объектларын) төзү гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлегенә (кишәрлекләренә) хокукларын раслый торган документлар (Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, җир кишәрлегенең Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән аренда (субаренда) шартнамәсе);

18) Төзүче оешманың өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында хисаплылыгы, шулай ук төзелеш проектының җыелма тупланма исемлекләре;

19) Ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аркылы) корпоратив юридик зат – төзүче оешмага ия булган (капиталда катнашу өлеше 5 процентттан артык булган) физик затлар турында мәгълүмат, мондый затларның фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта), яши торган урынын (даими тору урынын), салым түләүченең шәхси номерын яки чит ил гражданнары өчен аналогик тәңгәллек билгесен, мәҗбүри пенсия иминияте системасында хосусый шәхси счетның иминият номеры (булган очракта) һәм чит ил гражданнары өчен аналогик тәңгәллек билгесен күрсәтеп;

20) Инженерлык эзләнүләре, архитектура-төзелеш проектлау һәм төзелеш буенча эшләрен башкаручы, товар китерүче һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүче затлар турында Федераль законда каралган мәгълүмат составындагы белешмәләр һәм төзүче оешмага контрольлек итүче органнан аны тапшыру турында таләп алынганда;

21) Өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү өчен кулланыла торган өлешлле төзелештә катнашу шартнамәсе проекты (проектлары);

22) Өлешле төзелештә катнашучылар акчасын эскроу счетларында урнаштырган очракта, өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча мондый акчаны җәлеп итү шартлары.

23) 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган башка мәгълүмат.

5.84. 5.83 пунктның 1-4, 8, 11, 12, 15, 17, 21, 22 пунктчаларында күрсәтелгән мәгълүмат төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган һәр күпфатирлы йортка һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектына карата ачыла.

Өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган һәр күпфатирлы йортка һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектына карата торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында төзүче оешма тарафыннан мәгълүмат ачу тәртибенә карата таләпләр Хөкүмәтнең 2019 елның 26 мартындагы 319 номерлы карары белән билгеләнгән.

5.85. Әлеге Регламентның 5.83 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат төзүче оешма тарафыннан Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында төзүче оешманың һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^{1}$ һәм 2 өлешләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында Инспекция бәяләмәсе алынган көннән соң биш эш көне эчендә урнаштырылырга тиеш. Әлеге Регламентның 5.83 пунктындагы 11

пунктчасында күрсәтелгән фотолар Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында ай саен урнаштырылырга тиеш. Әлеге Регламентның 5.83 пунктының 13 пунктчасында күрсәтелгән белешмәләр төзүче оешма тарафыннан аталган системада квартал саен 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 5 өлешендә каралган мәгълүматны урнаштыру белән бер үк вакытта урнаштырылырга тиеш.

Әлеге Регламентның 5.83 пунктында күрсәтелгән белешмәләргә һәм документларга кертелгән, ачылырга тиешле үзгәрешләр Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында мондый үзгәрешләрне керткән көннән башлап өч эш көне эчендә урнаштырылырга тиеш.

Әлеге Регламентның 5.83 пунктындагы 18 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүмат төзүче оешма тарафыннан, һәр квартал тәмамланганнан соң, 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча, торак төзелеше системасында квартал саен урнаштырыла.

Әлеге Регламентның 5.83 пунктындагы 19, 20 пунктчаларында күрсәтелгән мәгълүмат төзүче оешма тарафыннан аның турында мәгълүмат ачу беренче мәртәбә гамәлгә ашырылган проект декларациясен урнаштыру белән бер үк вакытта төзүче оешма тарафыннан торак төзелеше системасында урнаштырыла. Әлеге мәгълүматны үзгәртүләр мондый үзгәрешләр барлыкка килгәннән соң 3 эш көне узганчы төзүче оешма тарафыннан ачыла.

5.86. Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат ачканда төзүче оешма тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүен күзәтү нәтиҗәләре буенча төзүче оешмалар тарафыннан ачылырга һәм урнаштырылырга тиешле мәгълүматка карата билгеләнгән таләпләрне тикшерү акты төзелә (әлеге Регламентның 7 нче кушымтасы).

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 5.78 пунктында күрсәтелгән нигез барлыкка килгән вакыттан башлап 3 эш көне эчендә, гамәлләрне башкару ешлыгы – ай саен.

Гамәлнең нәтиҗәсе: төзүче оешмалар тарафыннан мәгълүмат урнаштырганда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерү акты.

## ТӨЗҮЧЕ ОЕШМАЛАРНЫҢ ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕНЕҢ БЕРДӘМ ДӘҮЛӘТ СИСТЕМАСЫНДАГЫ МӘГЪЛҮМАТЛАРГА АНАЛИЗ ЯСАУ ЮЛЫ БЕЛӘН ПРОЕКТ ДЕКЛАРАЦИЯСЕНӘ КАРАТА ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ ҮТӘЛҮЕН КҮЗӘТҮ

5.87. Юридик зат белән бәйләнешкә кермичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чаралары кысаларында Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында мәгълүматны анализлау юлы белән проект декларациясенә карата төзүче оешманың зарури таләпләрне үтәвен күзәтү 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.3 статьясындагы таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.88. Тикшерү предметы булып түбәндәгеләр тора:

проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19, 20, 21 статьяларындагы таләпләргә җавап бирүе;

каралган үзгәрешләрне кертү тәртибенең һәм вакытларының үтәлеше.

5.89. Проект декларациясен тутыру тәртибенә карата таләпләр Россия Төзелеш министрлыгының 996/пр номерлы боерыгында билгеләнгән.

5.90. Төзүче оешманың проект декларациясен һәм аңа үзгәрешләрне Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырганда зарури таләпләрне үтәвен күзәтү нәтиҗәсендә проект декларациясен тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелә.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 5.54 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны төзүче оешма тарафыннан ачу һәм урнаштыру срогы тәмамланган вакыттан башлап 3 эш көне эчендә, гамәлне башкару ешлыгы – квартал саен.

Гамәлнең нәтиҗәсе: проект декларациясен тикшерү нәтиҗәләре буенча акт.

## ТОРАК-ТӨЗЕЛЕШ КООПЕРАТИВЫ ӘГЪЗАЛАРЫ АКЧАСЫ ХИСАБЫНА КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРНЫ ТӨЗҮНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ТӨЗЕЛЕШ-ТОРАК КООПЕРАТИВЫНЫҢ ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕНЕҢ БЕРДӘМ МӘГЪЛҮМАТ СИСТЕМАСЫНДА ДОКУМЕНТЛАРНЫ ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТНЫ БИЛГЕЛӘНГӘН ТӘРТИПТӘ УРНАШТЫРУГА КАРАТА ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕ ҮТӘВЕН КҮЗӘТҮ

5.91. Кооператив әгъзаларының акчасы хисабына күпфатирлы йортларны төзүне гамәлгә ашыручы төзелеш-торак кооперативының торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында документларны һәм мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә урнаштыруга карата зарури таләпләрне үтәвен күзәтү РФ Торак кодексының 123.1 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.92. Тикшерү предметы булып түбәндәгеләр тора:

торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган документларның һәм мәгълүматларның  РФ ТК 123.1 статьясы таләпләренә туры килүе;

каралган үзгәрешләрне кертү тәртибенең һәм вакытларының үтәлеше.

5.93. Күзәтү нәтиҗәләре буенча торак-төзелеш кооперативы тарафыннан торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган документларны һәм мәгълүматларны тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелә.

Үтәү вакыты: Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат ачканда торак-төзелеш кооперативының зарури таләпләрне үтәвен күзәтүне тәмамаган вакыттан башлап 3 эш көне эчендә, гамәлне башкару ешлыгы – квартал саен.

Гамәлнең нәтиҗәсе: торак-төзелеш кооперативы тарафыннан торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган документларны һәм мәгълүматларны тикшерү нәтиҗәләре буенча акт.

## АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАР ФАКТЫ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.94. Юридик зат белән бәйләнешкә кермичә тикшерүдә тоту чарасы нәтиҗәсендә зарури таләпләрнең бозылуы ачыкланса, Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи заты:

үз компетенциясе кысаларында ачыкланган бозуларны чикләү чараларын күрә;

Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) ачыкланган бозулар турында мәгълүмат белән язмача формада нигезләнгән йогынты актын җибәрә.

294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясының 5-7 өлешләрендә күрсәтелгән юридик затлар белән бәйләнешкә кермичә тикшерүдә тоту чараларын уздыру барышында зарури таләпләрне бозарга әзерләнүләр яки аларны бозу билгеләре турында белешмәләр алынган очракта, Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи заты юридик затка зарури таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында кисәтү җибәрә.

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 14.28 статьясында каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи заты административ хокук бозулар турында эшләр кузгата һәм аларның билгеләнгән тәртиптә каралуын тәэмин итә, административ җәза билгели һәм куллана.

Тикшерүдә тоту чарасы барышында тикшерүдә тоту буенча чара уздыру объекты булып торган хуҗалык яисә бүтән эшчәнлекнең законнардагы таләпләрне бозуга бәйле икәнлеге ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм чикләү мәсьәләләре Инспекция компетенциясенә карамаса, Инспекция мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрергә бурычлы.

Үтәү вакыты: күзәтүләр нәтиҗәсендә актлар рәсмиләштерү – тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры;

административ хокук бозу турында беркетмә төзү – административ хокук бозуның кылынганлыгы ачыклану белән кичекмәстән.

Гамәлнең нәтиҗәсе: күзәтүләр нәтиҗәсендә төзелгән акт, административ хокук бозу турында беркетмә.

## 6. ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ТОРМЫШКА АШЫРУНЫ ТИКШЕРЕП ТОРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ

6.1. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору вазыйфаи затларның үзләренең хезмәт вазыйфаларын үтәвенә агымдагы контрольлек уздыруны, дәүләт контроле (күзәтчелеге) үтәлешенә планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне, дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруда катнашучы Инспекция вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрне карап тикшерүне үз эченә ала.

6.2. Әлеге Регламентта һәм дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрнең үтәлүен, дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүдә тоту Инспекция башлыгы, башлыкның беренче урынбасары, Бүлек башлыгы тарафыннан башкарыла.

6.3. Агымдагы контроль квартал саен Инспекциянең вазыйфаи затлары тарафыннан тапшырыла торган хисаплылыкны анализлау юлы белән, шулай ук дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышында Инспекция вазыйфаи

затларының вазыйфалары үтәлүгә тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи затлары хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү очракларын исәпкә алуны оештыра һәм алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен уздыра һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.4. Тикшерүләр планлы (хисап чорында Инспекция вазыйфаи затының эш нәтиҗәләре буенча) һәм планнан тыш (Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи затының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьне үз эченә алучы мөрәҗәгать нигезендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда элегрәк ачыкланган бозуларны бетерүне тикшерүгә бәйле рәвештә) булырга мөмкин. Тикшерү барышында дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга бәйле барлык мәсьәләләр дә карала.

Планлы тикшерүләр Инспекциянең агымдагы елга еллык эш планы нигезендә уздырыла, бу тикшерүләр мондый планга дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру аның компетенциясенә карый торган Инспекция башлыгы тарафыннан кертелә.

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның тулы һәм сыйфатлы булу-булмавына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.5. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышындагы гамәлләр (гамәл кылмау), кабул ителә торган карарлар өчен Инспекциянең вазыйфаи затлары Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгәнчә җаваплы була.

6.6. Шушы Регламентның таләпләре үтәлүен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору берләшмәләрнең һәм оешмаларның уставлары, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча иҗтимагый контрольлекнең Инспекциягә тапшырылган нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә зарури карап тикшерелергә тиеш.

## 7. ИНСПЕКЦИЯНЕҢ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАВЫНА) КАРАТА СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Юридик затлар, физик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) Инспекциянең, аның вазыйфаи затларының дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән карарларына һәм гамәлгә ашырыла торган гамәлләренә (гамәл кылмавына) буйсынучанлык тәртибендә югары торучы вазыйфаи затка шикаять белдерергә хокуклы.

7.2. Мөрәҗәгать итүче язмача рәвештә кәгазьдә яисә электрон рәвештәге шикаять белән мөрәҗәгать итәргә, шикаятьне, тиешенчә, почта аша яисә «Интернет» челтәреннән файдаланып Инспекция сайты (http://gsn.tatarstan.ru) аша җибәрергә, шулай ук шикаятьне Инспекциягә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшырырга хокуклы.

7.3. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы булып Инспекциянең, аның вазыйфаи затларының дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә

ашыру барышындагы гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм алар тарафыннан кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарлар тора.

7.4. Инспекциягә яисә, компетенцияләре нигезендә, вазыйфаи затка килгән шикаять зарури каралырга тиеш. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту яисә карап тикшерүне туктатып тору өчен нигезләр караламаган.

7.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) Инспекциянең аталышы, яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яисә тиешле затның вазыйфасы;

б) шикаятьне бирүче мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), юридик затның аталышы, электрон почта адресы, әгәр җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиешле булса, яисә почта адресы, әгәр җавап язмача рәвештә җибәрелергә тиешле булса;

в) шикаятьнең асылын бәян итү (дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышында Инспекция вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган гамәлләре (гамәл кылмавы), карарлары, шул исәптән шикаять белдерелә торган гамәлләр (гамәл кылмау), карарлар белән риза булмау сәбәпләре);

г) мөрәҗәгать итүче хәбәр итү кирәкле дип санаган бүтән белешмәләр;

д) шәхси имза һәм дата.

Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документлар һәм материаллар яисә аларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

7.6. Әгәр язмача шикаятьтә юридик затның аталышы (мөрәҗәгать итүче юридик зат булганда), шикаятьне җибәргә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр дә күрсәтелгән шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

Әгәр язмача шикаятьтә цензурасын яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, шикаять анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалануның ярамаганлыгы турында хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр язмача шикаять тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул ул карау өчен дәүләт органына, җирле

үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә.

Язмача шикаятьтә аның асылы буенча элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә инде берничә мәртәбә язмача җаваплар бирелгән сорау бәян ителгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, Инспекция башлыгы, Инспекциянең вазыйфаи заты яки моңа вәкаләтле заты күрсәтелгән шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең Инспекциягә яисә Инспекциядәге шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаять белән мөрәҗәгать итүнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән мондый язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Инспекциягә яки Инспекциянең вазыйфаи затына, 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, Инспекциянең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алучы язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәрүче затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелучы сораугa җавап урнаштырылган Инспекциянең рәсми сайтының электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне Инспекциягә яисә аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.

7.7. Инспекциягә Инспекциянең, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышында алар тарафыннан кабул ителгән карарларга шикаятьләр килү судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

7.8. Юридик затлар шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле булган мәгълүматларны һәм документларны алырга хокуклы. Мондый төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен юридик затлар Инспекция адресына язмача рәвештә тиешле гарызнамәне язмача яисә электрон рәвештә җибәрергә тиеш. Инспекциянең вазыйфаи затлары юридик затка, физик затка, гарызнамәне теркәүгә алган көннән соң 30 календарь көне эчендә, аның хокукларына һәм ирекләренә турыдан-туры кагыла торган документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген бирергә тиеш, әгәр дә мәгълүматларга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләмәләр булмаса.

7.9. Инспекция вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) җибәрелергә мөмкин.

Инспекция, Инспекция башлыгы гамәлләренә (гамәл кылмавына), карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына

җибәрелергә мөмкин.

7.10. Шикаять Инспекция тарафыннан аны Инспекциядә теркәүгә алган көннән соң утыз календарь көне эчендә карала.

7.11. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) белдерелгән шикаятьне канәгатьләндерү;

дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) белдерелгән шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру.

Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турындагы дәлилләнгән җавап мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә әлеге Регламентның 7.10 пунктында күрсәтелгән чор кысаларында җибәрелә.

7.12. Шушы Регламентта җайга салынмый торган мәсьәләләр Россия Федерациясе законнары нигезендә хәл ителә.

Регламентка 1 нче
кушымта

Инспекция тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратыла һәм алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар исемлеге

| Документның һәм (яисә) мәгълүматның аталышы | Документ һәм (яисә) мәгълүмат белән эш итүче федераль башкарма хакимият органнары, дәүләтнең бюджетка карамаган фондлары органнары |
|---|---|
| Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алуның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез мөлкәт объектына теркәлгән хокуклар турында гомумүтемле белешмәләрне үз эченә ала) | Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе |
| Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алуның бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объектына хокукларның күчүе турында өземтә | Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе |
| Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алуның бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның күчемсез мөлкәт объектына анда элек булган (хәзерге) хокуклар турында өземтә | Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе |
| Күчемсез мөлкәт объекты турында кадастр өземтәсе | Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе |
| Күчемсез мөлкәт объектының кадастр бәясе турында белешмә | Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе |
| Күчемсез мөлкәт объектының кадастр паспорты | Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе |
| Территориянең кадастр планы | Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе |
| Бухгалтерия (финанс) хисаплылыгыннан белешмәләр | Татарстанстат |
| Салым түләүчеләрнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Татарстан Республикасы буенча Федераль салым |

| | |
|---|---|
| | хезмәте идарәсе |
| Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе |
| Квалификациясе алынган затлар реестрыннан белешмәләр | Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе |
| Законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләүдә әҗәт булуы (булмавы) турында белешмәләр | Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе |
| Барлык дәрәҗә бюджетларына агымдагы финанс елында фактта түләнгән салымнарның суммасы турында белешмәләр | Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе |
| Хөкемгә тартылу һәм (яисә) җинаять эзәрлекләвендә тору фактының булуы (булмавы) яисә җинаять эзәрлекләвенең туктатылуы турында, эзләнүдә булу турында белешмәләр | ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы |

Регламентка 2 нче кушымта

Заруори таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмә (формасы)

| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

**№_____ КҮРСӘТМӘ**

_____________________________ «___» ______________ 20 ___ ел.
(актны төзү урыны) (актны төзү датасы)

_________________________________________________________________ нигезендә
(тикшерү уздыру турында боерык аталышы һәм реквизитлары)

_____________________________________________________________________________
(тикшерелә торган оешма аталышы)

урынга чыгып планнан тыш/документар тикшерү уздырылды, төзүче оешманың кварталлык хисаплылыгына анализ ясалды _______________________________________________________

_____________________________________________________________________________
(тикшерү очрагында тикшерү предметын күрсәтергә)

Тикшерү/анализ нәтиҗәсендә түбәндәге бозулар билгеләнде:

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________
(кыскача тикшерү/анализ барышында ачыкланган бозулар турында күрсәтелә)

Әлеге бозулар ____ елның «___»_______ № ____ тикшерү актында/хисаплылыкны тикшерү актында чагылдырылды һәм тикшерү/анализ материаллары белән раслана.

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясында бирелгән вәкаләтләр нигезендә түбәндәгеләрне **тәкъдим итәм:**_____________________________

_____________________________________________________________________________
(тикшерелә торган оешма аталышы)

Түбәндәгеләрне бетерергә: _____________________________________________________

_____________________________________________________________________________
(ачыкланган бозуларны бетерү турында үтәү өчен заруори таләпләр чиратлаштырып күрсәтелә)

Шушы күрсәтмәне билгеләнгән вакытында үтәмәү Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясының 4 өлешендә каралган административ җаваплылыкка китереп чыгара.

Әлеге күрсәтмәне 20___ елның «__»___________ кадәр үтәү турында ТР ДТК инспекциясенә язмача хәбәр итәргә, түбәндәге адрес буенча:________________________________

_____________________________________________________________________________

_________________________________ __________ ___________________________
(күрсәтмәне биргән вәкаләтле затның вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

Күрсәтмәне үтәү өчен кабул итте _______________________________________________
(вәкиллек турында документ реквизитлары)

______________________________________ ___________ _____________________________
(юридик затның вәкаләтле вәкиленең вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

20____ елның «___» ____________ .

Регламентка 3 нче кушымта

Административ хокук бозу турында беркетмә
(формасы)

ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

**БЕРКЕТМӘ № ___**
**АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУ ТУРЫНДА**

______________________ 20__ елның «___»____________
(төзү урыны)
Беркетмәне төзү вакыты ______ сәг. ______ мин.

Мин, ________________________________________________________________
(беркетмәне төзегән затның вазыйфасы, Ф.И.А.)
Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.1 статьясының 1 пунктындагы 1 өлешенә, 28.2, 28.3 статьяларына таянып, административ хокук бозу турында эш кузгатылды һәм юридик (вазыйфаи) затка карата беркетмә төзелде:

Юридик затның тулысынча аталышы:
Юридик затның кыскартылган аталышы:
Юридик адресы (урнашкан урыны), телефон/факс:
ОГРН_______, ИНН ________, КПП______
Җитәкчесенең Ф.И.А.:
Башка белешмәләр:
__________________________________________________________________________
(административ җаваплылыкка тарту һ.б.)
____________________________________________________________уздырганда
(бозу очрагын ачыклаган чара күрсәтелә)
билгеләнде:__________________________________________________________
(бозуның асылы күрсәтелә)
Күрсәтелгән бозу __________________________________________чагылдырылды
(бозу чагылдырылган документ реквизитлары күрсәтелә)
Бозу очрагы барлыкка килгән урын:
Бозу очрагы барлыкка килгән вакыт:
Бозу билгеләнде:
Бозу очрагы түбәндәге дәлилләр белән раслана:
Административ җаваплылыкны йомшартучы хәлләр:
Административ җаваплылыкны катлауландыручы хәлләр:

Шул рәвешле, юридик затның аталышы (вазыйфаи затның ФИА), административ хокук бозды, аның өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының ____ статьясының ____ өлешендә җаваплылык каралган.

Үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган юридик затның аталышы (вазыйфаи затның ФИА) вәкиленә аның Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган хокуклары һәм бурычлары хакында аңлатмалар бирелде:

– эшнең барлык метариаллары белән танышу, дәлилләр тапшыру, эшне караганда катнашу, чыгыш ясау, аңлатмалар бирү, үтенечләр һәм каршы чыгулар белдерү, туган телендә шикаятьләр белдерү, тәрҗемәче хезмәтләреннән файдалану, яклаучының юридик ярдәменнән файдалану, шулай ук Административ хокук бозулар турында РФ кодексы нигезендә бүтән процессуаль хокуклардан файдалану хокукы (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 24.2 ст., 25.1 ст.);

– административ хокук бозу турында беркетмә белән танышу хокукы (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 28.2 ст. 4 өлеше);

– административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсен язу кәгазе белән алу хокукы (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 28.2 ст. 6 өлеше);

– законда билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозу турында эш буенча чыгарылган карарга шикаять белдерү (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 30.1 статьясы).

Беркетмәне укыдым. Дөрес язылган.

Вәкил яисә вазыйфаи зат____________ ____________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Үзенә карата эш кузгатылган юридик зат вәкиленең яисә вазыйфаи затының аңлатмалары, эшне хәл итү өчен кирәкле башка мәгълүматлар:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар һәм кисәтүләр:

________________________________________________________________________

(юк, беркетмәгә теркәлә)

Беркетмә белән таныштым, беркетмә күчермәсе бирелде (бирелмәде)

________________________________________________________________________

(юридик зат вәкиленең, вазыйфаи затының имзасы, Ф.И.А./беркетмәне төзегән вазыйфаи затның имза куюдан баш тарту турында язуы)

Хәзергесе белән ТР ДТК инспекциясенә минем персональ белешмәләремне эшкәртүгә ризалык бирәм. Эшкәртүнең максаты – ТР ДТК инспекциясендә автоматлаштырылган документ әйләнешен тәэмин итү. Электрон документлар ясау һәм аларны ТР ДТК инспекциясенең компьютердагы белешмәләр базасында саклау. Әлеге ризалыкның гамәлдә булу чоры аны кайтарып алу белән чикләнә. Ризалыкны кайтарып алу ТР ДТК инспекциясенә язмача мөрәҗәгать итү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

(«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон).

________________________________________________________________________

(имза, Ф.И.А.)

шаһитларның имзалары (булган очракта) ________________________________


(имза, вазыйфа, Ф.И.А.)

беркетмәне төзегән вазыйфаи затның имзасы______________________________

(имза, Ф.И.А.)

Регламентка 4 нче кушымта

ТР ДТК инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) кучемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы



Регламентка 5 нче кушымта

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге*

1. Инспекция башлыгы
2. Инспекция башлыгы урынбасарлары
3. Бүлек башлыгы;
4. Әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант.

* Исемлектә күрсәтелгән Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 28.3 статьясында, асылда Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 13.19.2 статьясында (күпфатирлы йортларны төзүне гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 13.9.3 статьясында (төзүче оешма, төзүче оешманың вазыйфаи затлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 14.28 статьясының 1-5 өлешләрендә, 14.28.1 статьясында һәм 19.5 статьясының 4 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы.

Регламентка 6 нче кушымта

# Акт
## төзүче оешманың кварталлык хисаплылыгын тикшерү турында

**20_____ елның «____»_______________ №_______**

**Төзүче оешманың аталышы:** ______________________________

**Хисап чоры:** ______________________________

______________________________________________________________

**(Вазыйфа)** **(фамилиясе, исеме, атасының исеме)**

түбәндәге юнәлешләр буенча тапшырылган кварталлык хисаплылыкка тикшерү уздырылды:

| № п/п | Тикшерелә торган сорауларның аталышы | Тикшерүдә билгеләнде |
|---|---|---|
| 1 | Хисаплылыкны тапшыруның вакытында башкарылуы (датасы) | |
| 2 | Тапшырылган хисаплылыкның тулы булуы | |
| 3 | Рәсмиләштерелүенең дөрес булуы (имзалар, мөһерләр, тегелеше) | |
| 4 | Кварталлык бухгалтерия хисаплылыгы | |
| **1. Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыручы төзүче оешма турында белешмәләр** | | |
| 1 | Фирманың исеме (аталышы) (оешу-хокук формасын күрсәтеп, рус телендә) | |

| | | |
|---|---|---|
| 2 | Кыскартылган фирма исеме (аталышы) (оешу-хокук формасын күрсәтеп, рус телендә булганда күрсәтелә) | |
| 3 | Урнашу урыны | |
| 4 | Проект кысаларында төзелә торган капиталь төзелеш объектларының урнашкан урыны (төзелешкә рөхсәт бирелгән һәр күчемсез мөлкәт объекты буенча аерым тутырыла) | |
| 5 | Бер кулдагы башкарма орган (төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы вазыйфаларын башкаручы оешманың фирма исеме (аталышы) яисә мондый вазыйфаларны башкаручы физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) күрсәтелә) | |
| 6 | Төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН) | |
| 7 | Дәүләт теркәвенә алу датасы | |
| 8 | Салым түләүченең тәнгәллек номеры (ИНН) | |
| 2. Төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган күпфатирлы йорт һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объекты турында белешмәләр (төзелешенә рөхсәт бирелгән һәр күчемсез мөлкәт объекты буенча аерым, өлешле төзелештә беренче катнашучы белән шартнамә төзелгән кварталдан башлап үсә баручы йомгаклары белән һәм өлешле төзелештә катнашучы белән соңгы шартнамә буенча төзүче оешманың үз йөкләмәләре үтәлгән квартал буенча тутырыла.) | | |
| 1 | Күчемсез мөлкәт объектының исеме (төзелешкә рөхсәт буенча) | |
| 2 | Күчемсез мөлкәт объектының урнашу урыны (төзелеш адресы) | |
| 3 | Күчемсез мөлкәт объектын төзү (булдыру) өчен бирелгән җир кишәрлегенә хокук турында мәгълүмат: | |
| 3.1 | җир кишәрлегенең кадастр (шартлы) номеры | |
| 3.2 | хокук төре (милек, аренда, субаренда, сроксыз куллану) | |
| 3.3 | аренда шартнамәсенең датасы, номеры, аның гамәлдә булу чоры | |
| 3.3 | күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында җир кишәрлегенә хокукны теркәү турында язылу датасы һәм номеры | |
| 4 | Төзелеш өчен рөхсәт турында мәгълүмат: | |
| 4.1 | Төзелешкә рөхсәт номеры һәм аны бирү датасы | |
| 4.2 | Төзелешкә рөхсәт биргән орган (оешма) атамасы | |

| | | |
|---|---|---|
| 4.3 | Төзелешкә рөхсәтнең беренчел гамәлдә булу срогы (үзгәрешләр керткәнче) | |
| 4.4 | Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү датасы, кертелгән үзгәрешләрнең кыскача тасвирламасы | |
| 4.5 | Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогының яңа вакыты турында мәгълүмат | |
| 5 | Үзләренә карата өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре төзелергә мөмкин булган күчемсез мөлкәт объекты составындагы мөстәкыйль өлешләрнең гомуми күләме, шул исәптән: | |
| 5.1 | Торак урыннар | |
| 5.2 | Торак булмаган биналар | |
| 5.3 | Машина-урыннар | |
| 6 | Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең өлешле төзелеш турында законнардагы таләпләргә туры килүе турында бәяләмә алынган датага булган торышында проект декларациясендә күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектын төзүнең (булдыруның) планлаштырылган бәясе (алга таба – төзелешнең проект бәясе) (млн.сум) | |
| 7 | Хисап чорында төзелешнең проект бәясен үзгәртү (млн. сум) | |
| 8 | Хисап датасына төзелешнең проект бәясе (млн. сум) | |
| 9 | Хисап датасына булган торышында төзелеш проектын гамәлгә ашыру буенча төзүче оешма тарафыннан фактик сарыф ителгән чыгымнар, барлыгы (млн. сум), шулардан: | |
| 9.1 | Төзелешнең гомуми фактик бәясе (млн.сум) (төзүче оешма тарафыннан башкарылган эшләргә, сатып алынган материалларга һәм күрсәтелгән хезмәтләргә фактик тотылган акчаның, шулай ук төзелеш проектын гамәлгә ашыру өчен бирелгән авансларның күләме) | |
| 9.2 | Подрядчыларга һәм тәэмин итүчеләргә бирелгән аванс күләме (млн.сум) (хисап чорының соңгы календарь датасына, төзелеш эшләрен, заказчы һәм сатып алучы функцияләрен, төзелеш проектын тормышка ашыру максатларында товар-матди кыйммәтләрне сатып алучы | |

| | | |
|---|---|---|
| | функцияләрен төзүче оешма тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашыру очрагында) | |
| 9.3 | Төзүче оешма хезмәтләре өчен түләүгә акча күләме (күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүнең (булдыруның) планлаштырылган бәясеннән төзүче оешма хезмәтләре өчен түләүгә 2018 елның 1 июленә кадәр алынган төзелешкә рөхсәт буенча төзелеш проектын гамәлгә ашыручы төзүче оешма тарафыннан проект декларациясендә күрсәтелгән акча күләме. Бүтән очракта төзүче оешманың аның эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары (административ һәм гомумхуҗалык чыгымнары) күләме күрсәтелә. Хисап чорының соңгы календарь датасына күрсәтелә (млн. сум)) | |
| 10 | Күчемсез мөлкәт объектын төзү (булдыру) өчен җәлеп ителгән кредит (заем) акчалары турында мәгълүмат: | |
| 10.1 | Күчемсез мөлкәт объектын төзүгә (булдыруга) кредит (заем) акчаларын биргән кредит оешмасының исеме, ИНН | |
| 1.2 | Кредит (заем) акчаларының гомуми күләме (млн.сум) | |
| 1.3 | Өлешле төзелештә беренче катнашучы белән шартнамә төзелгәнче җәлеп ителгән кредит (заем) акчалары (млн. сум) күләме | |
| 4.4 | Өлешле төзелештә беренче катнашучы белән шартнамә төзелгәннән соң җәлеп ителгән кредит (заем) акчалары (млн. сум) күләме | |
| 1.5 | Максатчан заем биргән төп җәмгыятьнең исеме, ИНН | |
| 5.6 | Заем акчаларының гомуми күләме (млн. сум) | |
| 11 | Күчемсез мөлкәт объектын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылардан җәлеп ителгән акча күләме турында мәгълүмат: | |
| 11.1 | Хисап чорының беренче календарь датасына төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча җәлеп ителгән өлешле төзелештә катнашучылар акчасы күләме (млн. сум) | |
| 11.2 | Хисап чорында өлешле төзелештә катнашучылардан җәлеп ителгән акча күләме (млн. сум) | |

| | | |
|---|---|---|
| 11.3 | Төзүче оешма тарафыннан күчемсез мөлкәт объектын төзү (булдыру) өчен җәлеп ителгән өлешле төзелештә катнашучылар акчасының гомуми суммасы (млн. сум) | |
| 11.4 | Максатчан билгеләнеше буенча хисап чорында төзүче оешма тарафыннан файдаланылган өлешле төзелештә катнашучылар акчасы суммасы (млн.сум) (2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 1 өлеше нигезендә) | |
| 11.5 | Шартнамәләрне өзүгә бәйле рәвештә өлешле төзелештә катнашучыларга хисап чорында кире кайтарылган акча суммасы (млн. сум) | |
| 11.6 | Хисап чорының соңгы календарь датасына өлешле төзелештә катнашучыларның акча суммасы (млн.сум) (12.4 һәм 12.5 графалардагы күрсәткечләр суммасы алынган 12.1 һәм 12.2 графалардагы күрсәткечләрнең суммасы күрсәтелә) | |
| 12 | Күчемсез мөлкәт объекты буенча өлешле төзелештәкатнашу буенча төзелгән шартнамәләр (алга таба – шартнамә) турында мәгълүмат: | |
| 12.1 | Беренче шартнамә төзү датасы | |
| 12.2 | Хисап чорында төзелгән шартнамәләр саны | |
| 12.3 | Хисап чорында өзелгән шартнамәләр саны | |
| 12.4 | Хисап чорының соңгы календарь датасына гамәлдә булган шартнамәләр саны | |
| 12.5 | Хисап чорының соңгы календарь датасына үзләренә карата шартнамәләр гамәлдә булган өлешле төзелеш объектлары – торак урыннар саны | |
| 12.6 | Хисап чорының соңгы календарь датасына үзләренә карата шартнамәләр гамәлдә булган өлешле төзелеш объектлары – торак булмаган урыннар саны | |
| 12.7 | Шартнамәләр буенча йөкләмәләрнең гомуми суммасы (млн. сум) | |
| 13 | Төзүче оешма тарафыннан шартнамәләр үтәлеше турында мәгълүмат (9 графаны исәпкә алып): | |
| 13.1 | Төзүче оешма тарафыннан башкарылган шартнамәләр саны (2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы | |

| | | |
|---|---|---|
| | Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлеше нигезендә төзүче оешманың йөкләмәләре яклар тарафыннан өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе яисә өлешле төзелеш объектын тапшыру турындагы башка документ имзаланганнан соң үтәлгән дип санала) | |
| 13.2 | Төзүче оешма тарафыннан үтәлмәгән шартнамәләр саны | |
| 13.3 | Төзүче оешма тарафыннан шартнамәләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләрнең гомуми суммасы (млн. сум) | |
| 14 | Өлешле төзелеш объектларын өлешле төзүдә катнашучыларга тапшыруның күздә тотылган вакыты (проект декларациясендә күрсәтелгән объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт алуның күздә тотылган срогыннан чыгып, өлешле төзелеш объектларын өлешле төзелештә катнашучыларга тапшыру срогы) | |
| 15 | Төзелеше тәмамланган күчемсез мөлкәт объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт турында мәгълүмат: | |
| 15.1 | Күчемсез мөлкәт объектын файдалануга тапшыру өчен рөхсәт бирелү датасы, номеры | |
| 1.2 | Күчемсез мөлкәт объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт биргән органның (оешманың) исеме | |
| 16 | Иминият шартнамәсе турында белешмәләр (2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.6 статьясында каралган очракта): | |
| 16.1 | Иминият оешмасының исеме (кыскартылган исеме), урнашу урыны, ИНН | |
| 16.2 | Иминият шартнамәсенең датасы һәм номеры | |
| 16.3 | Иминият шартнамәсенең гамәлдә булу срогы, аны озайткан очракта иминият шартнамәсенең гамәлдә булуының яңа чоры | |
| 17 | Түләү җаваплылыгы турында шартнамә төзү хакында мәгълүмат: | |
| 17.1 | Түләү җаваплылыгын алучы банкның исеме (кыскартылган исеме), урнашу урыны, ИНН | |
| 17.2 | Түләү җаваплылыгын алу шартнамәсенең датасы һәм номеры | |
| 17.3 | Түләү җаваплылыгын алу шартнамәсенең гамәлдә булу | |

| | | |
|---|---|---|
| | срогы, аны озайткан очракта иминият шартнамәсенең гамәлдә булуының яңа чоры | |
| 18 | Компенсация фондына түләүләр (кертемнәр) түләү буенча йөкләмәләрне үтәү турында белешмәләр (өлешле төзелеш турындагы Законның 3 статьясының 4 өлешендә каралган очракта) | |
| 18.1 | Төзүче оешма тарафыннан «Гражданнар – өлешле төзелештә катнашучылар хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенең компенсация фондына күчерелгән мәҗбүри акча (кертемнәр) суммасы (млн.сум) | |
| 18.2 | Төзүче оешма тарафыннан «Гражданнар – өлешле төзелештә катнашучылар хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенең номинал счетына кертелгән мәҗбүри акча (кертемнәр) суммасы (млн.сум) | |
| **3. Төзүче оешма эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлары турында мәгълүмат** | | |
| 1 | Йөкләмәләрнең тәэмин ителеш нормативы (Н1) (төзелешкә 2018 елның 1 июленә кадәр рөхсәт алган төзүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә.)(кимендә 1) | |
| 2 | Акчаны максатчан куллану нормативы (Н2) (төзелешкә 2018 елның 1 июленә кадәр рөхсәт алган төзүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә.)(1 артык түгел) | |
| 3 | Сарыф итмәүчәнлек нормативы (төзелешкә 2018 елның 1 июленә кадәр рөхсәт алган төзүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә.)(кимендә 1) | |
| 4 | Төзүче оешманың шәхси акча күләме (төзелешкә 2018 елның 1 июленнән соң рөхсәт алган төзүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә.) | |
| **4. Төзелеш проектын һәм шартнамәләр буенча йөкләмәләрне гамәлгә ашыруның якынча графигы** | | |
| 1 | Төзелеш проектын тормышка ашыру графигын һәм өлешле төзүдә катнашу шартнамәләре буенча үз йөкләмәләрен үтәү | |
| 2 | Өстәмә мәгълүматлар тапшыру | |
| **5. Төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеге** | | |
| 1 | Төзелеш проектының җыелма тупланма исемлегенә | |

| | | |
|---|---|---|
| | карата искәрмәләр | |
| | | |
| **Тикшерү нәтиҗәсе** | | |
| | **Хисаплылык** (**кабул ителде, кабул ителмәде**) | |
| **2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозу очраклары ачыкланды:** | | |
| **1.** | | |
| **2.** | | |
| **3.** | | |
| **Россия Төзелеш Министрлыгының 12.10.2018 ел, № 656/пр боерыгы таләпләрен бозу очраклары ачыкланды:** | | |
| **1.** | | |
| **2.** | | |
| **3.** | | |
| **Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карары таләпләрен бозу очраклары ачыкланды:** | | |
| **1.** | | |
| **2.** | | |
| **3.** | | |

**Актка теркәлә:** кушымталары белән хисаплылык _____ биттә.

**Хисапны тикшерде:** ___________________ (________________________)

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

__**Ачыкланган бозуларны бетерүгә карата күрсәтмә бирелде**__:

214-ФЗ номерлы Федераль закон ___________________________ кадәр

Россия Төзелеш министрлыгының 12.10.2018 № 656/пр боерыгы ___________________________ кадәр

РФ Хөкүмәтенең 1683 номерлы карары ___________________________ кадәр

__**Хисаплылыкта ачыкланган кисәтүләр бетерелде**__:

| | |
|---|---|
| 214-ФЗ номерлы Федераль закон | ______________________ (әйе яисә юк) |
| Россия Төзелеш министрлыгының 12.10.2018 № 656/пр боерыгы | ______________________ (әйе яисә юк) |
| РФ Хөкүмәтенең 1683 номерлы карары | ______________________ (әйе яисә юк) |

Регламентка 7 нче кушымта

**А К Т**
**төзүче оешма тарафыннан мәгълүмат ачу һәм урнаштыру таләпләренең үтәлешен тикшерү турында**

**20___ елның «____»_____________ № ______**

Төзүче оешма: ___________________________________
(төзүче оешманың аталышы)

| № п/п | 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә төзүче оешма тарафыннан мәгълүматларны ачу һәм урнаштыру | 214-ФЗ номерлы Федераль закон пункты | Тикшерү нәтиҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт | 3.1 статьяның 2 өлешендәге 1 пункты | |
| 2. | Төзелешкә рөхсәт (һәр объект буенча) | 3.1 статьяның 2 өлешенең 2 пункты (21 ст. 2 өлешенең 1 пункты) | |
| 3. | Проект документациясенә экспертиза бәяләмәсе, әгәр мондый экспертизаны үткәрү федераль законда билгеләнсә (һәр объект буенча) | 3.1 статьяның 2 өлешендәге 2 пункты (21 ст. 2 өл. 3 пункты) | |
| 4. | Төзүче оешманың җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар (һәр объект буенча) | 3.1 статьяның 2 өлешендәге 2 пункты (21 ст. 2 өл. 5 пункты) | |
| 5. | Проект декларациясе | 3.1 статьяның 2 өлешендәге 3 пункты | |
| 6. | Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең ярашлылыгы турында бәяләмә | 3.1 статьяның 2 өлешендәге 4 пункты | |
| 7. | Өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе проекты яисә төзүче тарафыннан күпфатирлы йортны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү өчен кулланыла торган мондый шартнамәләрнең проектлары (һәр объект буенча) | 3.1 статьяның 2 өлешендәге 5 пункты | |
| 8. | Федераль законның 12.1 статьясының 2 өлеше нигезендә өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча вазыйфалар үтәлешен тәэмин итүнең төзүче тарафыннан сайланган ысуллары яисә Федераль законның 15.4 һәм 15.5 статьяларындагы таләпләр нигезендә өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе буенча өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү шартлары турында мәгълүмат (исәп-хисап счеты, (комп. фондына/эскроу акча күчерү турында документ (түләү йөкләмәсе)) | 3.1 статьяның 2 өлешендәге 6 пункты | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | Федераль законның 12.1 статьясының 3 өлешендә каралган очракта Федераль законның 15.3 статьясы нигезендә төзүче оешма белән төзелгән җаваплылык алу шартнамәсе (устав капиталы күләме Федераль закон таләпләренә җавап бирмәгән очракта) | 3 статьясының 2 өлешендәге 7 пункты | |
| 10 | Агымдагы елның беренче кварталы, ярты еллыгы һәм тугыз ае буенча кварталлык нигезендә төзүче оешманың арадаш бухгалтер (финанс) хисаплылыгы турында мәгълүматлар | 3.1 ст.2 өл. 7 п.; 3 ст. 5 өл. | |
| 11 | Төзүче оешма тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген башкаруның соңгы елы өчен төзүче оешманың еллык бухгалтерия (финанс) хисаплылыгы турында белешмәләр | | |
| 12. | Төзүче оешма тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегенең гамәлгә ашырылуы турында соңгы ел өчен аудитор бәяләмәсе | 3.1 статьяның 2 өлешендәге 2 пункты | |
| 13. | Төзелә торган объектларның төзелеш торышын чагылдыручы фоторәсемнәре (һәр ай саен) | 3 статьяның 2 өлешендәге 8 пункты | |
| 14 | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы | 3.1 ст. 2 өлешенең 9 пункты | |
| 15 | Җир кишәрлегенең шәһәр төзү планында күрсәтелгән мәгълүматларга ярашлы рәвештә эшләнгән, капиталь төзелеш объекты урнашкан урынны, аңа машина белән килү һәм үтү юлларын, гавами сервитутларның гамәлдәге зоналары чикләрен, археологик мирас объектларын билгеләп, җир кишәрлеге оештыруның план схемасы | 3.1 ст. 2 өлешенең 10 пункты | |
| 16 | Төзүче оешманың шәхси акчалары күләмен исәпләү һәм финанс тотрыклылыгы нормативлары турындагы мәгълүматны үз эченә алган документ | 3.1 ст. 2 өлешенең 11 пункты | |
| 17 | «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында белешмәләр | 3.1 ст. 2 өлешенең 12 пункты | |
| 18 | Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында шәһәр төзү эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә җибәрелгән хәбәр | 3.1 ст. 2 өлешенең 13 пункты | |
| 19 | Төзүче оешманың исәп-хисап счетын ачу турында яки ябу турында белешмәләр, мондый счетның номерын, вәкаләтле банк исемен һәм аның идентификаторларын (салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры) күрсәтеп | 3.1 ст. 2 өлешенең 14 пункты | |
| 20 | Законнарда каралган башка мәгълүмат | РФ Хөкүмәтенең 319 номерлы карары | |
| 21 | Торак төзелешенең   бердәм мәгълүмат | 3.1 статьяның 3 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | системасында төзүче оешманың һәм проект декларациясенең ярашлылыгы турында урнаштыру датасы | өлеше | |
| 22 | Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән документларга үзгәрешләрне урнаштыру датасы | 3.1 статьяның 4 өлеше | |

**Нәтиҗәләр:** ______________________________________________________________

______________________________________________________________

Вазыйфа ____________ /Ф.И.А./

Вазыйфа ____________ /Ф.И.А./